МӘКТӘП КИТАПХАНӘСЕ

Г. БӘШИРОВ

СИВАШ

МӘКТӘП КИТАПХАНӘСЕ

ГОМӘР БӘШИРОВ

СИВАШ

ПОВЕСТЬ

Сигезенче басма

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1977

С(Тат)2
Б90

Художник *В. В. Вагин* оформлениесе
Г. Е. Трифонов рәсемнәре

«Сиваш» повесте — гражданнар сугышының тарихи фактларына нигезләнеп язылган популяр әсәрләрнең берсе. Повестьның авторы китапта тасвирланган героик сугыш вакыйгаларында үзе катнашкан.

Бу китап 1937 елдан бирле әледән-әле басылып тора. Аның русча тәрҗемәсе зур тираж белән беренче мәртәбә Мәскәүдә һәм Казанда басылып чыкты.

УРТА ҺӘМ ОЛЫ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

Баширов Гумер Баширович

СИВАШ

(на татарском языке)

Редакторы Резеда Вәлиева
Художество редакторы Э. Е. Сподикова
Техник редакторы Ф. Х. Абдрахманова
Корректорлары С. С. Гайфуллина, Ә. Х. Салахова

ИБ № 581

Наборга бирелде 19/V-1976 ел. Басарга кул куелды 3/VIII-1976 ел. Типография кәгазе № 1. 84×108¹/₃₂. Учетн. изд. табагы 8,0. Якынча басма табагы 7,56. Заказ Е-410. Тираж 15 000. Бәясе 38 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты, Казан, Бауман ур., 19.

Б $\frac{70803-001}{М132(03)-77}$ 131—77

«СИВАШ» ПОВЕСТЕ НИЧЕК ЯЗЫЛДЫ

Ул елларда мин Балтачта халык тикшерүчесе булып эшли идем. Бер елны, Мәскәү журналисты дустым Кадыйр Урманов кунакка кайткач, Шушма суы буенда йөргәндә, мин аңа Сиваш сазлыгын ничек кичүебезне, Кырымны аклардан ничек азат итүебезне сөйләдем. Кадыйр әсәрләнеп тыңлады да, шундый зур сугышта катнаша торып, бу хакта язмыйча түзеп йөрүемә бик гаҗәпләнде.

— Яз син бу хакта! Кара аны, язмыйча калма! — диде, миннән бик нык вәгъдә алып китте.

Ләкин вәгъдәмне тиз генә үти алмадым. Чөнки хезмәтем шундый, һәрвакыт төнне көнгә ялгап, атналар буе ял итмичә эшләргә туры килә иде. Әмма сугышта баштан узганнар, һич тә истән чыкмыйча, һәр даим дулкынландырып торды. Ниһаять, түзеп булмады, мин ул хакта очерк яздым. Вакыт булмауга карамастан, тикшерү эшләре белән йөргәндә авыл Советларының салкын канцеляриясендә төннәрен бер үзем калып булса да, җиделе лампа яктысында булса да яздым.

Кави Нәҗми очеркны бик ошатуын әйтте.

— Бу темага зуррак әсәр язарга да мөмкинлегегез бар, стилегез дә шундый, — диде.

Бу яхшы киңәшләрне хуп күрсәм дә, зур әсәр язу ул вакытта хыял гына иде әле. Ул елларда авыл хуҗалыгын күмәкләштерү башланганлыктан, авыл интеллигенциясе ифрат киеренке, бик тә кырыс тормыш белән яшәде. Кая ул әдәби иҗат турында уйлау! Шәхси тормышны кайгыртырга гомумән вакыт калмый иде.

Бу хыялны юстициядән матбугат эшенә күчеп, марксизм-ленинизм институтында укып чыкканнан соң гына гамәлгә ашырырга мөмкинлек туды. Ул вакытта мин газета-журналларда эшләп азмыкүпме тәҗрибә дә туплаган идем. Күрәсең, каләмем дә бераз «шомара» төшкәндер.

Беренче карашка, китап язу өчен «читкә чыкмаска» да була, үз башымнан үткәннәр дә бик җиткән кебек иде. Чыннан да, гражданнар сугышы елларында безнең буын кайда гына булмады, ниләр генә кичермәде! Мин, ярым-йорты гына русча белгән гади авыл малае, Казанда оешкан дивизиянең солдаты буларак, беренче тапкыр туган авылымнан еракка китеп, ярты Россияне диярлек әйләнеп чыктым. Гомеремдә беренче мәртәбә Мәскәү каласында, революция бишеге — Петроградта, Ладога буенда булдым, Псков урманнарының кай төшендәдер яшел бандаларга каршы сугышып йөрдем. 1920 елда Көньяк фронты ачылганнан соң, иңемә винтовка, патронташ, кәрәк, граната һәм башка шундый сугыш кирәк-ярагы аскан хәлдә Украинаның байтак җирләрен, Таврия далаларын аркылыга-

буйга җәяү йөреп чыктым. Полкташ иптәшләрем — руслар, татарлар, украинлылар һәм башка милләт уллары белән бер сафта без, аклар армиясен куа-куа, Кара диңгезгә барып җиттек. Яшь Совет властен дошманнардан саклап калу өчен чал Днепр камышларын айкадык, Черек диңгезнең (Сивашның) серле дәһшәте алдында да туктап калмадык. Бу — Көньяктагы гражданнар сугышының соңгы көннәре, иң кыен, иң авыр көннәре иде. Кырымга бәреп кергәндә, Перекопта һәм Сивашта, ун меңнәрчә батыр сугышчыларыбыз мәңгегә егылып калды. Аларның кайберләрен Сивашның мәкерле чаклаклары* суырып алды, кайберләре акларга каршы авыр сугышларда һәлак булдылар. Ул сугышларның ни дәрәҗәдә авыр булуына бер генә мисал: Сивашны кичкәч, акларның соңгы позицияләрен штурмлаганда безнең ротадагы җитмеш биш сугышчы һәм командирдан бер-ике сәгать эчендә нибары унсигезе генә исән калды. Шулай да Кызыл Армиянең ярсу атакаларын яңгыр урынына яуган пулялар да, үкереп килгән снарядлар да, кавалерия атакалары да — берсе дә туктата алмады. Безнең һәммәбезгә дә ифрат та авыр, чиктән тыш кыен иде. Әмма әгәр дә шул вакыт туган ил кирәк тапкан булса, шул ук кыен, хәвефле юлларны без, һич икеләнмичә, яңадан бер мәртәбә үткән булыр идек.

Китапның нигезенә күңелдә уелып калган менә шушы истәлекләр салынды. Ләкин мондый зур тарихи әһәмиятле вакыйгаларны киләсе буыннарга һич ялгыштырмыйча, тормышның үзендә ничек булса, шулай җиткерү өчен истәлекләр генә җитенкерәми иде. Сугыш булып узган урыннарга яңадан барып чыгарга, сугышта катнашкан кешеләр белән сөйләшергә, архив документлары белән танышырга кирәк булды.

1935 елның җәендә, ягъни сугыш гөрелтесе тынып унбиш ел узганнан соң, Строгановка авылына яңадан барып чыктым. Безнең дивизияне дөм караңгы төндә озын таягы белән кармаланып, аягы белән капшап диярлек Сиваш аша алып чыккан батыр йөрәкле Оленчук бабайның ишеген кактым. Картым җанланып китте. Күкрәгенә орденын тагып үзе буе таягына таянды да, Сивашка юнәлдек. Сугыш төнендә дивизия штабы урнашкан, Фрунзе шуннан приказларын биреп торган яр башындагы кечкенә өйдә музей ачканнар икән, узышлый аңа да кердек.

Сивашның тыныч чагы иде. Еллар да күп узганлыктан, сугыш эзләре томаланган, йомылган иде. Без сугышып узган төндә кешеләр һәм атларны, орудиеләр һәм тачанкаларны йотып калган шомлы урыннар бөтенләй тигезләнгән. Черек диңгез үзенең мәкерле явызлыгын дөнья күзенә күрсәтмәс өчендер, күрәсең, аларны дөм караңгы куенына яшергән. Әйтерсең, монда беркайчан да, берни дә булмаган, туплар да гөрелдәмәгән, пулялар да сызгырмаган, атлар да, кешеләр дә батып калмаган. Шулай да ул тирәләргә без, батырларның мәңгелек йокыларын бүлдермәс өчен, сагаеп кына бардык та башларыбызны иеп тынып калдык.

Симферопольгә кереп Кырымның дәүләт архивында, Мәскәүдә «Гражданнар сугышы тарихы» редакциясендә күп кенә истәлекләр белән таныштым. Аларны безнең дивизиянең командирлары, комиссарлары һәм сугышчылары язган иде. Перекоп белән Сивашның географиясе, тарихы, алар турындагы легендалар да кирәк булып чыкты.

Менә язарга утырдым. Тик шул вакыт өстәл янында мин үзем генә түгел кебек хис итә башладым. Сугышның кыенлыкларын да,

---

* **Чаклак** — Сивашта туңмый, куермый торган баткак урын.

жинү шатлыкларын да бергә кичергән, бер сынык икмәкне икегә, өчкә бүлеп капкан, бер шинель ябынып йоклаган якташларым, дусларым, иптәшләрем бар иде бит. Без алар белән сугыштан чыгып торган көнпәрне, кичке тынлыкта Украина кызларының соклангыч моңлы җырларын тыңлый, авылда калган сөйгән ярларыбызга хатлар яза идек. Аларның кайберләрен миңа, фронтка барып җиткәнче, укырга-язарга өйрәтүне тапшырганнар иде. Бервакыт политрук дәшеп алды да:

— Сез укытучы булгансыз икән. Белэсез бит, без — революция солдатлары, безгә надан булырга ярамый,— диде.

Шул көннән башлап, бераз гына туктап торган арада, нинди дә булса берәр сарайда яисә су буенда мин үземнең «шәкертләремне» хәреф танырга, иҗекне иҗеккә кушып сүзләр ясарга, сүзләрдән җөмләләр оештырырга өйрәтә башладым. «Шәкертләрем» арасында үз гомерендә күпне күргән, барлык сугышларны узган сакаллы абзыйлар да байтак иде. Менә алар ничә еллар буе бары винтовка белән граната гына тоткан дәү куллары белән кеп-кечкенә хәрефләрне тырыша-тырыша кәгазьгә төшерергә азапланалар. Берәр нәтиҗә килеп чыкса, балаларча куаналар. Миңа моның дулкынландыргыч тирән бер мәгънәсе бар кебек тоела. Сугыш кырында рәхим-шәфкатьне белмәгән шушы кырыс күңелле аяусыз солдат язу-сызу тирәсендә үзенең чын кешелек асылына кайта түгелме соң?

Кызганычка каршы, минем якташ, иптәшләремнең, таныш-белеш, дусларымның күбесенә туган-үскән илләренә әйләнеп кайту насыйп булмады. Алар әйтәсе сүзләрен, җырлыйсы җырларын ярты сүздә бүлдереп, Кырым капкасы төбендә ятып калдылар. Инде мин исән калып китап язарга тәвәккәлләгән икәнмен, ул иптәшләрем исеменнән дә нидер әйтергә, аларның ярты юлда бүленеп калган уйхисләрен дә укучыга җиткерергә тиеш түгелмени? Сугышчан иптәшләремнең кадерле ядкаре сүзсез-өнсез генә миннән шуны көтәдер кебек тоелды.

Кызыл Армия дивизияләренең Сиваш баткаклыгын кичеп Кырымга бәреп керүе, кыю стратегик вакыйга буларак, Совет дәүләтенең тарихына алтын хәрефләр белән язылды. Шул сәбәпле миңа ул вакыйгаларны язганда бик игътибарлы булырга кирәк иде. Кайбер сугыш операцияләрен көненә генә түгел, сәгатенә кадәр тормышның нәкъ үзендә булганча язарга тырыштым. Фронт командующие Фрунзе безнең дивизиягә нәкъ китапта язылганча килеп чыкты. Безнең дивизиябез Сивашка нәкъ шулай караңгы төшкәч аяк басты. Акларның Юшуньдагы иң соңгы позицияләренә без 1920 елның нәкъ 11 нче ноябренда көн урталарында бәреп кердек.

Шулай да бу әле сугыш вакыйгалары, фотога төшергән кебек, ничек булса шулай, һич үзгәртмичә язылган икән дигән сүз түгел. Әдәби әсәр язганда әдәбият кануннары белән эш итела. Моны нинди мисалда җиңелрәк аңлатып булыр икән? Мәсәлән, кинода язгы ташуның котырынып агуын күрсәтергә кирәк булды, ди. Моның өчен елганың ничек ташуын башланган җиреннән тамагына кадәр лентага төшереп алуның һич тә кирәге юк. Бәлки аеруча ашкынып, котырынып аккан берәр урынын җентекләбрәк күрсәтү дә бик җитә.

Сиваш белән Перекоп тирәсендәге сугышлар җәй көне үк башланып киткән иде. Мин исә ул сугышларның фәкать берничә көнен генә күрсәтергә кирәк таптым, иң соңгы, хәлиткеч көннәрен генә.

Аннан соң инде ярты гасырдан артык вакыт узды. Шундый батырлыклар күрсәткән Сиваш дивизиясе исә яшәвен дәвам итә,

яшь солдатлар исәбенә һаман яшәрә генә бара. Бу данлы дивизия Бөек Ватан сугышында да шулай батыр сугышкан, күп шәһәрләр алган, биш орден белән бүләкләнгән. 1918 елда Идел буендагы Инза шәһәрендә оешканлыктан, ул башта Инза дивизиясе дип исемләнә иде. Хәзер инде сугыштагы батырлыклары өчен «Инза, Сиваш, Штеттин» дивизиясе дип атала.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте сугыш ветераннарын һәрвакыт кайгыртып тора, игътибар үзәгендә тота. Сиваш сугышларында катнашуымны, шул хакта әдәби әсәр язуымны искә алып, хөкүмәт мине сугышчан Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләде.

Дивизиябезнең ярты гасырлык юбилее, шулай ук Курск дугасында немец фашистларын җиңүгә 30 ел тулу уңае белән сугыш ветераннарын кунакка дәштеләр. Җәйге көннең матур иртәсендә Поныри станциясенә барып төштем. Вокзал каршында күкрәкләре орденнар белән тулган офицерлар, Советлар Союзы Геройлары, солдатлар, гади киемдәге иптәшләр төркеме ветераннарны каршы алырга чыккан иде. Бу минутларда ниләр кичерүем, ничек дулкынлануым шәт аңлашылса кирәк. Шушы каршы алучылар арасында моннан илле өч ел элгәре минем белән бергә Сивашта утны-суны кичкән карт сугышчылар да булуы мөмкин бит! Әгәр дә мин шуларның берсен генә булса да очрату бәхетенә ирешсәм?

Бәхеткә каршы, бар иде алар, бар иде минем сугышчан кордашларым! Өч кенә бөртек калган булсак та, шатлыгыбыз тау кадәр булды. Без, үзебез өчен дә, якты киләчәк өчен авыр көрәштә һәлак булган иптәшләребез өчен дә, бер рота солдаты кадәр шаулап, кочаклашып күрештек.

1974 *Гомәр Бәширов*

I

Кинәт җир тетри һәм гүли башлады, пулеметтан аткан сыман, нидер өзлексез шытырдап торды. Шәмси, дер-дер калтыранып, торып утырды. Таң алды яктылыгында якындагы олы юлдан бере артыннан бере, дөбердәп, шаулап, зур кара атлар җигелгән дистәдән артык тачанка, алар артыннан томырылып чапкан бер эскадрон чамасы атлы үтеп бара икән.

Шәмси кабаланып, йөрәге сикергән хәлдә, винтовкасына үрелде. Монда! Үзендә! Бәхетенә каршы, винтовкасы үзе яткан ызан төбендә иде... Атлылар шулкадәр ашыгалар икән, шул арада ерагаеп күренмәс үк булдылар. Кемнәр булды икән? Безнекеләрме, әллә Махно отрядымы? Ул эсәрләнүдән сикереп тора язды. Тәгаен Махно! Ничә тапкыр күргәне бар: һәйбәт тачанкалар, берсеннән-берсе шәп кара атлар. Дала юлыннан кара афәт булып, өермәдәй тизлек белән котырынып чабалар. Артларыннан тузанлы койрык кына суэылып кала торган иде.

Шәмси, күзләрен угалап, як-ягына каранды. Ул юлдан читтәрәк тирән бер ызанга кереп ауган иде. Һе! Шәп, бик шәп! Соң шунда махночылар күрсә, я аклар-

ның разведкасы юлыкса?! Кинәт аның күз алдына каракүл папахасын бераз кырын салган, чалара башлаган калын кашларын җимергән, кырыс табигатьле, каты куллы рота командиры килеп басты:

— Һм! Солдат, имеш, сугышчы! Һм! Революция җимешләрен саклаучы!..

Шәмси, гүя чыннан да ротный каршында басып торган кебек, уңайсызланудан иңбашларын селкеткәләп, кашларын җыерып куйды.

Хәер, монда булмаса, кайда да булса алдарак барыбер егылмыйча түзә алмаган булыр иде. Аны санитарлар курсына җибәргәннәр иде. Ун көн укыганнан соң, кичә курсны ябып аларны үз полкларына кире озаттылар. Нигә? — дип сораганнар иде, кайткач белерсез, диделәр. Болар шат иде. Кем белә, бәлки моны сугыш бетүгә юрарга кирәктер? Боларны озатканда аңа полкны Сивашка таба чыгып китте, дип әйткәннәр, юлын да өйрәткәннәр иде. Шәмси әллә илле чакрым, әллә артык та куды. Полк дигәнең юк та юк. Әллә бик кызу баралар шунда, әллә икенче яккарак борылдылар. Көн буе куды, аннары төннең-төн буе килде. Һаман юк! Инде тәмам эштән чыгып арыганнан соң, аяклары бөтенләй атламый ук башлагач, ул шушы ызанда ял итмәкче булган иде... Бераз гына, ярты гына сәгать... Әнә хәзер яктырып килә инде.

Өелеп-өзелеп ашыйсы килә иде. Шәмси, нидер табуны өмет итеп, яшел капчыгын капшарга тотынды. Менә котелок, әнә кружка, берничә обойма патрон... Башка берни дә юк иде. Әйе, менә хәзер генә исенә төште: шайтан алгырысы, икмәгенең актык сыныгын кичә ашап бетергән иде бит. Ул күңелсезләнде. Шулай да капчык почмагында аз гына икмәк валчыгы калган икән, аны, бер бөртеген дә калдырмыйча, учына аударды да теле белән генә ялмап алып чәйнәргә тотынды. Авыз эчләре бөреште, авызына әчкелтем су тулды, тешләр арасында тузан чытырдады. Тик ул валчык та бик аз иде шул...

Ул туңудан бөгелмәс булган салкын бармаклары белән сүтелә башлаган обмоткасын яңадан урады, ямьшәйгән, кояшта төсе уңган яшел фуражкасын төзәтте, пряжкасы аркага таба борылган брезент каешын рәтләде дә, капчыгын аркасына чөеп, йөгерә-атлый юлга чыкты.

Далада кояш чыгар вакыт җиткән иде. Әнә офыктагы болытларның түбәнге чите, ерактагы янгын шәү-

ләсен хәтерләтеп, алсулана башлады, аннары ул юка гына булып дала өстенә дә җәелде. Менә бераздан шыксыз дәү булып, бөтен дөньяны кызартып, кояш үзе күренде. Ул, йокысы туймагандай авырсынып, теләр-теләмәс кенә чыгып килә иде. Шулай да аның чырае күтәрелгән саен яктыра бара, әле бөтенләй җылытмаса да, төн буе калтыранып чыкканнан соң аның күренүе генә дә күңелне күтәреп җибәрә иде.

Кояш күренү белән, дала терелә башлады. Кипкән куралар арасында нидер елтырап китте. Кайдадыр кошлар чыелдаганы ишетелде. Юл буендагы буразна чокырыннан куян атылып чыкты. Арт аякларына басып, озын колакларын алмаш-тилмәш уйнаклатып, «нишләп йөри монда берүзе» дигәндәй, кызыл күзләре белән Шәмсигә карап тора башлады. Шушы шәп-шәрә салкын далада кечкенә генә булса да җан иясе бит. Шәмси туктап куянга ым какты:

— Әй, нихәл, кыек күз? Син дә туңасыңмы?— Аннары, нәрсәдер исенә төшеп, көлеп җибәрде.— Әй, истә дә юк, татарча белмисеңдер бит син...— дигән булды.— Һайт!— дип кычкырып җибәрде.

Куян, терт-терт сикергәләп, ашыкмыйча гына әремнәр арасына кереп китте.

Куе болытлар, кояш бераз күтәрелергә өлгергәнче, аны шундук камап алдылар. Аларның күк кырые буйлап сузылган зәңгәрсу буразналары арасыннан кояшның озынча сары сызыклары гына күренеп калды.

Арттан, кайры тунлы, колакчынлы Россия ягыннан, карга төренгән кырлар, урманнар өстеннән салмак кына салкын җил исә башлады. Ул анда-санда утырып калган көнбагыш сабакларын кыймылдаткалады, Шәмсинең юка шинеле аша үтеп аркасын чиркандырды. Егет, кулларын угалап, винтовкасын иңбашына җайлабрак элде дә тагын да кызурак атларга тотынды.

Алда һаман авыл-фәлән юк, берән-сәрән узучы атлы я җәяүле сугышчылардан башка берни дә очрамый иде. Тирә-як һаман шул шәп-шәрә дала. Кибеп корышкан кылган, тузанлы соры юл. Шушы Врангель фронтына килгәннән соң Шәмсиләр Тавриянең бу очсыз-кырыйсыз тигез басуларын ничә тапкыр гына узмадылар! Аркылыга да, буйга да. Көндез дә, төнлә дә. Тәүлегенә алтмышар-җитмешәр чакрым. Һаман җәяү дә җәяү. Барып кына җитәләр — тагын чыгып китәргә.

Шулай да бар иде бу кырларның сокландыргыч чаклары! Әле күптән түгел генә, берәр ай гына элек. Бер ягында — үз авырлыгына үзе сыгылып торган табак хәтле көнбагыш башлары. Икенче ягында — күз күреме җитмәслек еракларга сузылган карбыз басуы. Нинди генә карбыз әле: пычак тимәс борын шытырдап ярылып китә, борыныңа хуш исе килеп бәрелә, авызың тисә, аерыла алмыйсың. Кайчагында шул көнбагышлар арасыннан көнбагыш сабагына охшаган нечкә билле, Таврия күге төсле зәңгәр күзле украинкалар елмаеп кала торган иде... Зәңгәр күзләр ничектер уңа барды, үзгәрде, хәзер инде Шәмсигә әллә кайдан, бик ерактан моңаеп, кара кашлы зур коңгырт күзләр кыюсыз гына карап тора иде. Егетнең йөрәге сулкылдап куйды, бер үк вакытта бик моңсу да, рәхәт тә булып китте. Оялып башын игән килеш кайнар кулларын сузган иде бит. Аннары колак төбендә чулпылары чылтырап китте, битенә кайнар сулышы бәрелеп калды, пышылдап әйткән сүзләре ишетелде: «Мине дисәң, мине сөйсәң, үзәгемне өзмә, хатлар яз!..»

Егет, үзеннән-үзе дәртләнеп, кызурак атлый башлады. Әйтерсең, аны озаткан кичтәге шикелле зарыгып Нәсимәсе көтеп тора.

Тик өздереп искән салкын җил аны яңадан хәзерге хәленә кайтарды.

Шәмси, як-ягына карангалап, офтанып куйды. Әйе, әле кайчан гына. Ул чагында муллык бөркеп, кайнап, хуш исләр аңкытып торган чәчәкле, җанлы иген кыры хәзер корыган, кипкән, шыксызланган иде. Әйтерсең, сугыш уты, дары сөреме шулай бөтенесен көйдереп узган.

Алга карыйсың — борылмый-сарылмыйча туп-туры офыкка барып тоташа торган шәп-шәрә киң юл. Ник бер генә җан иясе булсын да, ник ичмасам бер генә агач заты, бер генә авыл күренсен, Казан артындагы шикелле ник рәхәтләнеп берәр болын буйлап барасы, я ташларга баса-баса инеш чыгасы булсын.

Уңга карыйсың — күз тутырып карарлык дип әйтмисең дә инде,— ичмаса, бер генә калкуы да, бер генә куагы да булмаган тип-тигез соры дала. Казан тирәсендәге шикелле яшел урманнар монда сагынып карар өчен генә дә юк.

Сулга карыйсың — бик ерактагы зәңгәрсу офыкка, күк читендәге туңудан җыерчыкланып, сырланып каткан

соры болытларга барып тоташкан шул ук кырыс чырайлы салкын дала. Бөтен тирә-як тип-тигез, төп-төз, хәрәкәтсез. Тик ара-тирә юл буендагы корыган әремнәр селкенгәли дә, әле тегендә, әле монда үзенә хас бер тавыш белән кыштырдап юл аркылы давыл үләненең зур йомгаклары тәгәрәп узгалый. Аннары тагын шул ук тынлык.

Егеткә күңелсез булып китте. Ул барды-барды да, гүя үзенең ничек болай ялгыз калуына гаҗәпләнгәндәй, алдына-артына, як-ягына карады. Юлдан тузан туздырып килүче әллә кайдагы атлыларны искә алмаганда, якын-тирәдә бер җан иясе дә, узгынчы-фәлән дә юк иде.

Әйе, ул хәзер ялгыз, ул әллә кайларда, аның туган яклары бик ерак калган иде инде. Ерак, чакрым исәбенә дә тиз генә чыгарлык түгел, санарга тотынсаң, меңнәрдән узып китәр.

Шәмси, бара торган көенә башын чайкый-чайкый, күңеленә килгән җырны көйләп җибәрде:

Йөгереп китәрдәй булам,
Кайтып житәрдәй булам,
Кичке салкын жилләрдә
Туган-үскән илләргә шул,
Туган-үскән илләргә.

Их! Ничек итептер менә, күз ачып йомган арада, авылга кайтырга иде дә, Киек тавы башыннан торып, җырлап җибәрергә иде. Судан кайтучы кызлар бер аягын баскач, икенчесен атларга онытып, яшь киленнәр сыер савуларын бүлеп, карт-корылар кулларын колакларына куеп рәхәтләнеп тыңласыннар иде. Ишетсеннәр иде дә, моңланып, җырлаучының тавышын танып, хәйран калсыннар иде. «Әнекәем, Шәмси кайткан! Шәмси тавышы бит бу!»— дип Нәсимә йөгереп чыксын иде.

Шунда ничектер үзеннән-үзе анасы күз алдына килде. Арча станциясендә, Шәмсине озаткандагыча... Күзләрен ала алмыйча карап торды-торды да поезд кузгалуга кинәт тилпенеп китте, гүя төтен таулары бөркеп кузгалган паровозны да, яшьләр белән тулган кызыл вагоннарны да ниндидер кодрәт белән туктатырга, җибәрмәскә җыенгандай, кулларын сузып поезд артыннан ташланды...

Шәмси коңгырт күзләрен кысып бераз моңаеп алды. Әни, әни!.. Ул бит Шәмсинең атасын да әнә шул ук станциядән, шулай ук елый-елый герман сугышына озатып калган. Озатуын озаткан, әмма каршы алырга туры

килмэгэн... Ана күнеле нилэр генэ кичермэгэндер?!. Һай, эни, эни! Ичмаса, берэр җылы сүз әйттеме ул аңа, юаттымы ичмаса!

Әйе, менә хәзер кайтып төшәсе иде дә ана кешене дә куандырасы, бүтәннәрне дә шаккатырасы иде.

Өстә күн тужурка, бутылкалы кызыл чалбар, аякта шпорлы шәп итек, башта ротныйныкы төсле каракүл соры папаха булсын иде. Унсигезенче елны аның авылдашлары нәкъ шулай киенеп кайтканнар иде бит. Азин дивизиясеннән иде бугай...

Әйе, кайтып төшәсе иде дә әни каршысына «зыңк» иттереп килеп басасы иде:

— Әни! Мин бит бу! Шәмси! Күрдеңме?

Кәефе килүдән аның үзеннән-үзе авызы ерылып китте. Тик шунда ул ботинка олтанының шапылдавына гаҗәпсенеп бөкрәеп карарга мәҗбүр булды: олтанны беркетеп бәйләгән телефон чыбыгы, күп йөри торгач, өзелгән икән дә олтан бөтенләй төшеп кала язган...

Аннары ямаулы тезләренә күзе төште, шинеленең терсәгендәге тишеккә бармагын тыгып карады, авыр сулап, ботинка олтанын бәйләргә тотынды. Бераздан, кулын селтәп, йөгерә-атлый тагын китте. Беравык баргач, үзеннән-үзе көлеп куйды:

— Салам торхан! Нәрсәләр турында хыяллана бит... Булмаганны!..

Шулай бик озак барганнан соң, алда, бик еракта, кыр өстеннән аз гына калкып, соры карамчык кына булып, бер авыл күренә башлады. Бәлки аның полкы шундадыр? Хәер, белмәссең. Сугыш тирәсендәге авылларда моңарчы власть перчаткадай алмашынып торды. Көндезен авыл өстендә, чуар юрган төсле зәңгәрле, сарылы әләм эленеп торса, төнлә аны Махноның баш сөяге төшерелгән шомлы кара әләме алмаштыра. Ул да түгел, тагын бераздан аның урынында һәммәсен дә җиңгән урак-чүкечле кызыл әләм җилферди иде. Сугыш башланганнан бирле бу тирәдә гел шулай. Ә монда сугыш башлануына инде аз дигәндә өч ел икән. Политрук Исмаев шулай ди. Кемнәр генә борынын тыгып карамаган бу бай, матур илгә! Украина контрлары, немец буржуйлары, поляк паннары, патша генераллары, Махно бандитлары... бере артыннан икенчесе килеп, Украина халкын канга батырганнар, талап киткәннәр.

Берсе, Врангель дигәне, әнә хәзер дә әле бөтен көче белән сугышып халыкны кырдырып ята бит.

Врангель — кара барон, кара йөрәкле явыз барон. Врангель диюгә, нигәдер, кара тут тәнле, ач яңаклы, карчыгадай кәкре борынлы, чыелдык тавышлы берәү күз алдына килә. Күпме кан койды, күпме авылларны яндырды!

Кайту дигәннән, политрук Исмаев әнә нәрсә ди бит:

— Безнең кайтыр юлларыбыз Врангельнең кабере өстеннән узачак,— дип җибәрә.— Нигә дисезме? Безгә Врангельне бетермичә кайтырга ярамый. Сугыш бик туйдырды инде, туганнар, ай-һай туйдырды! Алай гынамы! Никадәр халыкның башына җитте, илне бөлдерде, халыкны ач-ялангач калдырды. Врангель — афәт, Врангель — сугыш ул. Врангельне бетерсәк, бу инде сугыш бөтенләйгә бетте дигән сүз була. Менә бит эшләр ничек! Сугыш беттеме, тыныч көннәр башланачак. Эшче үзенең заводына кайтыр, крестьян — сукасына...

Әйе. Политрук Исмаев шулай ди. Дөрес әйткәнгә охшый бит?! Дөрес...

Алгы якта кинәт бик каты гөрселдәп куйды. Шәмси күтәрелеп карады. Юк, ерактагы авыл өстендә дә, аның як-ягында да төтен-фәлән күренми иде. Шулай да туп тавышы, гүя таш-таулар берсе өстенә берсе җимерелгәндәй, өзлексез гүли, үкерә башлады.

Шәмсигә нигәдер ул якта тәгаен безнекеләр ата, хәтта аның үз полкының артиллериясе дошманны шулай дөмбәсли кебек тоела иде. Шунлыктан бу дәһшәтле гөрселдәүләр аны куркытмый, бәлки ничектер дулкынландыра, хәтта ашкындыра башлады. Шундый кайнар бәрелеш, каты сугыш вакытында үз полкында иптәшләрең янында буласы килә бит.

Ләкин полкның кайда булуын ничек белергә, кемнән сорашырга?

Бара торгач, каршы яктан ике яклы утлык сыман озын челтәрле арбага зур-зур көрән үгезләр җиккән бер украинлы килеп чыкты. Мөгез аралары берәр колачка сузылган дәү үгезләр йокымсырап кына атлыйлар, крестьян агай үзе кыска кайры тунына төренеп, тире тышлы йонлач бүреген басып кигән дә — цоб, цобе!— дигәләп, үгезләрен кугандай итә. Бу агай олы юлдагы авылдан түгел икән, солдатлар да очратмаган.

— Агайман?— Украинлы, йонлач бүреген алга этеп бераз муен тамырын кашып торганнан соң, Шәмси сораган авылның исемен тагын бер кабатлады.— Агай-

ман! Бик ерак булмас, бәлки унбишкә бетәдер, бәлки егерме чакрымга сузыладыр. Тильки с һаком...

Шәмси көлде дә кулын селтәп китеп барды. Украинлы чакрымга гак сүзен кушып әйттеме, бетте инде, тиз генә барып җитүеңне өмет тә итмә!

Тик, бәхетенә каршы, бу юлы аңа Украинаның исәпсез-сансыз гакларын адымлап санарга туры килмәде.

II

Шәмси үгез җиккән агайдан ерак та китәргә өлгермәде аны бик шәп чабып килүче пар ат җигелгән тачанка куып җитте. Ярсыган атлар гыжлап тояк тавышларын яңгыратып узып китте дигәндә генә, аңа исеме белән дәштеләр:

— Әй, Гайфуллин!

Борылып караса, пулеметчы Митричев белән взвод командиры Гриша Данилов икән. Шәмсинең авызы ерылып китте:

— Һа! Менә бәхет! Ничек болай? Сез кайдан?

Каеш дилбегәне ике кулына урап ат башына утырган Митричев, ярсып җиткән атларны көч-хәл белән тыя төшеп:

— Тиз бул!—дип кычкырды.— Күп шапылдап торсаң, җәяү генә барырсың!..

Шәмсинең сикереп менүе булды, атлар тагын элеп алып чаба башладылар.

Данилов, артка таба каратып утырткан пулеметның шәрә көпшәсе аша Шәмсигә иелеп, алгы якка ымлады:

— Полкны бик тиз куып җитәргә әйттеләр. Ишетәсеңме?

Ул, саламдай сары кашларын җыерып, туплар гөрселдәгәнне тыңлады да пулемет көпшәсенә учы белән сугып алды.

— «Максим»ны төзәттереп алдык бит, менә кияү егетен туйга өлгертергә дип чабабыз.

Кичә госпитальдә дә шушы арада бик хәтәр хәлләр буласы сизелеп калган иде. Нindидер зур сугыш! Әмма ул шушы кадәр тиз башланыр дип үк уйламаган иде әле.

— Ә, шулай укмыни?—дип куйды.— Бүген үкмени?

Данилов башы белән ымлады. Әйе, шулай, бүген үк.

Ат җиленнән Даниловның шлем колаклары җилферди, шлем маңгаендагы ал постаудан тегелгән дәү кызыл

йолдыз астында зәңгәрсу күзләре бер йомыла, бер ачыла, киңчә сипкелле битен, алгарак чыгып торган куш ияген бөтенләе белән диярлек кыска җиз сакал басып килә. Шәмси әле дә хәтерли: Данилов аларның ротасына беренче тапкыр килеп күренгәндә аның өстендә һәйбәт күн пинжәк, башында да кызыл йолдызлы кара күн фуражка иде. Аны шахтер иптәшләре Донбасстан фронтка коммунистлар отряды җибәргәндә шулай шәп итеп киендергәннәр дип сөйләделәр. Хәзер исә аның ул киемнәре тузып беткән, башкаларныкы кебек үк аның аягында да чүпрәк обмоткалы иске ботинка, өстендә гади соры шинель иде. Даниловның пулемет көпшәсе өстенә таянган кулында җиз төкләр арасында, дары чәчрәгән төсле, бөрчек-бөрчек кара тарылар күренә. Забойда озак эшләгән шахтерлар җир астыннан шулай тамгаланып чыгалар ди бит.

Данилов шинель кесәсеннән зәңгәр баулы кызыл янчык чыгарды. Кыска юан бармаклары белән янчыгының төбен капшап карады да, җиз кашларын җыерып, аны яңадан кесәсенә салып куйды. Шәмси күреп тора: Даниловның тартасы килә. Әмма ул бүтәннәр шикелле әрсез түгел. Шәмсидә, үзе тартмаганлыктан, тәмәке өзелмәвен белсә дә, ул бервакытта да үзе сорап алмый иде. Төптән юан чыккан базык гәүдәле, аю кебек алпан-тилпән атлап йөрүче бу кешенең сугыш вакытында каты куллы булып та, әнә шундый вакытларда бик тыйнак, кирәгеннән артык әдәп саклаучан кешегә әверелүе Шәмсигә бик ошый, ул аны бигрәк тә шул яклары өчен ихтирам итә иде.

Шәмси кулында бер пачка махорка күргәч, Даниловның йөзе берьюлы яктырып китте:

— О, менә байлык! Значит, көйрәтәбез?!

Ул хәзер ниндидер сары газета кәгазенә төргән юан тәмәкесен бик тәмләп суыра да аксыл зәңгәр күзләре белән, нидер күрергә теләгәндәй, бик озаклап, тыңлыйтыңлый, туплар улаган якка карап бара. Аннары уйланып утыра-утыра да тагын суырып куя. Нигә болай авыр итеп уйлый икән командир? Алда барган сугышның авыр сулышын сизәме? Әллә көчебез җитәрме икән, юкмы икән дип борчыламы?..

Шәмси тагын да җентекләбрәк карады. Икесенең дә чырае бик җитди, икесендә дә бүтән чакта булмаган ниндидер бер кырыс сагаючанлык сизелеп тора. Шәмсигә хәзер алдагы гөрелте тагын да дәһшәтлерәк булып

ишетелде, атларның шулай ашкынып чабулары да бушка гына түгел кебек тоела башлады. Сугыш, сугыш!

Аларның монда кадәр дә сугышта булганы бар иде инде. Бер генә тапкыр да түгел. Врангель гаскәрләре 1920 елның җәендә Кырымнан Украинаның Таврия даласына бәреп чыкканнан соң бөтен көче белән Донбасска бәреп керергә дип ыргылганда, алар полкының да канга батканчы, ярты сугышчысы кырылып беткәнче сугышкан чаклары булгалады. Ай-һай, кыен булды. Әмма бу сугыш башкачарак, тагын да рәхимсезрәк буласы, диләр. Офыкның әнә шулай буйдан буйга гөрселдәп торуы тикмәгә генә түгел бит. Бу сугышның иң соңгы сугыш булып барон Врангельнең башына җитәргә тиешлеге дә барысын да куандыра, һәр сугышчы аны күптән үк көтә, Врангель армиясенең кырылып бетәчәгенә ышанып, ашкынып, түземсезләнеп көтә иде. Уен эш түгел бит! Врангельнең исән калган барлык офицер полклары, ач бүре шикелле, үләрен белмичә ташланачак, аның йөзләрчә туплары, меңнәрчә пулеметлары берьюлы үкерә башлаячак. Ә безнең монда патроннар да саегып бара, пулеметлар да бик аз. Авыр артиллерияне әйткән дә юк, анысы Таганрогта ук тоткарланып калган. Политрук Исмаев шулай ди.

Шулар турында уйланамы икән әллә командир? Аның тәмәке төтене белән бергә нинди борчулары һавага оча? Сорарга иде командирдан. Ләкин мондый нечкә әйберләр турында вәземләп сөйләшә торган урысча сүзләрне кайдан алырга? Шунлыктан дөньяда һәммә нәрсә белән дә кызыксынучан бу яшь сугышчы, көлемсерәүчән коңгырт күзләрен елтыратып, өлкән иптәшләренең әле берсенә, әле икенчесенә күз сала, үзенчә нидер чамалый, нидер абайлый, үзенчә нидер төшенгәндәй була, кирәгенкирәкмәсен әле шытып кына килә торган бала мыегына чорнап калгандай итә иде.

Шәмсигә, алгы якта орудиеләр гөрселдәвс көчәйгән саен, Митричев атларны да ныграк куа кебек күренә башлады. Тәгәрмәчләр тигән җиргә тия, тимәгән җиргә — юк, тачанка орудиеләрнең туң туфракка сытып кергән киң эзләренә бер төшеп, бер менеп үрле-кырлы сикерә.

Митричев, чабыш ат өстендәге сыман, бөтен гәүдәсе белән алга йөгенгән, аның шинель итәкләре, зур кош канатлары сыман, чабулары белән лып-лып бәрә... Ат башында утыруы, бу ике турыны шулай чаптыруы белән

ул шулкадәр мавыккан, хәтта хәзер шушы атлардан башка беркемне дә күрми, берни дә белергә теләми, каеш дилбегәсен атларының әле берсенең, әле икенчесенең янтауларында шапылдатып, чаптыра бирә. Шунда ук көр, яңгыравыклы тавышы белән, чабыштагыдай дәртләнеп, әллә сүгенә, әллә мактый, ниндидер аңлашылмаган сүзләр кычкырып җибәрә.

— Әйй, сырмолотный!.. Крой-й-й!

Атларның тоякларыннан тачанкага балчык йомарламнары атыла, кайчак ялт итеп очкыннар чәчрәп китә. Авызларыннан ак күбекләр өзелеп кала.

— Әй!..

Митричев бу полкка килгәнче Буденныйның атлы армиясендә хезмәт иткән, диләр. Аннан җәяүлегә күчерелүенең сәбәбе турында Митричев үзе сөйләнергә яратмый, ул турыда озын колактан гына ишетелә: Митричев анда ниндидер бик зәһәр бер чабыш аты белән акларның штабы янына ук барып чыккан да граната белән бөтенесен җимерткәч, аз гына үзе дә эләкми калган. Әмма аның бу башсызлыгы аркасында ниндидер сугыш сере ачыла язган, имеш. Атлы гаскәрне оныта алмавын Митричев үзе дә яшерми иде. Әйтерсең аңа, карт сугышчы Вәлитов әйтмешли, ат җене кагылган. Җәяүлеләр арасында винтовкалар, көрәкләр, яшел капчыклар асып, арып-талып атлар-атламас барганда, кырыйдан камчыларын уйнатып атлылар уза калса, Митричев үзен кая куярга белми, алар артыннан күзен ала алмыйча юксынып, моңаеп карап кала да соңыннан бик озак башын иеп сөйләшми йөри, әгәр инде бик артып китсә, әйләндереп, болгандырып, солдатча бик яман сүгенергә тотына торган иде.

Шәмсине бу егетнең чаялыгы белән батырлыгы кызыктыра иде. Аның фуражка астыннан бөселеп чыгып торган кара бөдрәләре ук «мин — мин инде ул, сез түгел!..» дигән сыман масаеп торалар бит.

Җәяүле чакта барып җитә алмастай ерак булып күренгән әлеге Украина авылы үзенең ап-ак хаталары белән күзгә күренеп якыная барды. Менә йорт саен диярлек сиртмәле коелары, саламнан я таштан өелгән киң коймалары калкып чыкты, менә ишек алларында ниндидер кара киенгән кешеләр күренә башлады. Озак та үтмәде, тачанка җилдәй тизлек белән авылның эченә ук килеп керде.

Атлар кырынлап чаптылар-чаптылар да, Митричевны санламыйча, авыл уртасындагы калай түбәле бер йорт каршына, сиртмәле кое янына килеп туктадылар. Митричев козырегын артка каратып кигән яшькелт фуражкасын сул колагына этәреп куйды да ат башыннан сикереп төште.

— Алайса бераз тамак чылатып алабызмыни?..

Митричев коедан бер генә чиләк су чыгарып өлгерде, ишек алдыннан бере артыннан бере иңнәренә кара бурка салган яисә кара шинель, кара папаха кигән, кылыч таккан мыеклы кешеләр чыга башлады. Алар, явыз елмаеп, акрын-акрын тачанка янына җыелдылар, боларның иске шинельләрен, обмоткаларын бер-берсенә күрсәтеп мыскыллап көлешергә тотындылар. Кайдан болар, бу нинди команда? Күтәрелеп карауга Шәмсинең эче «жу» итеп китте. Капка түбәсендә кара җәймәгә ап-ак баш сөяге белән шәрә кул сөякләренең сурәтен чалыштырып ясаган Махно эләме эленеп тора!

Кое янына җыела башлаган төркем эченнән берсе сүгенергә тотынды.

— Әй, хәерче команда! Пычратма коены!..

Коңгырт мыеклары иягенә асылынып төшкән базык гәүдәле берсе Митричевның янына ук килде, аның обмоткаларына, ямьшәйгән фуражкасына күрсәтеп көлә башлады:

— Егетләр, күреп калыгыз! Большевиклар яңа фасон чыгарганнар! Башка — чүпрәк, балтырга — чүпрәк, ботинкалары олтансыз! Ха-ха-ха!

Аның янындагы ак чырайлысы, кара бурка бөркәнгән озын буйлысы, тегесенә каршы әйткән булды:

— Нәрсә син кешенең дәрәҗәсен төшерәсең, пычтергән үгез? Монысы комиссарларыдыр әле аларның! Большевик, жид! Күрмисеңме, чәчләре нинди бөдрә, күзләре нинди елтырый!

— Нишләп алай булсын?! Сөйләмә булмаганны! Чегәндер ул!

Митричев, ямьшәеп, изелеп беткән фуражкасын куе кара бөдрәсенең бер ягына элеп куйган хәлдә, тегеләргә һич игътибар итмәгәнгә салынып, атларны эчерүдә дәвам итә. Ләкин ярсудан аның иреннәре дерелди, ул, түземсезләнеп, әледән-әле пулеметка һәм Даниловка карап алгалый иде.

Теге ак чырайлысы, ике кулы белән бөеренә таянган килеш, һаман мыскыллавында дәвам итте:

— Нәрсә сез! Аларның бит комиссарлары гына итек кия. Боларына чабата тиешле. Кызылларның кавалериясе озакламыйча сыерга атланып безне куарга чыгачак икән. Боларның комиссары пегашкасын тәүлегенә примерно икешәр чакрымнан куса, безнең Гуляй-Полега киләсе елның нәкъ пасхасына барып җитәчәк...

Ул да түгел, исерекләрчә бөгелә-сыгыла хахылдап көлүче бу төркем арасында кайсыдыр наганнан атып җибәрде. Атлар, Митричевны бер якка кагып, кинәт кенә борылдылар да урам уртасына бәреп чыктылар. Шуны гына көткәндәй, акырышып, берсеннән-берсе яман хахылдашып, махночылар төркеме тачанка артыннан ташланды.

— Ура! Тез буыннары калтырый!

— Хлопцы! Чалбарларын салдырып карагыз! Анданиләр бар икән?

— Ха, ха, ха!

— Тотыгыз, тот!

— Әй, куян йөрәкләр, туктагыз!

Ул арада җитезрәкләре тачанкага якынаеп ук киләләр, кайсысы кылычын чыгарып маташа, кайсылары наганнарын тартып алалар, баш очларында кыска карабиннар айкала башлады.

— Тот большевикларны, җибәрмә!

Нишләргә? Пулеметтан кырып ташларгамы, әллә атмыйча гына чыгып ычкыну ягын карарргамы?

Данилов тешен кысып бер пулеметка, бер бандага карап икеләнеп калганда, Шәмси ничектер, шулай кирәген күңеле сизенеп булса кирәк, атларның башына барып асылынды, ул да түгел, Митричев яшен тизлеге белән пулемет янына менеп ябышты. Шул сулышта ук Данилов аны читкә этәрде дә гайрәт һәм ачу белән йодрыгын айкап кычкырып та җибәрде:

— Тукта! Чиген!

Махночылар көтелмәгән бу кыюлыктан гаҗәпкә калып кинәт туктадылар, акайган күзләре белән «максим»ның үзләренә төбәлгән кара көпшәсенә текәлеп катып калдылар. Данилов, аларга аңнарына килергә вакыт бирмәстән, йомарлаган кулларын айкый-айкый тагын да гайрәтләнебрәк кычкырды:

— Әй, сезгә әйтәм! Чиген! Әгәр өчкә кадәр санаганчы капкага кереп югалмасагыз, ут ачам! Митричев! Хәзерлән! Бер!

Митричев, атып егачак иң беренче корбанын эзләгәндәй, зәһәрләнеп елтыраган күзләрен кыскан килеш, тешләрен шыкырдатып пулеметының көпшәсен уңнан сулга, аннары сулдан уңга боргалый башлады.

Махночылар бераз исләренә килмичәрәк тордылар, аннары төркем кинәт чайкалып китте, кайнаша, болганыша, кычкыра башладылар.

— Нәрсә бу! Әллә шул йолкыш куркытмакчы буламы? Безнеме? Хлопцы! Ни дип безгә пулемет төзи бу кацап! Ни карап торасыз?! Ташлан, бәреп төшер!

Ләкин шул вакыт Данилов, йомарланган кулы белән һаваны айкап, икенче мәртәбә кычкырып җибәрде:

— Ике!

Көчле дулкын килеп бәрелгәндәй, тегеләр кинәт артка чигенделәр. Башта ак чырайлы озын буйлысы кырынлатып капкага шыңкайды, аннары бүтәннәре, кайсы арты белән, кайсы кырын-кырын капка артына яшеренделәр.

Ул арада тачанка да кузгалып киткән, Шәмси, калтыранган куллары белән җирсенгән атларны тыя төшеп, ат башында бара, Данилов, Митричев янына тезләнгән килеш, капкадан күзен алмастан, кулы белән Шәмсигә ишарәли иде.

— Акрын, Гайфуллин, акрын, чаптырма! Без качмыйбыз, аңлыйсыңмы?! Без куркак түгел, юк!..

Тачанка авыл башына чыгып җитәрәк капкадан акрын-акрын гына чыгып килгән берничә кеше күренсә дә, алар инде куркыныч түгел, иң хәтәр вакыт узган иде.

Авылдан чыкканнан соң Данилов, шактый салкынча булуга карамастан, изүләрен чишеп җибәрде, бик авыр әйберне өстеннән ташлагандай, «уф!» дип куйды. Митричев ямьшәйгән фуражкасын тартып алып тезенә бәрде, аның күзләреннән усал очкыннар чәчрәде.

— Эх! Әрәм калды унбиш бандит! Командир! Әйт, пожалуста, нигә без ул сволочьларны шунда кырып ташламадык? Бөтен өеме белән, бөтен шайкасын берьюлы! Ә, нишләп? Йөрәк җитмәдеме?!

Данилов тәмәке төрергә дип әзерләгән газета кәгазен Шәмсигә сузды. Аннары бик тыныч кына итеп:

— Петрусь! Ахмак син,— диде.

— Менә сиңа мә? Бандитларны кырыйк дигән өченме?

— Әйе, нәкъ шуның өчен. Күрмәдеңмени? Бөтен авылны Махно отряды килеп баскан бит. Белмисеңмени,

аларга бит сылтау гына кирәк. Син бер генә патрон аткан булсаң, алар безне шунда ук тураклап ыргытачаклар иде.

Митричев, кара көдрәләре арасыннан мыскыллы күзләрен елтыратып, көлеп җибәрде:

— Әһә! Соң син туп-туры шулай диярләр. Билгеле... «цыпленок тоже хочет жить!» Күрә торып кемнең генә кәкрәясе килсен?! Бигрәк тә сугыш бетәр алдыннан, бигрәк тә синең. Атага бер генә ул да булгач... тегесе дә, монысы...

Шәмси бу көдрә егетнең кайвакыт шулай берни белән дә исәпләшмичә урынлы да, урынсыз да кирле-мырлы сөйләнеп иптәшләренең хәтерен калдыру гадәте барын белә иде. Әмма әле генә башларыннан узган вакыйгада командирны куркак дип мыскыл итүе Шәмсинең дә ачуын китерде.

— Нәрсә син, Петрусь, юкка кыланган буласың? Данилов булмаса, безне әллә кайчан чүплеккә чыгарып аткан булырлар иде инде.

— Менә-менә, икегез дә шуннан курыктыгыз шул сез! Чокырга чыгарып ату гына түгел, үлгәннән соң ник миңа ияр салып атланып йөрмиләр, анысына төкермим дә. Әмма күрә торып каршындагы бандитны исән калдыру — бу инде батырлык та түгел, солдатча да түгел. Харап икән, өч пешка...

Данилов кулын селтәде:

— Эш анда гынамыни, кирәкмәгәнгә яңа сугыш кабынып китә, скандал башланып китә иде бит.

— Ә син скандалсыз-нисез, бер дә атышмыйча, тәмле тел белән генә сугышмакчы идеңме? Бәлки мич башында гына ятып сугышсаң, тагын да уңайрак булыр иде. Ха, ха, ха!

Данилов борылып утырды да Митричевның башына чиертеп күрсәтте:

— Синең бу тартма эчендә акылмы, әллә әрбәме? Ничек син, кайнар баш, шуны гына төшенергә теләмисең? Бу сиңа 18 нче ел түгел, моны сиңа 1920 елгы регуляр армия, Кызыл Армия диләр! Бердән, пулеметлы өч сугышчы пешка гына түгел ул, зур көч! Шуның өстенә, Махно отряды Врангельгә каршы сугышырга сүз бирде. Сугышырмы, юкмы, ничек сугышыр, анысы икенче мәсьәлә. Әмма аннан да бигрәк без ата башлаган булсак, ул бандитлар безне үтергән булсалар, безнең полк моны шул килеш калдырыр иде дисеңмени?!

һе! Шулай булмыймы соң? Шул минутында ук бер батальонны монда җибәргән булырлар иде, иң аз дигәндә дә бер рота! — Данилов кулы белән ишарәләп тын калырга кушты. Туп тавышлары хәзер баягыдан да ачыграк ишетелә башлаган иде.— Ишетәсеңдер бит?! Врангельнең үкчәсенә баса-баса, менә чорнап алабыз, менә муенын борып ыргытабыз ди-ди көне-төне куып барганда, Махно белән бәйләнеп вакытны әрәм итү акыллы эшмени?!

Митричев төкереп куйды:

— Фу, кайдан җыелды безгә шушындый җыен акыллы кешеләр! Аңлыйсыңмы син, акыллы баш! Андый чакта минем әнә шул уңлап бандитны борыннарын канатып, кырып саласым килә. Ярыймы ул, ярамыймы, анысында минем эшем юк! Сугышның тәме дә шунда, кызыгы! Ә син миңа әллә нәрсәләр турында акыл сатасың. Бәлки скандал чыгуы шәбрәктер, бәлки ул бандитларны менә шушында өереп алып кырып ташларга кирәктер?!

Шәмси атларын җан-фәрманга чаптырган килеш боларга да борчылып караштыргалый иде. Ләкин Данилов кинә саклаучы кеше түгел икән, Митричевның кычкыруларына исе китмәстән, тәмәкесен суыргалап көлепкенә җавап бирде:

— Шуңа күрә сине, Петрусь туган, командир итмәгәннәр дә бит! Бераз акыл керә башлаганчы пулеметчы гына итеп калдырганнар...

III

Алда полкның чакрымнарга сузылган озын колоннасы күренүгә, Митричев дилбегәгә тагын үзе сузылды:

— Бир әле миңа!

Атларның өстендә дилбегә уйнатып, ачы тавыш белән тагын кычкырып җибәрде:

— Әй, сырмолотный!..

Атлар кыска койрыкларын тырпайтып, сөлектәй сузылган хәлдә суырылып алга ыргылдылар. Тачанка каты юлда, малайлар тартып йөгергән уенчык арбадай, үрле-кырлы сикерде.

Поход кухнясын уздылар. Бөкрәеп утырган кашеварның шинель якасыннан күгәргән борыны белән җилдән кызарып яшьләнгән күзләре күренеп калды; санитар арбасының зур итеп ясалган Кызыл Хач билгесе,

арба янынннан кулларын җиң эчләренә яшереп бөгелеп төшкән авырулар, аягы бозылган аксак сугышчылар күренде. Алардан алда, колоннаның башында баручы полк командирына хәтле сузылган батальоннар, роталар, взводлар җәяүли иде.

Юлны иңләп агылган соры шинель, уңган яшел фуражкалар, йонлач папахалар өстендә тонык кына елтырап штыклар урманы чайкала. Аркасына яшел капчыгын, иңенә винтовкасын асып, бил каешына сапер көрәген, иңенә хәситә итеп киндер патронташын элгән сугышчылар, арып башларын игән хәлдә, аякларын көчхәл белән атлыйлар. Алар шулкадәр арыганнар, колонна кырыеннан әле алга, әле артка чабып узучы кылтыйн кыяфәтле атлыларга түгел, хәтта Митричевның һайһулап, дөбердәп, шаулап узган тачанкасына да күтәрелеп караучы булмады.

Данилов башын чайкап Шәмсинең колагына кычкырды:

— Ай, ай! Бөтенләй эштән чыкканнар, аяк атлар хәлләре дә калмаган. Ярый әле хәзер үк сугышасы түгел!

Шәмси авыз ачып өлгергәнче, Митричев ялт борылып Даниловны тешләп алырга да өлгерде:

— Әһә! Димәк, без аклар килеп чыкмагае дип котыбыз гына чыгып торабыз... Ә, шулай булып чыгамы?

Митричев нигәдер бүген иртәдән бирле гел бәйләнә, барыннан да бигрәк Даниловка бәйләнә иде. Данилов сары кашларын җыерып ачудан төкереп куйды:

— Ташла әле, зинһар, бушка лыгырдавыңны! Күрмисеңмени? Бу хәлдә бит беренче бәрелештә үк полкның яртысы кырылып бетәчәк. Ике көн рәттән ял итмичә җәяү килә бит!

— Җәяүлене җәяү йөргән өчен кызгану солдатча түгел.

Данилов моңа каршы кулын гына селтәде.

Ротаның алдыннан баручы биек соргылт папахалы таза гәүдәле командир турысына килеп җитүгә, Митричев атларны туктатты. Рота командиры Пахомов боларның сәламенә җавап бирде дә иң элек пулеметны килеп карады. Аннары тачанкага аяклары бозылган ике сугышчыны утыртырга кушты.

Митричев гаҗәпләнгән кыяфәт белән:

— Ә пулеметның үз расчеты ничек? — дип сорады.

— Җәяү атлый... ләкин тачанка янында.

Ул арада полкның башыннан, ротадан ротага күчә-күчә команда ишетелде:

— Привал! *

Команда тавышы тынып та өлгермәде, колоннаны, әйтерсең, көчле җил бәреп аударды; беренче батальоннан башлап иң арттагысына кадәр барлык роталар бере артыннан бере сөрлегеп, юл кырыена егыла бардылар. Кайсы винтовкасын кочаклаган килеш ызанга ауды, аеруча эштән чыгып арыганнары, аркасыннан капчыгын да салып тормыйча, баскан җирендә үк сузылып ятты. Берничә минуттан бөтен тирә-як тынган, бөтен полк иң актык солдатына кадәр юл читенә авып беткән, тик көтүенең ничек урнашуын карап торучы көтүчеләрдәй, анда-санда кайбер командирлар гына аяк өсте күренә иде.

Шәмси белән Данилов үз взводлары туктаган урынга барып утырдылар. Данилов, як-ягына карана торгач, ызан кырыенда борынын шинель якасына яшереп йокымсырап яткан дусты Миша Борисовны күреп алды. Тегесе аркасыннан кагуга керфек арасыннан гына карап ымлады да тагын күзен йомды. Ул баш астына китаплар, газеталар тутырган брезент сумкасын салган, куеныннан тагын бер китапның почмагы күренеп тора. Монысы үзе укый торган китабыдыр инде. Аз гына буш вакыт булдымы — ул үз янына бер төркем сугышчыларны җыеп ала да я китап, я газета укырга тотына. Аның өстенә ул әле укый-яза белмәүче сугышчыларны русча да укыта. Данилов белән алар бик дус иде. Ул аңа яратып, якын итеп карап торды. Ягымлы егет, матур да. Озынча ак битле, мыек та әле яңа гына чыгарга җыена, иреннәре дә бик юка гына. Шинель якасы арасыннан Даниловка аның бите кызлар битенә охшаган сыман күренде. Әмма барыннан да бигрәк Борисов тагын әллә сөйкемлелеге, әллә яхшы күңелле булуы белән яраттыра иде. Данилов дустының яшел обмотка чорнаган балтырларын шинель итәге белән каплады.

— Әх, син, солдат, арыш камыры шикелле изелеп төшкәнсең. Сөйләшерлек кенә дә хәлең калмаган. Ичмасам, менә Гайфуллин белән исәнләш! Унбиш көннән бирле күргәнең юк бит...

---

* Привал — гаскәри бүлекләрнең юлда туктап ял итеп алу вакытлары.

Борисов, ирен читен елмайган сыман кыймылдатып, нидер мыгырдады, күзен ачмыйча гына кулын сузды:

— Ә, кайттыңмыни?

Әмма Данилов тәмәке көйрәтеп җибәрүгә, ул юка гына борын канатларын селкеткәләп, күзен ачар-ачмас:

— Сорок! — дип куйды.

— Ах, наян! Нәрсә син мутланып ятасың! Тәмәке тартырга ул уяу, ә инде иптәшләре белән сөйләшәсе булса, күзе дә ачылмый.

Шәмси эзләнеп як-ягына каранды. Ул юк арада взвод шактый ук кечерәеп калган. Шәмси белә иде инде: ул киткәннән соң аның полкын фронтның әле бер канатына, әле икенчесенә ташлаганнар, полк арыган, йончыган, иксез-чиксез походларда сугышчыларның өс-башлары, аяк киемнәре таланып беткән. Каты сугышларда әллә никадәр сугышчы кырылган. Кайсы үлгән, кайсы яралангандыр инде аларның. Мондагылар арасында Шәмсинең иң якын иткән, иң яраткан бер дус кешесе күренми иде. Ул, дусты турында авыр хәбәр ишетүдән куркып, кинәт кенә сорарга базмады.

Шулай да моны Даниловтан яшереп булмый иде. Шәмсинең кемнедер юксынуын ул үзе үк сизеп алды.

— Югалттыңмыни?

— Вәлитовны күрмим. Аңа да берәр хәл булмагандыр бит?

Данилов җавап бирергә ашыкмады, иреннәрен очлайтып, бик тәмләп суырды да тәмәке төпчеген Борисовка сузды.

— Аянычка каршы, булды шул, туганкай, булды. Бөтен хикмәт тә шунда. Әле син ишетмәдеңмени?

Шәмси агарып китте, күзләрен зур ачып Даниловның җиңенә ябышты.

— Нәрсә син? Әйт, ни булды? Үлдеме? Кул-аягы яраландымы?

Данилов башын селекте.

— Тагын да хәтәррәк!

— Бик авырмы?

Данилов башын чайкап кулларын җәеп җибәрде.

— Авыр, бик авыр. Кайда ул кул-аяк кына! Бөтенләй башын ук югалтты. Беләсеңме, аңарга хатыннар зәхмәте тиде...

— Ә? Нәрсә болгатасың? Нинди зәхмәт?

— Әйе, чын зәхмәт! Хатыннар зәхмәте...

Шәмси ачуланырга да, гаҗәпләнергә дә өлгерә алмый калды. Борисовка аркасын терәп яткан шинельле кинәт калыкты да, түгәрәк коңгырт сакалы, тынгысыз шаян күзләре, йоклаганда ниндидер ак əз төшкән, таушалган озынча бите белән болайга таба борылып, Шәмсигә кулын сузды.

— Ә, син бит бу, якташ! — диде.— Ничек болай истә-оста югында? Син бит доктор булып кайтасы кеше идең. Ничек алай бик тиз?! — Ул да түгел, Шәмсинең җавабын да көтмичә, киң җилкәсе белән бер селкенеп, Даниловны утырган җиреннән төртеп аударды.— Аһ, сары шайтан! Син нәрсә шахтер башың белән кепә-көндез алдашып утырасың? Нигә син минем якташның башын әйләндерәсең?..

Данилов өсләрен каккалап торып утырды да авызын ерып тагын үчекләргә тотынды:

— Дөрес ич инде, дядя Ахмади. Бер айдан бирле телеңдә гел хатын-кыз гына бит. Дөрес түгел дисенме? Кичә кое янында теге солдатканы ни дип кысып алдың? Я әле, я, менә якташың алдында ни диярсең икән? Телең бәйләнмәсме икән?

Вәлитов мәзәк кенә итеп күзен кысты.

— Әй, юрамалый гына бит ул,— дигән булды.— Бәй, ак сөякме икән, әллә кара эш эшләп үстеме икән дип, белер өчен генә ич ул...

Шәмси көлеп башын чайкады.

— Ай, ай, ай, абзыкай гынам. Сине бөтен полкта иң тәүфыйклы кеше дип йөргән идем, мин югында аза башлагансың түгелме соң?

— Ышанма син шул сары шайтанга. Көнләшеп үчекли ул. Аң бул, Гриша! Кайтышлый, Донбассыңа кереп, хатынына бер гөнаһыңны биш иттереп сөйләп чыкмасам, менә шушы тишек ботинкам аягымнан төшеп калсын.

— Ха, миңа буласы кәләш кисәге күзен елтыратып почмактагы кечкенә чүлмәк өстендә утыра ди әле...

Җыйнаулашып тагын көлеп алдылар.

Шәмси шушы барлы-юклы ике атна эчендә дә иптәшләрен чын-чыннан сагынуын хәзер бигрәк тә ачык сизде. Аңа иптәшләре белән юк-барны сөйләшеп менә шулай янәшә утыруы гына да бик рәхәт; ул, Әхмәдине ротадан киткән көнне үк юксына башлавын исенә төшереп, хәзер аннан күзен алмыйча карап утыра иде. Чөнки, бердән, алар икесе дә Татарстан кешеләре,

шуның өстенә, Шәмси әле яз көне генә алынган яшь сугышчы булганлыктан, кыен чакларда тәҗрибәле олы кеше итеп Вәлитовка сыена торган иде.

Вәлитов моңарчы Польша фронтында булган. Польша белән ике арада килешү кетелгәнлектән, көзгә таба армиянең бер өлешен Врангель фронтына күчерә башлаганнар. Менә ул да шундый частьларның берсендә әле күптән түгел генә болар полкына килеп төшкән иде.

Карт солдат мондагы яшьләргә башыннан узган бик күп сугыш маҗараларын, Польша фронтында күргәннәрен, Буденный атлыларының, ак полякларның тылына бәреп кереп, бик күп шәһәрләр алуын, Варшавага барып җитә язып, буржуйларның котларын очыруын сөйләде.

Әхмәди тиз ияләште. Шаянлыгы, мәзәк сүзләре, яхшы иптәш булуы белән ул үзен бик тиз танытты. Аны яшьләр «Әхмәди абзый» дип йөри башладылар. Шәмсинс ул чая телле, кыю холыклы булуы белән дә үзенә тарта иде. Чыннан да аның кыяфәте дә, тавышы да шулайга охшый. Менә хәзер җилтерәп сикереп торыр да, һәммәсен кузгатып, сүгеп ташлар шикелле. Озын буй, таза гәүдә, озынча матур бит, әрсез коңгырт сакал, шуның төсле үк калын мыек, тынгысыз үткен күзләр, чәчендә анда-санда җемелдәгән ак бөртекләр,— үзе әйтмешенчә, окопта узган озак еллар истәлеге,— менә шундый иде Әхмәди.

Тик Шәмси озакламыйча бу очрашу куанычы бер үзе генә түгел, аның янында ук күңелсезлекләр дә көтеп торуын сизә башлады. Әхмәди абыйсы бик үк таза түгел икән. Аның өстенә шинеле тузган, юка, җәйге гимнастеркасы телгәләнеп беткән. Әхмәди үзе бик ябыккан, каралып, ничектер бөрешеп калган, йөткергәли дә башлаган.

Вәлитов бераз арттарак туктаган поход кухнясына күз салды. Кухнядан төтен чыкмый иде. Кашевар, кухняга җигелгән карт алашасы кебек үк җилгә аркасын куеп утырган килеш үзе дә черемгә киткән. Вәлитов кулларын җиң эченә яшереп тагын да бөрешебрәк утырды.

— Мм. Булмады бу. Әллә кайдан күренеп тора. Азык китермәгәннәр... Икмәк тә өләшмиләр. Бер генә кадак булса да тамак ялгарга ярап куя торган иде...— дип әйтеп куйды, Шәмсинең үзенең генә моны аңлап бетермәве дә бар дигәндәй, гаепле кешедәй елмайды:— Кичәдән бирле ашаган юк. Эчне бора. Чабабыз да чаба-

быз. Шундый кызулыйбыз, ипекәй артыбыздан куып житә алмый.

Вәлитов, балалар беркатлылыгы белән үзе дә сизмәстән, Шәмсинең яшел капчыгына текәлде. Егет тылдан килгән кеше булгач, аның капчык төбендә берәр икмәк сыныгының булуы бер дә гаҗәп түгел бит. Шәмсинең белүенчә, Әхмәди абзасы ашау-эчү мәсьәләсендә алай комагай кеше түгел, күп вакытны ачлы-туклы торуга да түзә торган чыдам кеше иде. Инде хәзер олы башы белән шул сүзләрне әйтә икән, күрәсең, хәлләр яхшыдан түгел, ул аның үзәгенә үткән... Ләкин егет үзе дә кичәге көн өчен алган икмәген кичә үк ашап бетергән иде. Нишләргә соң? Капшана торгач, ул Әхмәди абзасына капчык төбендә кысылып калган бер шакмак шикәр сузды.

— Онытып та торам икән. Миннән күчтәнәч тиешле. Тик бар булганы шул гына, мә, суыр шушы тәмле шакмакны!

— Бәй, күчтәнәчнең зурысы-кечкенәсе юк бит аның. Энә дә бүләк, дөя дә бүләк, диләр. Рәхмәт, энекәш...— Әхмәди, шикәрне суырып балалар сыман иреннәрен ялмагач, телен чартлатып куйды.— Эх, булса иде шушында бер табак кайнар бәрәңге! Галимә апаң көн саен ярмаланып торган сары бәрәңге пешерә торган иде. Өстеннән буы бөркелеп тора, бармакларыңны пешерә-пешерә, учыңда сикертә-сикертә аласың...

Данилов тагын үчекләргә чамалап карады.

— Әйттем бит башыңа хатыннар чире суккан дип! Хәзер үз хатыны турында гына сөйләгән була әле, менә күр дә тор, ул сиңа бүтәннәрен дә тезә башлар.

Әхмәди аңа кулын гына селтәде дә, аягын бөкләп утырган килеш, гүя сөйләгәннәрен күз алдына китерергә теләгән сыман, күзләрен ярым йомып сүзен дәвам итте:

— Ашъяулыкта күкрәккә терәп, калын итеп кискән арыш әпәе. Бәрәңге өстенә аз гына көнбагыш мае да сибеп җибәрәсең. Аннары куе итеп, сөтләп торып кайнар чәй! Эх, әпәй, әпәй. Әпәй белән бәрәңге! Корсак тутырып «пух» иткәнче ашап чыгасың да эшләп торып җибәрәсең, әй, якын-тирәдә бураннар гына уйный!..

Шул вакыт әллә иптәшләренең сөйләшкән тавышларына уянды, әллә ашыйсы килүенә түзә алмады, Әхмәди артындагы ызаннан күзләрен уа-уа Микола Перебейнос торып утырды.

— Әй, Бачило, ишетәсеңме? — дип, ул янында яткан ап-ак чәчле, юан гына базык гәүдәле күршесенә дәште.— Бәрәңгене, дим, синең белоруссларың гына яратмый икән бит, ә?

Тегесенең моңа бик артык исе китмәде. Ул, җавап биреп мәшәкатьләнмәстән, сизелер-сизелмәс итеп иңбашларын гына селкетеп куйды. Михась Бачило болай да сүзгә юмарт кеше түгел иде. Бөтен көн буена бер генә тапкыр да авыз ачмаган чаклары да булгалый торган иде. Әмма бер җенен чыгарсалар, анда инде чыдап кына тор. Бу ике дусның, һаман шулай әйткәләшкән булсалар да, үзара сокланырлык дәрәҗәдә тату яшәүләре, бер-берсен туганнарча кайгыртулары Шәмсигә бик ошый иде.

Миколаның калын тавышы тагын гөрелдәп алды:

— Карале, син, Михась, мин әйтәм, бәрәңге белән бергә шәт теленне дә йотмагансың ич?

Бачило монысында да күзен ачмады, бары иңбашын гына кыймылдатты. Әмма дусты Микола өченче тапкыр да уртәргә тотынгач, Бачило түзә алмады. Ул, белорус теленә рус сүзләре катнаштырып, Миколаны шундый суганлап-борычлап сүгеп ташлады, тегесе шаккатып күзләрен акайтты. Шулай бераз карап торды-торды да гөрелдәп көләргә тотынды:

— А, һа, һа, һа!

Һәммәсе дә тынганнан соң, Бачило, әле һаман да күзен ачмастан, әмма гүя берни дә булмагандай, йокыдан арынмаган йомшак тавыш белән дустын кунакка чакырырга тотынды:

— Син безнең Белоруссиягә сугыштан соң килеп чык. Минем Ганькам сине бәрәңгедән шундый-шундый ризыклар белән сыйлар, сезнең хохол халкы андыйны өстәлдә түгел, төшендә дә күрә алмый. Тик сугыш беткәч инде алары...

Әхмәди, кашларын җыерып, тәмәке төпчеген читкә ыргытты. Әллә ашыйсы бик килгәнгә, әллә башкага, шул арада аның кәефе бозылып та өлгергән иде.

— Беткәч, беткәч... Кайчан бетә бит әле ул! Әнә теге капкорсаклар, муеннары сынгыры, тирес кортлары бездән көнләшәләр бит. Ярлы-ябагайның тамагы туймагае, бездән башка да тормыш кормагайлар иде, безнең кирәгебез бетмәгәе дип көнләшәләр. Шуннан котлары чыга, җаннары табан асларына төшә бит!

Ул арада, тачанкасы белән пулеметын обозда калдырып, болар янына Митричев та килеп житте.

— Менә бәхет! Привал бетми дә бетми. Ни булды, нигә кузгалмыйбыз дип бер генә кеше дә кыбырсымый. Шым!..

— Алай аягың бик кычытса, бар, алдан тәпили тор.

— Аның бит аягы түгел, теле генә кычыта.

Митричев боларга кушылып үзе дә көлде, Вәлитовның ышыгына кереп бөрешеп утырды да шинель җиңендәге тишектән бармагын чыгарып күрсәтте.

— Шинельгә тишек ябыша башлады, кайда әле безнең политрук? — диде.

Мондый кәефсез чакларда Әхмәдинең бик каты тешләп ала торган гадәте дә бар иде.

— Сиңа яңа шинель алырга дип чахаузга йөгерде... Шунда бер очтан бутылкалы кызыл ыштан да тектереп кайтам, ди. Шуларны кигәннән соң син койган да куйган Кузьма Крючков буласың. Ишеткәнең бармы шундый бер буш куык турында? Бөдрәләре тырпайган, борынын чөйгән, фасон шәп!

— Юк, чынлап, менә күрәсең, шинельнең киярлеге калмады бит. Нинди җылы торсын монда? Пожалуй, Врангель офицерларыннан алып тормыйча булмас. Аларга Антанта* тагын җибәрер әле. Күргәнегез бармы? Яшел, җиз төймәле... Һәйбәт, җылы шинель...

Борисов яткан урыныннан торып утырды, аның матур чыраенда ризасызлык билгесе күренде.

— Син шуны чирканмыйча кияр идеңме?

— Нигә кимәскә? Нигә җирәнгән булып кыланырга? Җылыткач, миңа димәгәе ник шунда Врангельнең үз шинеле булып чыкмый!

Борисов бик гаҗәпләнгәндәй башын чайкады.

— Менә син нинди... Нигә кимәскә, имеш. Ә син белмисеңмени, синең авыз суларыңны корыткан ул яшел шинелең кып-кызыл канга буялган! Синең туганың канына, Совет власте өчен көрәшкән эшче-крестьян канына! Син нәрсә, онытгыңмыни?..

— Ну, син инде бигрәк нечкәртеп җибәрдең. Исең киткән, барышня, үләсең килмәсә, киярсең!.. Кимисең

---

* Антанта — Беренче империалистик сугыш вакытында Англия, Франция, Италия һәм патша Россиясе арасында оешкан сугыш союзы шулай атала иде.

икән, әнә шулай дерелдисең генә, я, үпкәңә салкын тидереп, әнә шундый берәр ызанда түнеп каласың.

Борисов йөзен чытып читкә карады. Митричевның шуны да аңламавы аны җәберли иде. Ул Вәлитовка борылды.

— Синеңчә дә шулаймы, дядя Ахмади? Антанта шул яшел шинельләрне кидереп, юк-бар белән алдап, безнең өскә кемнәрне генә җибәрмәде! Никадәр кан койдылар, никадәр балалар ятим калды. Тиз онытасың икән син, туган.

Әхмәди «дөрес» дигән сыман башын иеп куйды.

— Сез бер дә кирәкмәгәнгә бәхәсләшмисезме икән? Шинельдә генә түгел монда хикмәт. Туры килсә, яңа шинельне мин дә җилтерәтеп кенә алыр идем. Була шундый чаклар, тешләрең тешкә тими. Әмма ерткычлык дигәндә, синең сүзең хак, анысы онытылмас, юк! Илләкомсыз, иллә кансыз да инде буржуй дигәннәре. Менә мин революциянең башыннан бирле гел сугышып йөрим. Кайларда гына сугышмадым! Юденичы да калмады, Колчагы да, Деникины да. Син ул буржуйны, әйтик, боз дингезе буенда дөмбәсләп җибәрәсең, ә ул, канлы танавын сузып, я Каспий ягыннан, я Афган чигеннән килеп тыкшына. Анда муенын борып ыргытасың, ул сиңа өере белән шпионнар җибәрә, ут төртә, кешеләребезне үтертә, кырык төрле бүтән этлекләр эшли.

Данилов Әхмәдинең иңбашына кулын салды.

— Ә син ничек булыр дип уйлаган идең? Бүтәнчә була да алмый ул. Шуның өчен дә бит ул буржуй, капиталист. Без көчәеп китсәк, аңарга бит крышка. Шуңарга ярсыйлар да алар.— Ул барасы якка ымлап:— Хикмәт әнә кайда!— диде.— Кырымны алсак, аларга бүтән тыкшыныр урын да калмый.

Ул арада болар янына рота командиры да килеп чыккан иде. Ул:

— Взвод командирлары! — дип кычкырды.

Данилов белән тагын ике взвод командиры аның янына килеп бастылар.

— Полкны шунда туйдырырга приказ бар. Хәзер үк каптенармуска икмәк алырга җибәрегез!

Аннары ул боларның төркеме янынарак килде дә шинеленең чабуын кире кайтарып ызан буена килеп утырды, гүя сугыш кырындагы күкрәүләрне тыңлагандай, башын иеп җиргә текәлде, калку маңгаена җыерчыклар чыкты.

Барысы да тынып калдылар. Бу тынлыктан котылу өчен Әхмәди:

— Безнекеләрдер бит бу, иптәш ротный? — дип сорады.

Пахомов, гүя соравының мәгънәсен аңламагандай, Вәлитовка озак кына карап торды, туп тавышлары тагын бер гөрелдәп алдылар.

— Юк. Түгел...

Пахомов элек патша офицеры булган имеш дип сөйлиләр. Шунлыктан сугышчылар аның үзен тотуын, сөйләшүен аеруча кызыксынып күзәтәләр иде. Командирның шинеле элек погонлы булган да хәзер аның инбашында алтын погоннарның уңып җитмәгән аксыл соры эзләре генә калган тәсле күренде. Киң ирененде дә элек бик хәтәр тәпи басып торган бөтерүле мыек булган да хәзер, аның урыны шәп-шәрә калгач, ул кимсенә кебек. Чыннан да, кайчакларны командир, нидер исенә төшкәндәй, имән бармагы белән мыек урыннарына үрелгәли торган иде. Аны биек каракүл папахасы да башка командирлардан аерып тора, анык кебек агач кобуралы зур маузер хәтта полк командирында да юк иде.

Патша офицеры... Кем белә, бәлки аның, Шәмсиләр янындагы алпавытныкы шикелле, үз имениесе, юртак атлары, салпы колаклы бурзайлары булгандыр?.. Ефәктән генә киенеп йөрүче дәү эшләпәле, кызыл иренле. симез хатыны бардыр... Бәлки бөтен байлыгыннан мәхрүм иткәнгә шулай ачулыдыр әле ул, оныта алмый торгандыр...

Шәмсигә дә, бүтәннәргә дә командирның кайсы якларыдыр аңлашылмый, ул ничектер үзен бик салкын, бик коры тота. Шулай да соңгы вакытларда аның сагаеп кына булса да үзләренә якынаерга тырышуы барысына да ошый иде.

Бераз тыңлап утырганнан соң Пахомов тагын әйтеп куйды.

— Тегеләр ата. Ишетәсез бит, авыр артиллерия. Ә безнекеләр килеп җитмәгән әле, тегендә калдылар...

Пахомов, «тегендә»нең кайда булуын белдереп, башы белән артка таба ымлады.

Башкалар кебек үк Әхмәдинең дә командирның телен чиштереп җибәрәсе килә иде.

— Кырымга ерак та калмадык бугай инде, иптәш командир, шулайдыр бит? — диде.

Пахомов алга таба кулын сузып күрсәтте:

— Аа-нә теге болытларны күрәсезме?

— Күрәбез,— диештеләр.

— Шул болытлар турысында инде ул Кырым... Тик алардан чүт-чүт түбәнрәк кенә...

Кайберәүләрнең, бу сүзләрне чынга алып, муенарын суза-суза болытлар астыннан Кырымны күрмәкче булып маташуларыннан ул үзе үк көлеп җибәрде, аның иреннәре арасыннан алтын теше елтырап китте. Бүтәннәрнең дә авызы ерылды.

— Алай итеп Мәскәүне дә күрсәтергә була.

— Алайса бу гөрселдәү Кырым капкасы төбендә түгелмени әле?

— Юк, түгел.— Пахомов шул якка колак салып тагын бераз тыңлап торды. Ишетелүенә караганда, сугыш тагын да кыза төшкәнгә охшый иде.— Түгел, Перекопка барып җиткәнче бик каты бәрелешәсе бар әле. Бәлки менә бүген үк, шушында ук... Сез Фрунзеның акларга Кырымга чигенергә ирек бирмичә, Тавриядә камап алып бетерергә, дигән приказын ишеттегез бит?

— Ишеттек.

— Ишетсәгез, без әнә шул приказны үтәргә җыенабыз инде. Аңлашылдымы?

Пахомов шуның белән эш беткәнгә санап портсигарына сузылды. Ул солдат белән приказ телендә генә сөйләшергә күнеккән иде. Солдат та аңар элек-электән «так точно!» яисә «никак нет!» дип ике сүз белән генә җавап биреп килде. Шул җитмәгәнмени? Кайсыдыр авыз эченнән мыгырданып кына әйтеп куйды:

— Менә тагын, аңлашылмыйча. Аңлашыла, конечно...

Пахомов махорка тутырган көмеш портсигарын тезе өстенә ачып салды да ниндидер плакат кырыеннан ертып алынган саргылт кәгазьне бармак арасында уа башлады.

Әйе, шул җиткән. Солдат белән солдатча сөйләшергә кирәк. Бу сиңа базар түгел, сугыш җире... Ләкин, як-ягындагы тынлыкның артык озакка сузылуына игътибар итеп, шунда ук күтәрелеп карады.

Әйе, кайсы чүгәләп, кайсы тезләнеп, җилдән саклану өчен бер-берсенә сыенып утырган сугышчылар аннан тагын нидер көтәләр иде. Шулдыр, әлеге теге кызыл командир дип йөртелгән яшь этәчләр кебек аның да такылдавын көтәләрдер. Иптәшләр, янәсе. Буржуйлар шундый да, буржуйлар мондый... Кызыл сугышчыга

аңлы булырга кирәк, фәлән булырга кирәк... Юк инде, бик рәхмәт. Өндәү-димләүләр политрук эше, ул шуның өчен паёк ала, шуның өчен казна киемен туздыра. Хәер, бүтән эше дә юк. Сөйли бирсен...

Тәмәкесен көйрәтеп бирәр суыргач, Пахомовның аз гына башы әйләнеп китте. Командир, нәрсәгәдер үзен дә бераз гаепле санагандай, башын күтәрер-күтәрмәс сугышчыларына тагын да җентекләбрәк карый башлады. Күбесенең иреннәре күм-күк, үзләре бөрешкәннәр. Аларның бит кичәдән бирле бер сынык икмәк капканнары юк. Җылы өйдә йокламаганнарына шәт унбиш көн бардыр. Чөнки керер урын юк, гел кырда куныла, гел далада. Менә хәзер сугыш башланып китсә, ул бит боларны һөҗүмгә алып барачак, атакага, үлгәнче сугышырга! Ә аларның кичәдән бирле ашаганнары гына түгел... тәмәке тартканнары да юк!

Пахомов тәмәкесен ашыгып бирәр генә суырды да ничектер уйлап та тормыйча, үзеннән-үзе, уң ягында тәмәке төпчегеннән күзен ала алмастан иреннәрен ялмаштырып утырган Митричевка сузды. Анысы бирәр суыруга аңа күршесе сузылды. Тәмәке төпчеге түгәрәкне әйләнеп чыгарга да җитмәде, тартылып бетте.

Пахомов эчтән генә авыр сулап куйды:

— Алай... һм... Кырым турында сорадыгыз бит әле?

— Әйе, иптәш командир.

Пахомов Борисовның мылтыгыннан штыгын алды да, чүгәләп утырып, туфракка нидер сызарга тотынды. Бербирсенә янәшә китереп бер түгәрәк белән шактый ук озынча бер шәкел ясагач, бераз уйланып торды. Аннары штыгы белән бәрәм-бәрәм төртеп күрсәтте.

— Монысы Украина, монысы Белоруссия,— диде.— Моннан бер-ике ай гына элек безгә каршы Польша да сугыша иде бит әле. Менә! — Штык очы Польша ягыннан Советлар иленә таба озын бер ук китереп кертте. Шуннан соң иң аста бер дүртпочмак ясады.— Бусы Кырым булды.— Аннан Советлар җиренә таба тагын бер ук сузылды.— Монысы Врангель армиясе! — диде. Бераз икеләнеп, нәрсәгәдер уңайсызланып торды. Әйтергәме? Бу сүзләрне ул бер җыелышта полк комиссарыннан ишеткән иде. Үз авызында да беренче тапкыр. Булса соң?! — Ленин... Владимир Ильич бу ике укны буржуйларның Советлар Россиясен буарга дип сузган ике кулы дип атаган иде... Бу кулларның менә монысын...— Польшадан кергән укны штык очы аркылы сызды,— Кызыл

Армия кисеп ыргытты.— Күтәрелеп караганда төркем артында политрук Исмаевның мангаена төшкән кап-кара чәчен, көлемсерәгән елтыр күзләрен күргәч тагын да уңайсызлана төште. Командир белә: агитаторларга кырын караучы, алардан көлеп йөрүче кеше үзе өндәүдимләү эшенә тотынган дип көлемсери бит ул. Көлмәгәе! — Ә монысы ничек?..

Пахомов, үзенә үзе гаҗәпләнүенә каршы, сугышчыларына һаман якыная баруын, аларның да моңа кадәр бераз кырынрак карап, бераз читләтебрәк йөргән командирларын хәзер якын һәм үз итүләрен, ничектер ике арада җылылык урнаша баруын хис итә башлады. Кинәт аңа бик рәхәт булып китте. Күңеле горурлык белән тулды. «Ышаналар,— дип уйлады,— минем белән утка да, суга да керәчәкләр!»

— Сезгә сөйләгәннәр булса кирәк, Врангель Кырымнан кырык мең гаскәр белән бәреп чыккан иде. Никадәр артиллерия, никадәр танк! Ләкин без аны Днепр буенда, Каховкада, хәтерлисезме, ничек изеп ташладык?!

Митричев рухланып китеп приклады белән җиргә бәрде:

— Әй! Хәтерләмәгән кайда ул! Издек! Ярты гаскәрен кырып ташладык, нихәтле плен алдык!.. Ничә танк!..

Тик аның янында утырган Данилов иптәшенең шинель чабуыннан тартты. Менә бит, аңгыра бәрән, шуны да күрми! Командирның сөйлисе килә, дәртләнеп, үз итеп сөйли, кирәкне сөйли!.. Аңлатсын әйдә! Митричев күршесенә усал караш ташлады да авызын турсайтып тынып калды.

— Исән калган ярты гаскәре белән Врангель хәзер без утырган җирләр аша Кырымга чигенеп Перекоп артына посмакчы була. Без менә хәзер аның чигенү юлына аркылы төштек. Инде командующий Фрунзе безгә әйтә: юк, сез Врангельне моннан исән уздырмагыз! Кырымга кереп бикләнергә ирек бирмәгез, менә шушы тирәдә камап алыгыз да төрле яктан чытырдатып кысыгыз. Шушында бетерегез, шушында! Аңлашылдымы?

Йөзләре ачылып киткән сугышчылар, күңелләнеп, төрлесе төрле яктан тавыш бирделәр:

— Менә хәзер аңлашылды, иптәш командир!

— Барын да белдек. Булды хәзер!

— Төшендек!

Пахомов нигәдер елмайды, әмма моны үзе үк ошатмады, яңадан тәмәке төрергә тотынды.

Обоз ягыннан берничә бөтен икмәк күтәреп килүче Шәмси күренде. Икмәкне шунда ук бүлеп тә ташладылар. Пахомов икенче караганда һәр сугышчы үз паегын, бер генә валчыгы да төшмәслек итеп, ике куллап учлаган да бөтен дөньясын онытып кимерә дә башлаган иде.

Ул да түгел, култык астына газеталар кыстырып, яңадан политрук Исмаев калкып чыкты. Ул сугышчыларның туктаган вакытын сагалап кына йөри иде. Уртага килеп командир янына тезләнде дә кыштырдавыклы ап-ак яхшы кәгазьгә басылган ниндидер чит бер газетаны җәеп җибәрде.

— Иптәш командирның болай төшендереп бирүе бик әйбәт булды әле,— диде. Кап-кара кашлары өстенә ишелеп торган чем-кара куе чәчен бармак очлары белән колак артына сыпырып, елмайган кара күзләрен командирга сирпеп алды.— Шуңарга өстәп мин сезгә дошманнарның үзләре язган хәбәрләрне укып карыйм әле,— диде. Кайсының кырын ятып, кайсының утырып, җайланып бетүен көтте. — Бу — акларның Севастопольдә чыга торган «Великая Россия» исемле газеталары. Аклар менә нәрсәләр язалар: «Ж а н к о й.... Октябрь. Безнең данлы һәм шанлы гаскәрләребез һич туктамастан алга баруда дәвам итәләр... Төньяк Таврияда генерал Слащев частьлары кызылларның өч мең җәяүлесен плен алды һәм бик күп санда сугыш кораллары кулга төште... Безнең гаскәрләр шушы арада, алла боерса, кызылларны бөтенләй кырып бетереп, Днепрның аргы ягына чыгачаклар. Аннан инде туп-туры Мәскәүгә! Хәзер кызылларда паника. Алар, обозларын, штабларын ташлап, тәртипсез рәвештә качалар...»

Политрук актык сүзне укып бетерүгә, шаулашып көлеп җибәрделәр:

— Качалар?! Ха-ха-ха, кемнәр кача икән, шуны сорыйсы иде!

— «Мәскәүгә» имеш!.. Тот капчыгыңны!

— Ах син оятсызларны, ә! Өч мең плен алды дигәнме?!

— Каховка янында ничек хур булуларын, танкларын калдырып качуларын язмыйлар, ә?

— Менә солдатның ничек башын әйләндерәләр икән, эттән туганнар!

Терекөмеш кебек гел тәгәрәп кенә йөрүче, кайвакыт белмәгән башы белән командирлар эшенә дә борынын тыккалаучы бу әрсез егетне, Исмаевны, Пахомов, туры-

сын гына әйткәндә, бик үк өнәп бетерми, аның белән бик үк исәпләшми дә иде. Әмма менә бу эшен бик ошатты. Кара син, нинди җайлы вакытта килеп кысылды да нинди кирәкле нәрсәләрне кузгатты бит! Русчанываткалап булса да маташтыра бит! Шундый зур бәрелешләр көтелгән бер вакытта, моны аларның үз авызларыннан әйттерү бик шәп бу!.. Пахомов үзалдына елмаеп куйды.

Исмаевка төрле яктан сораулар ява башлады:

— Я, я, иптәш политрук, тагын шундый кәмит урыннары юкмы?

Сугышчыларны киләчәк бәрелештә кирәк булачак кайбер нәрсәләр белән таныштыра тору, Кырым ныгытмалары турында алдан ук аларның исенә төшереп кую өчен дә бу бик җайлы вакыт иде.

Исмаев командир белән ике арадагы кырауны бөтенләй эретеп бетерү өчен аның белән дә киңәшеп алган булды.

— Аполлинарий Петрович! Ничек, сезнеңчә, дәвам итәбез алайса?

— Сөйли бир! Барысы да кирәк.

Исмаев әлеге газетаны тагын укый башлады:

— «Инде булмастайны булды дип гөман итсәк тә, кызыллар Тавриядә җиңгән сурәттә дә Кырым өчен тынычсызланырга һичбер сәбәп юк. Перекоп һәм Сиваш элек-электән кызыллар аяк баса алмаслык урыннар иде. Ә безнең командование аларны тагын да мөкәммәлләштерде. Хәзер инде Перекоп һәм Сиваш, гомумән, Кырымның төньяк буе, шундый итеп ныгытылды ки, кызылларның җанлы көче дә, «техникасы» да бу ныгытмаларга аз гына да зарар китерә алачак түгелләр».

Исмаев укып бетергәннән соң беразга сүзсез утырдылар. Бу кадәр кистереп әйткәч, ихтимал, барысы да ялган түгелдер. Монда уйланасы нәрсәләр шактый ук иде. Әгәр аклар Кырымга кереп бикләнәләр икән, бу бит инде шушы өтек өс-баш, шушы тишек ботинкалар белән тагын кыш буе Кырым капкасы төбендә таптанырга, кыш буе сугышырга кирәк дигән сүз. Сугышчыларның күз алдына менә нәрсә килеп басты. Политрук Исмаев күңел төшенкелегенә бирелергә яратмый торган кеше иде.

— Ну, анысын карап карарбыз әле! Әйе бит, Аполлинарий Петрович! — диде,— хәзергә без менә бүгенгесен кайгыртыйк. Бүген нишләргә? Ул сволочьларга

Кырымга кереп посынырга ирек бирмәскә! Әйе бит, иптәшләр!

— Шулай, барып кына житик, ничек итеп аласын алардан сорап тормабыз!

— Әйе, анда барып житкәч, Кырымны алмыйча кире борылып кайтмабыз инде анысы.

Боларга Пахомов та кушылды:

— Анысы факт! Тик барысы да ансат кына эшләнер дип уйлый күрмәгез. Зур көч куярга туры киләчәк...

Исмаевның Борисовка күзе төште. Миша Борисов, ара-тирә сүзгә кушылгаласа да, бүген нигәдер аеруча боек күренде. Политрук аны әңгәмәгә катнаштырасы килеп:

— Менә безнең Борисов ни әйтер тагын,— дип куйды.

— Минме?.. Мин сугышны тизрәк бетерү ягында.

Политрукның аны әңгәмәгә тартырга тырышуына кайбер сәбәпләр бар иде.

...Борисов армиягә алынганчы Тамбов губернасындагы шәһәрләрнең берендә укытучы булып эшләгән. Монда килгәч тә ул, полк ялда вакытларда, кызылармеецларга рус теле һәм арифметика укытты. Вәлитов белән Шәмси дә русча укырга-язарга аннан өйрәнә башладылар. Ул тора-бара ротаның укытучысы да, китепханәчесе дә булып китте; иптәшләре өчен актык сынык икмәген дә урталай бүлеп бирә торган иркен күңелле, юаш бер егет иде.

Менә шул күңелле егетне моннан унбиш көннәр элек, кара болыт төсле булып, зур бер кайгы килеп басты. Элек ягымлылык сирпеп торган көләч күзләренә эчкә генә сыймаганга тышка бәреп чыккан моң пәрдәсе тартылды. Баштарак кайберәүләр: «Укымышлы кешеләр аз-маз борчуны да зур итеп күтәрүчән була, шулай боегып йөрер-йөрер дә узар әле», дип уйладылар. Тик Борисовны азаплаган борчу алай узгынчы гына булып чыкмады. Шулай да һәркайсы аның кайгысын жиңеләйтергә тырыштылар.

Авылда кунган бер төнне Исмаев аны үз янына чакырды.

— Кулдан килә торган икән — булышырбыз, әйтергә яраса, безгә белдерүең яхшы булыр,— диде.

Борисов аңа, кайгысын уртаклашырга хәзер торуы өчен, рәхмәт әйтте.

— Минем,— диде,— атам-анам да, туганнарым да

юк. Мине якын иткән, күңелемнең иң тирән бер җиреннән урын алган бары бер генә кеше бар иде...

Аннан соң ул үз теле белән берни дә әйтмәде, политрукка шаян елмайган бер кыз рәсемен һәм хат чыгарып бирде. Ул хаттан аны язган кулның калтыравы күренә иде.

«Миша!

Бу хатны язарга кулым бармыйча озак икеләнеп йөрдем. Минем бик күп төннәрем йокысыз узды. Бу хәлне язып, синең күңелеңне җәрәхәтләргә вөҗданым җитмәде. Йөрәгемә урмәләгән хәшәрәтне синнән яшереп торырга, азабын үзем генә күрергә тырыштым. Инде хәзер түзүдән узды. Хәлем бик аяныч, Миша. Мине дошманнар мыскыл иттеләр. Безнең ике арадагы якын йөрәк дуслыгын, синең Лидияңне, яшьлек чәчәгеңнең парын, хур иттеләр...

Миша! Оныт мине. Саф күңелеңне моның белән тапләма».

Алар байтак вакыт бер-берсенә сүз әйтә алмый утырдылар. Исмаевның ике кашы арасына тирән җыерчыклар чыкты.

— Хәзер ничек соң?

— Больницада, сәламәтләнүенә өмет аз дип язалар.

— Ә бандитларны нишләткәннәр?

— Анысы билгеле инде...

Политрук, маңгаендагы җыерчыкларын сыйпаштыргалап, бераз уйланып утырды.

— Бәлки сиңа кайтып килергә кирәктер? Күрерсең, сөйләшерсең...

Борисов башын селекте.

— Юк, мин аны күтәрә алмам. Аннары, вакыты да ул түгел.

Байтак сөйләшкәннән соң, ул бераз онытылыр төсле дә булды. Шулай булса да аның бу борчылуы тиз генә җинелерлек түгел иде әле.

Политрук вакыйганы Пахомовка да сөйләде. Алар Борисовка ничек ярдәм итү турында, аягүрә генә булса да, киңәшеп тә алдылар.

...Командир, гәпне дәвам иттергәндәй:

— Шулай да, Борисов, кайтып килсәң ничек булыр икән, ә? Минемчә, яхшы чыккан булыр иде. Белмәссең, бәлки инде тазарып та килә торгандыр.

Борисов Пахомовка кинәт кенә күтәрелеп карады. «Бу сүзләрне ул үзенә үзе ышанып әйттеме икән? Әллә чыннан да аның тазаруына ышанырга берәр сәбәп бармы икән?»

— Әйе, әйе,— диде Пахомов.— Нигә син ул тазара алмый дип уйлыйсың? Яшь кеше бит ул!

Борисовның күңеленә беренче тапкыр өмет чаткысы керде. «Чынлап та, нигә аның тазаруы мөмкин түгел? Нигә авыруны җиңмәсен икән ул?» Ул үзен бу өмет белән алдап, соңыннан дөрес булып чыкмаганда авыр булмасын өчен, хәзер аңа ышанып бетмәскә булды.

Шулай да Борисов күңелендә кечкенә генә бер өмет чаткысы урнашып калды. Ул чаткы аның авыр уйларын җиңеләйтте. Ул аңа дәрт һәм ышаныч өстәде. Ул күңеленең иң түрендә генә булса да, шушы сугышны бетергәч кайтып килгәндә яхшы булыр иде, дигән уйга урын бирде.

Борисов үзен искә алуларына бер яктан шатланды, икенчедән, шундый вакытта үз кайгысы белән башкаларны борчуына уңайсызланды.

— Кирәкми, урыны андый түгел. Нәрсә ул? Тузан! Бу бит аерым кешеләрнең капризларын көйли торган урын түгел. Ул монда килешми дә.

— Менә моңысын ялганлыйсың инде,— диде Пахомов. Ул Борисов фикеренең нилектән дөрес түгеллеген әйтмәкче булып авызын ачкан иде дә, Данилов сүз башлагач, аны бүлдермәде.

— Минемчә дә, Борисов ялгыша. Урынына карап. Нинди эш, нинди кеше бит...

Әнгәмә бетеп тә өлгермәде, атлары ап-ак күбеккә төшкән ике атлы, камчыларын селти-селти, колоннаның башына таба чабып уздылар. Ат тоякларының тавышы тынып кына җитте, юл уртасыннан тиз-тиз атлап болайга таба килүче берничә командир күренде. Нечкә буйлы, аяк очына төшеп торган озын аксыл шинель, башына кызыл түбәле биек соры папаха кигән мәһабәт һәм матур гәүдәлесе шпорларын зыңгылдатып килде дә:

— Командир!— дип кычкырып җибәрде.

Пахомов җәһәт кенә сикереп торып аның каршысына барып басты, бик килешле һәм оста итеп уң кулын папахасы турысына менгереп алды:

— Тыңлыйм, иптәш комбат!

— Хәзерләнегез, кузгалабыз!

Батальон командиры, Пахомовның бу әйткәннәр белән генә канәгатьләнмәвен, тагын нидер көтүен сизеп, аның янына ук килеп басты. Хәзер инде командирның тавышы йомшак, иптәшләрчә иде:

— Аполлинарий Петрович,— диде,— безнең өскә Кырымга таба чигенеп баручы ике полк ябырыла. Күзләренә ак-кара күренми. Беләсең бит, аларда җан кайгысы, баш кайгысы! Аңлашыламы? Синең пулеметың бирәү генә бит. Тиз бул, гранаталар алырга кеше җибәр. Озакламыйча атакага күтәрелергә туры килмәгәе!.. Аңлашыламы?

— Бик! Ләкин миңа аз дигәндә тагын бер пулемет кирәк иде бит.

— Булмый, чөнки юк! Килеп җитмәде.

Комбат үзе шикелле үк пөхтә киенгән яшь кыяфәтле штаб башлыгы һәм элемтәчеләре белән кызу атлап арттагы роталарга таба узып китте.

Тик алар күздән генә югалып өлгерделәр, полк командирының ординарецы, атын куып, колонна буенча чабып узды:

— Кузгалырга, тиз, алга, бегом!

Тагын бер минуттан бөтен полк аякка баскан, кайсы винтовкасын иңенә алып, кайсы кулына тотып атлый-йөгерә алга таба ашыга иде.

IV

Бер сәгать тә, сәгать ярым да узып китте, полк шулай кызулап баруында дәвам итте. Алдарак кайдадыр каты сугыш бара, ара-тирә әле якындарак, әле ерактарак туплар гөрселдәгәне ишетелә, әмма барасы уңайда берни дә күренми иде әле. Сугышчылар талчыга башладылар, бер адым атлау да бик кыенга әйләнде.

Бик авыр булса да, бу полкның сугышчылары өчен озын-озак юлларны җәяүләп узу яңалык түгел иде түгелен. 1920 елның язында Казанда оешкан җәяүле укчы дивизиянең сугышчылары көз башларында Украинага килеп шушы 15 нче Инза дивизиясенә кушылганнан соң, аларның барлык гомерләре диярлек сугыш кырларында, походта йөреп узды.

Барон Врангель җәй көне Кырымнан бәреп чыгып озак ял иткән, яхшы коралланган, һәйбәт киенгән кырык меңлек гаскәр белән Донбасс унаена һәм Мәскәү

юлына таба көчле һөҗүм башлаганнан соң, бу дивизиягә каты сугышларда катнашырга туры килде. Менә бу, йөз утыз икенче полк та, дошманны алга уздырмас өчен, кайвакытларны ялсыз, кайнар ашсыз тәүлегенә алтмышар-җитмешәр чакрым юл уза иде. Барып җитүгә, ял итмәстән, ачлы-туклы килеш я сугышка керә, яисә икенче бер юнәлешкә ташлана. Сугышчылар шәрә кырда, каты кантарлар өстендә ипи сыныгы капкалап алганнан соң, аягүрә йоклый-йоклый, унике ярым кадаклы винтовкасын, 250 патрон тутырган киндер патронташын, сапер көрәген һәм тимер чыбык кисә торган зур кайчысын, алар өстеннән солдат капчыгын аскан килеш тагын Тавриянең очсыз-кырыйсыз озын юлына чыгып китә. Каты җилдән сугышчыларның битләре, куллары ярылып бетте, күз кабаклары җилсенде. Айлар буена мунча керә алмаганлыктан һәм алмашынмаганлыктан, өс-башлары телгәләнеп бетте, күп вакытны кырда, шәрә балчык өстендә йокларга туры килгәнлектән, шинельләр ертылып эштән чыкты, күп йөрүдән ботинкалары таралды.

Менә хәзер дә рота командирыннан башлап иң арттагы сугышчыга кадәр бөтен полк авыр йөген күтәреп тиз-тиз алга атлый, әмма арулары җиткән иде инде. Хәлсезрәкләр, аягы бозылганнар яисә картрак сугышчылар арткарак кала башладылар.

Көн салкын булуга карамастан, күбесе изүләрен чишеп җибәрде, колонна өстеннән бу күтәрелә, сугышчыларның авыр сулаганы ишетелә иде. Шулай да акрынларга ярамый, алда нидер көтә, каядыр хәзер үк барып җитәргә кирәк. Полк командирының ординарецлары әледән-әле колонна буеннан атларын камчылап командирның приказын кычкырып үтәләр:

— Тизрәк, тизрәк, артка калмаска, таралмаска!

Актык көчләрен җыеп тагын да кызурак атларга тырышып карыйлар. Бәлки ерак та түгелдер инде.

Үргә менеп җитүгә, алда бер авыл күренә башлады. Ул, Украинаның башка авыллары шикелле үк, берничә чакрымга сузылып даланың иңкелендә утырган зур авыл иде. Аның өстенә зәңгәр сөрем җәелгән. Авылның бу ягында кечкенә ак өйләр тезелгән, урта бер урында, йортлар өстеннән калкып, биек манаралы, көмеш гөмбәзле кызыл чиркәү утыра. Берничә урында муеннарын югары сузган кое сиртмәләре, шәрәләнгән кечкенә җимеш бакчалары күренә.

Миша Борисов барысыннан да артыграк арыган иде. Ул Шәмсинең иңбашына таяна төшеп аякларын көч-хәл белән генә сөйри, кипкән иреннәрен ялый башлаган иде. Авылны күргәч, салынган башын беренче тапкыр күтәреп елмаеп карады.

— Уф! Авыл! Мин дә егылып калмыйча барып җитәм бугай. Кеше шушы кадәр арыганнан соң да аякларын атлый алыр дип уема да килгәне юк иде.

Аның йөзендә үзен гаепле сизгән сыман көлемсерәү күренә иде.

Әхмәдинең дә хәле җиңелдән түгел иде. Аңа аяклары әллә ничек кенә, әллә нинди кодрәт белән генә атлыйлар, алар хәлсезләнеп, менә-менә төшеп калырлар кебек тосла иде. Ләкин ул, карт төлке, бик үк алга да узмыйча, бик үк артка да калмыйча, аякларны җай гына салып барганлыктан, көчен саклый алган, алда авыл күренгәч, хәтта ул башын күтәрә төшеп азрак телләнеп тә алды:

— Һәй, егет димәсәң, хәтерең калыр. Пешкән шалкан, төшкән калган ди безнең татар. Беләсеңме нигә шулай тиз арыйсың син? Көпшәк тәнле булганга! Нигә көпшәк тәнле син? Эшләми үскәнгә. Җир сөрмәгән, урман кисмәгән, кар көрәмәгән син. Гел өстәл арты да парта тирәсе. Менә шуңа күрә дә синең савырларың чүпрәк шикелле шәлперәеп кенә тора. Беләсеңме, андыйларны кызлар да бик үк яратып бетерми... Әһә! Ярыйсы гына авыл күренә бу... безгә эләксә...

Бөтенесен алдан белеп торырга, белеп җиткермәсә дә бик белдекле булып үзеннән өстәп сөйләргә яратучы Митричев монда да түзә алмады:

— Нигә эләкмәсен? Болай булгач, авыл безнеке инде! — дип куйды. — Димәк, Буденныйның атлы армиясе ак сволочьларны әнә тегендә, — ул кулын уңга сузып туплар тавышы ишетелгән якны күрсәтте, — камап алып кырып бетергән дә, алар Кырымга чигенә алмыйча калганнар.

Шәмсигә Митричевның шапырынуы ошамый, ул аңа хәзер ышанмый ук башлаган иде инде.

— Каян беләсең?

— Күрмисеңмени? Авыл тып-тын. Сыңар солдат та юк. О, барып кына җитик! Кайнар аш, галушки! Бәлкем әле...— Ул күз алдына китерү дә мөмкин булмаган тагын күп төрле рәхәтлекләр вәгъдә итеп күзен кысты: — Менә, әйткән иде Митричев диярсең...

Миша Борисовның талчыккан йөзендә елмаю шәүләсе чагылып узды. Шәмси аның күзләрендә балаларның шаянлыгына мыек астыннан гына карап елмаючы өлкән кешенең көлемсерәвен күрде.

— Эх, Петрусь! Әйтерсең, авызыңда хәзер үк кайнар галушки, кочагыңда матур кызлар...

Митричевның күзләре бик хәтәр ялтырап китте. Ләкин ул башкаларны бер дә тайчанмыйча сүгеп ташлый алса да, учительгә авыр сүз әйтергә аның теле бармыймы, ниме, нәрсәдер аны тыелырга мәҗбүр итәдер иде. Шулай да ул бирешергә теләмәде:

— Нәрсә, ышанмыйсыңмы әллә? Менә күрерсең. Әнә бит, бер кеше дә юк!

Тик Митричев мактанып кына бетерде, авылның уң ягындагы үр артыннан килеп чыккан ике-өч эскадрон чамасы атлының томырылып авылга таба чапканы күренде. Алар артыннан ук җәяүлеләр колоннасы калкып чыкты. Әхмәди күршесенең иңбашына сугып алды:

— Чәчелде синең галушкилар, Петрусь кода, безгә тәтемәде.

Митричев күзләрен елтыратып сүгенергә тотынды.

Төрле яктан команда тавышлары ишетелде, комбат атыннан төшеп батальонның алдына килеп чыкты. Ике батальон йөгерә-йөгерә юлның ике ягына таралырга да өлгермәде, аклар үр өстеннән ата да башладылар.

Уң канаттан рота командирының кул изәгәне күренде. Рота, сирәк көнбагыш сабаклары арасыннан посынгалап, алга үрмәли башлады.

Ләкин болар соңгарак калган булып чыкты, акларның ниндидер часте авылга кереп ныгыган икән, ул да аргы яктан ут учты. Атышның көчлесе авыл белән аклар арасын өзәргә дип туп-туры авыл читенә карап йөгергән шушы рота өстенә күчте.

Ышыкланыр урын юк, шәп-шәрә кырдан пулемет уты астында барырга туры килә иде. Әхмәди моңа бик борчылса да, яшьләргә сиздерәсе килмәде:

— Башланды, егетләр, башланды! Башыгызны саклагыз, фуражкагызга тиеп әрәм итмәсен!— дип сөйләнә-сөйләнә, Шәмси белән Борисов арасындагы ызанга кереп ятты.

Нигәдер бу яшь солдатларны ул башкаларга караганда якынрак күрә, әллә алар Әхмәдинең яшь чагын хәтерләтәләр, әллә шундый кыен вакытта аларны үз канаты астына аласы килә, әмма болар белән бергә булу

аңа рәхәтрәк иде. Әхмәди монда да сөйләшмичә түзә алмады.

— Безнең дә пушкабыз булса, мин әйтәм, менә хәзер аклар белән кети-кети уйнар идек. Иң элек әнә теге авылдан ата торган пулеметны тончыктырасы иде, аннары килеп, чиркәүнең манарасын чәнчелдереп төшерергә кирәк. Ник дисәң...

Әхмәди сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, сызгырып килгән снаряд нәкъ тезмә турысында ярылды да, сары ялкын чүмәләсе бөркеп, коточкыч шартлап картечь сиптерде. Монысы тынып җиткәнче, тагын берсенең чыелдавы ишетелде. Анысы ярылганда авылдагы бакча эченнән өченчесе улап чыкты. Шәмсигә җир өсте әнә шул шартлауларга түзә алмыйча бии, сикергәли, калтырана кебек тоела башлады.

Әхмәди, башын калкытып, Шәмсигә күз салды. Ул көрәге белән башын каплап, йөзтүбән сузылып яткан, бераз арткарак та калган иде. Әхмәди шикләнә калды:

— Әй, күрше, син нәрсә анда? Ул-бу юктыр бит?

— Белмим... юк бугай... Ай-яй шартлый...

— Шартлый? Их сине, малай актыгы. Төкер син аның шартлавына! Син алай сузылып ятма, үрмәләвеңне бел, алга тәгәрә!

Әхмәди сугышның дәһшәте астында каушап, үлем турындагы эчпошыргыч уйлар белән чуалу чорын, бар азаплардан да берьюлы котылу өчен, тизрәк үләсе килү чорын күптән үк уздырган; снаряд белән пуляларның тияргә тиешлеген генә түгел, киресенчә, тими узарга тиешлеген, тими калу мөмкинлекләрен дә күптән күздә тотарга өйрәнгән, һәртөрле шартларга тиз җайлашырга, хәзер, менә шушы урында, нишләргә кирәклекне бик тиз төшенергә гадәтләнгән карт сугышчы иде.

Ул аклар ягыннан күзен дә алмый кебек күренә, әмма күршеләрен дә бер генә минутка да күздән югалтмый иде. Борисовка борылып карауга, Әхмәдинең тагын чырае бозылды. Яшь сугышчының сумкасындагы китаплары аның күзе алдында тузгып һавага очты, Борисов үзе, агарынып, винтовкасын кочаклаган килеш, җиргә сыланды.

Вәлитов аңа ачуланып кычкырды:

— Син нәрсә кукраеп калкуга менеп яттың? Төш ызанга!

Егет, өзгәләнеп таралып яткан китапларыннан күзен ала алмастан, гаҗәпләнгән, каушаган кыяфәт белән үрмәләп ызанга төште, күшеккән куллары белән кабаланып винтовкасының затворын каккалый башлады. Әмма затвор һаман ачылмый, егет каушаганнан-каушый бара иде. Әхмәдинең тагын кәефе кырылды. Бу ике егетнең сугыш дәһшәтенә һаман да күнегеп җитә алмаулары аны бик борчый иде. Ул нидер әйтмәкче булып авызын ачканда, коточкыч шартлап, тагын картечь сибелде. Әхмәди абзыйсының алар өчен борчылуын, аңа нәрсәдер ошамавын Шәмси дә сизә иде. Ул аның тынычлыгына сокланып бетә алмый. Әнә бит йөгерергә хәзерләнеп, винтовкасын янына кыскан да, башын аз гына калкыта төшеп, күзен аклар ягына текәгән. Һәммәсен күрә, һәммәсен белеп тора.

Ул арада үрнең артыннан кинәт кенә акларның броневигы килеп чыкты. Ул, батальон өстенә пулеметтан пуля сиптереп, чабып йөри башлады.

Акларга Кырымга таба чигенер өчен башка юл юк, я шушы полкны сытып, изеп узу, я шунда кырылып бетү генә калган иде. Шунлыктан алар авыл янына килеп бөялгән бөтен көчләре белән берьюлы полк өстенә ыргытылып, аны берьюлы кырып узмакчы булдылар. Уннан артык пулеметлары төрлесе төрле урыннан ата башлады. Броневиклары, иңкел буенда чабып йөреп, әле бер батальонга, әле икенчесенә ташланды. Унтер-офицерлардан оешкан зур бер төркемнәре, шуышып килеп, атакага кузгалырга җыена иде...

Батальон командиры яланбаш килеш тезмәгә таба йөгереп килде. Акларның болайга таба үрмәләүләре күзенә чалынды. Ул ниндидер ярсулы чыелдык тавыш белән рота командирына кычкырды:

— Контратакага! Чигендерергә! Хәзер үк! Живо!

Пахомовның ротасы үрмәләп аклар өстенә барганда, пулеметын сөйрәп Митричев та килеп чыкты. Ул, тезмә арасыннан йөгереп узып, акларның үр кырыеннан якынлашып килгән беренче сафына ут ачты.

Аклар, ап-ачык җиргә килеп чыккан бу башсыз пулеметчыга каршы килә алмыйча, кашлак урында җиргә егылырга мәҗбүр булдылар. Алар арасында офицерларының, револьверларын айкап, нидер кычкырулары ишетелә; солдатларының, башларын яшереп, җиргә посулары, шулай да яңадан алга үрмәли башлаулары күренә иде.

Митричев, пулеметын тагын бераз алга сөйрәп, яңа лента куйды. Акларга күз салып, прицел рамкасын күчерде. Дошманны камыш урынына аяусыз кыйдыра ала торган шундый көчле машина аның кулында булуына горурланып, җай гына төймәне басты... Ләкин «максим» ул уйлаганча кистерә башламады, бер-ике шартлады да туктады.

— Ничек? Нишләп? Ни булды?

Бу хәл аның котын очырды: пулемет тәмам эштән чыгып туктаган булса? Югыйсә Митричев кулында чакта аның мондый гадәте юк иде бит...

Аклар моны сизеп кыюлана төштеләр. Аларның алдагылары, взвод артыннан взвод, йөгерә-йөгерә үрнең түбәнге итәгенә төшәргә тырышалар иде. Озакламый атака башланыр, әйе, атака... Әгәр аларга иңкелгә төшәргә ирек бирелсә, тагын берничә минуттан ротаның хәле кыл өстендә генә калачак...

Рота командирының ачулы тавышы ишетелде:

— Митричев! Огонь!

Әйтерсең лә Митричев аннан башка белми! Ул ачудан төкереп куйды.

Ул арада инде пулеметның атмавына башкаларның да эче поша башлады. Якында гына яткан Данилов:

— Җибәр тизрәк!—дип кычкырды.

Кайсыдыр сүгенеп тә алды:

— Әй, нәрсә йоклыйсың син анда?!

Митричев, зәһәрләнгән күзләре белән тишеп алырдай ачулы карап:

— Пош-шел ты к...—дип кычкырды.

Менә үр өстендә офицерларның команда тавышы ишетелде. Аклар гел якыная бардылар.

Як-яктан тагын түземсезләнеп кычкырдылар:

— Давай тизрәк, давай!

Митричев, ярсып, пулеметының капкачын ачып җибәрде. Ачып җибәрүе булды, өстеннән тау да төште. Бер начар пистонлы пуля туры килгән дә яньчелеп шул эшне бозган икән.

Ул, шатлыгыннан һәм оятыннан, ата-бабаларын, Иисусларын тезеп сүгенеп куйды. Шул ук секундта пулемет та эшли башлады.

Атакага килүчеләр бер өскә калкып, бер аска посып пулеметның мушкасы тирәсендә чайкалдылар. Митричев аларның сафларына, бер кырыйдан икенчесенә хәтле, пуля сиптерергә тотынды. Пулеметның тотенле

борыны белән бер-ике айкатып, «максим»ының житез һәм тигез тыкылдавына колак салды да, көе матур чыгуга шатланган гармончы шикелле, дәртләнеп кычкырып жибәрде:

— «Максимка», милый...

Мушка астына соры папахалар, авыр гәүдәләр коела иде.

Шәмсинең Митричевны сугыш эчендә болай якыннан күргәне юк иде әле. Менә хәзер ул онытылмаслык булып күз алдында сурәтләнеп калды: фуражкасының ертык козырегы артка борылып жилкәсенә терәлгән, жиргә таянган куллары пулемет аткан тибеш белән дерелдиләр, ботинкасының ертык табаныннан, песи борыны төсле кызарып, аяк бармагы карап тора... Ә ул ярсыганнан-ярсый барып, үзенең шушы ярсуы һәм «башсызлыгы» белән сокландырып, ата да ата иде.

Бераздан атака бөтенләй сүнде. Акларның исәннәре, кыр уртасында бер өем үләксә калдырап, абына-сөртенә артка чигенделәр.

Ләкин әле куанырга иртә иде. Рота командиры Пахомов тезмә артында яткан жиреннән аклар ягына бер күз ташлау белән хәлнең кискенлеген, дошманның күп яктан өстен булуын шундук күреп алды. Аклар үр артыннан чыгып гел өстәлә тора, алдынгы сафтагыларны яңа көчләр алмаштыра. Дошманның күп сандагы пулеметларына, броневикларына каршы куярга полкта төрле жиргә сибелгән иске-москы берничә «максим»нан башка юньле корал да юк, ни дә юк, аның өстенә сугышчылар эштән чыгып арыган иде.

Беренче төркемнәре чигенә башлауга аларның артыннан ук акларның әле генә килеп житкән яңа батальоннары калкып чыкты. Пахомов маузерын ала-ала тынычсызланып тезмә буенча күз йөртте. Мылтыклардан ата-ата көнбагыш сабаклары арасында яткан сугышчылары, беренче сафтагылар белән бергә үрмәләүче политрук Исмаев күзенә чалынды, күрше ротаның алдында батальон командирының кылыч айкаганы күренде. Яңадан атакага килүчеләргә күз салды. Вакыт!

Пахомов сикереп торды да маузерын болгап кычкырып жибәрде:

— Алга, алга! Ура!

Аяк астында Украинаның эссе кояшы һәм көзге кырач жиле белән киптерелгән үлән сабаклары кыштырдады, аклар ягыннан битләргә дары исе, көек исе килеп

бәрелде. Күпләрнең соңгы сулышлары белән бер секундта казылып, актарылып яткан снаряд чокырлары ешрак очрый башлады. Туп тавышлары гөрселди, өзлексез пулемет тыкылдый, колак төбендә пулялар өермәсе сызгыра иде. Ул да түгел, кара-каршы ыргытылган гранаталар гөрселдәшеп туктауга, гүя бу хәлгә хәйран калган, сыны каткандай, кинәт бөтен дөнья тынып калды: ике як, штыкларын төбәп, берсен-берсе чәнчергә җыенып, штык сугышына ташланды.

Ул арада наганнар пүкелдәшкәне, бер-берсенә бәрелеп штыклар чыйкылдаганы ишетелә башлады.

Борисов та, ярсып йөгерә торгач, шушы бер-берсен чәнчешкән, утын кискәндәгедәй эһелдәп бер-берсенә прикладлар белән бәрешкән соры төркем эченә атылып керде. Ул нашивкалы ике солдатның бер кызылармеец өстенә ташлануларын күрде дә, солдатның берсен үзенә каратып, чәкәләшергә тотынды. Тик ул як-ягына карарга да өлгерми калды, погонлылар аның үзен камап алдылар. Күзләрен кан баскан ике солдатның яссы штыклары аның күкрәгенә сузылды.

Каршыдагы солдат кизәнүгә Борисовның фуражкасы атылып төште, чәче тузгыды, кинәт яңагы кызып китте, иренендә тозлы кан тәмен сизде. Ул үзен эзәрлекли торган штык очларының әле бер якта, әле икенче якта елтырап китүен, дошманнарның, ерткыч җанвардай, аның өстенә сикерергә хәзерләнеп бөгелгән гәүдәләрен генә күрде, шуларны гына күзәтте.

Аның шинеле чишелеп китте, обмоткасы чуалды. Ярсудан, ачудан үзеннән-үзе җиңеләеп, гәүдәсен туптай очындырып, бер солдатка кадады да артка сикерде.

— Мә, паразит!

Сары чәчле, нашивкалы солдат, кайдадыр ябышырга теләгәндәй кулларын айкап, чалкан егылды...

Тик Борисов шул минутта ук күкрәгендә кинәт бер ачы сызлау сизде, сыкраумы, ачумы билгесе булып, аның чырае сытылды. Ул да түгел, аның йөрәге «жу» итеп китте. Әгәр «ул» ертылган булса? Штык аны да тишеп чыкса?!. Аның күкрәген, күкрәгендәге кесәсен, ул кесәдәге кечкенә рәсемне капшап карыйсы килде. Бармагына сөеклесенең йөрәк җылысы тияр, күз карашларыннан бөркелеп торган мәхәббәт ялкыны сизелер кебек иде. Шунда кинәт аның өзелеп-өзелеп яшисе килеп китте. Аһ, әгәр исән калса, ул моңарчы исенә дә кереп чыкмаган әлләниләр эшләр иде... Юк, бирешмәскә

мәскә кирәк! Дошманны, дошманны җибәрмәскә!.. Кайда булдылар соң әле аның иптәшләре?!. Нишләп күренмиләр? Ничек ул болар кулына ялгызы гына килеп эләкте?..

Бөтен рота актык көче белән сугыша, аның янында гына уһылдыйлар, тәннәргә салкын йөгертеп үлем ачысы белән кычкырып җибәрәләр. Тик Миша Борисов боларның берсен дә ишетә дә, күрә дә алырлык хәлдә түгел иде инде.

Шинелендә кан тимгеле киңрәк җәелгән саен, аның винтовкасы авырая барды. Ул тезләре дерелдәгәнне сизде. Кинәт кемнәр беләндер аңа таба йөгереп килгән политрук Исмаев күзенә чалынган шикелле күренде.

«Киләләр... менә хәзер килеп тә житәрләр...»

Ул арада каршысындагы погонлының штыгын читкә кагыйм дигәндә, аркасыннан нидер шытырдап кистереп керде. Дошманның арттан кадавы аның күңелендә иң соңгы хисне, нәфрәт хисен тудырды. Тәне ничектер оеп китте. Җир, айкалып, аңа таба авып төшкән кебек булды. Йөрәге, нидәндер курыккандай, кинәт калтыранып куйды. Тәненә кайдандыр кургашын авырлыгы коела башлады. Салкын авырлык, җиргә индерергә теләгәндәй, гел баса барды. Салкынайтты... Ул арада иң соңгы тойгылар да сүнде...

Караңгы күптән үк төшкән иде инде. Атыш гөрелтесе дә, һаман ерагая барып, тора-бара бөтенләй тынды.

Акларның атлысы һәм җәяүлесе, Кырымга таба чигенү юлларына аркылы төшкән бу полкны көч-хәл белән ерып, бик күп обозларын, орудиеләрен, хәтта бик күп үле солдатларын һәм яралыларын калдырып, юл өстендәге авылларны яндыра-җимерә Перекопка ташланды.

Даниловның взводы, дөресрәге, взводның исән калган сугышчылары, гәүдәләрен көч-хәл белән сөйрәп, авыл буендагы салам кибәннәре төбенә килеп егылдылар. Авылда аларга урын калмаган, анда өй эчләре генә түгел, өйаллары, ашлык амбарларына хәтле сугышчы белән тулган. Ишек алларында аяк басарга да урын юк, анда орудиеләр, пулеметлар, тачанкалар килеп бөялгән иде.

Кибән төбендә, яртылаш саламга күмелеп ятучылар арасында, бит-куллары ак марляга төренгән яралы ке-

шеләр күренгәли, тора торгач ыңгырашкан тавышлар ишетелгәли.

Күзенә көтүе белән килеп бөялгән, бөтен тәнен мәлҗерәткән йокыдан исереп, бүтәннәр арасында Шәмси дә ята. Ләкин йоклый алмый иде. Аның күз алдында погонлы солдатлар айкала, штык очлары ялтырап китә, ачыргаланып кычкырган йөрәк яргыч ачы тавышлар ишетелә. Шәмси аның саен күзен ныграк йома, онытылырга тырыша иде. Ләкин Борисовның таш төсле зәңгәрсу-саргылт маңгае, күгәреп каткан күм-күк иреннәре, авыз кырыеннан кызыл җеп булып сузылган кан эзе күз алдына килүгә, ул әллә ничәнче тапкыр сикереп торды.

— Әхмәди абзый!..

Вәлитов бераз селкенде, бәйләгән кулын кузгатып ыңгырашып куйды, әмма күзен ачмады.

Авылның чиркәве кайгылы бер басынкылык белән, озак көттереп, чаң суга башлады. Чаң тавышы салкында туңып ыңгырашканга охшый, моңаеп, сагышланып нәрсәдәндер зарлана, кемгәдер тирән нәфрәт белән рәнҗи кебек ишетелде. Шәмси кибән төбендәге иптәшләренең ыңгырашуларына, туңып уһылдап куюларына колак салды да авыр сулап яңадан ятты. Тик шунда ук тагын торып эчке кесәсендәге кечкенә рәсемне капшап карады. Күмәр алдыннан политрук бу көләч кызның рәсемен, Мишаның күкрәк кесәсеннән алып, Шәмсигә биргән иде.

— Әниләренә җибәрерсең, хат язарсың...

Шәмсигә хәзер бу кыз алдында бик уңайсыз иде. Аңа ни язарга, ни дип җавап бирергә? Нигә болай килеп чыкты, ничек абайламый калдылар, ничек болай күз алдында харап иттеләр соң әле Мишаны?..

Болар күргәндә Борисов винтовкасын көч-хәл белән генә күтәреп тора, хәлсезләнеп як-якка чайкала иде. Аралары ун-унбиш адым гына иде бит, өч-дүрт кенә сикерәсе иде. Әхмәди абзасы теге солдатның үзен дә бәреп екты егуын, тик ул вакытта Миша бөгәрләнеп төшкән иде инде.

Шәмси Әхмәди абзасына таба борылып ятты да аның шинель якасына пышылдады:

— Их, бер генә минут алдан күргән булсак...

Вәлитов өстендәге саламын чөеп ыргытты, җенләнеп торып утырды.

— Я, нигә мыжылдыйсың? Нигә дип минем йөрә-

гемне талыйсын?!. Сугышчымы син, әллә... юеш танаулы елак малаймы? Ә?!. Монда әбиеңә кунакка килдем дип беләсеңмени?..

Әхмәди мылтыгын икенче кулына алды да, ачу белән «дерт» итеп, Шәмсигә арты белән борылып ятты. Саламда бик озак кыштырданды, аягын аякка какты, уһылдап куйгалады.

Авылда берөзлексез кое сиртмәләре чыелдады, кайдадыр бик еракта, дошман качып киткән якта, тонык кына туплар гөрселдәгәне ишетелеп торды. Шәмси авыр сулап уф орып куйды, мылтыгын аяклары арасына кыстырды, шинель якасын күтәрде дә, Әхмәди абзасының аркасына борынын төртеп, тынып калды.

V

Караңгы кыр юлыннан тын гына бер төркем сугышчы атлый. Үр өстенә күтәрелгән чакта, якты болытлар җирлегендә, аларның шәүләләре күренеп кала да иңкелгә төшкәч, тагын күренмәс була. Ара-тирә каты көзге юлда аяк кыштырдаганы ишетелгәли, берәрсе йөткереп куя, я, үзләре генә ишетелерлек итеп, акрын гына сөйләшкәләп алалар.

Иң алда, рота командиры Пахомов белән Исмаев арасында, юан таякка таянган калын гәүдәле бер карт бара. Ул, украинлылар «кожух» дип йөртә торган кыска кайры тунының кыек кесәсенә кулын яшергән килеш, бөтен гомерен юл йөреп уздырган кешедәй, салмак һәм җайлы атлый, аның йомшак тире чабатасының хәтта кыштырдаганы да ишетелми. Карт дигәннәре ара-тирә кечкенә челемен авызыннан алып төкереп куя, аннары яңадан авызына каба да гыжылдатып тагын суыра башлый. Аның челеменнән чыккан яхшы тәмәке исе Исмаевның авыз суын китерә, хәтта башын әйләндерә, ләкин Пахомов алдында карттан тәмәке сорарга аның кыюлыгы җитми иде. Хәер, яктырмыйча барыбер тәмәке тартып булмас иде бит. Ярамый. Дошман бәлки шушы тирәдә генә сагалап торадыр? Әмма Исмаевны да, башкаларны да иң кызыктырганы картның хуш исле тәмәкесе түгел, бәлки үзе, Кырымның партизан оешмасыннан килгән кеше булуы иде. Тик сөйләшергә һаман җай чыкмый иде әле. Полк штабында картны Пахомов ротасына тапшырганда Исмаев аның ирененең ике кырыеннан асылынып төшкән калын чал мыегын

да бакыр балдак белән кыршаулаган кечкенә челемең генә күреп калган иде. Менә хәзер аның бик беләсе килә: бу карт фронт аша ничек чыга алган, нинди яшерен хәбәрләр алып килгән, Сивашка ничек юл табарга уйлый икән? Ләкин рота командиры әле һаман суза, һаман сораштырмый. Нәрсә көтә, ничек түзеп барадыр бу, шайтан белсен!..

Ниһаять, Пахомов, авыз эченнән генә нидер сөйләнеп, кул сәгатен күзләренә китерде, беләзегендә зәңгәрсу чаткы җемелдәп китте, аннары күк йөзенә каранды. Бер якта болытлар арасыннан, кыюсыз җемелдәп, җидегән йолдызның койрыгы күренә. Битләргә дымлы салкыны белән ышкылып, каршыдан салмак җил исә иде.

Пахомов башы белән алга таба ымлады:

— Бу сезнең яктан инде, ә?

Карт еш-еш челемен суырып алды, нидер иснәгәндәй итте, як-ягына, аннан күккә карады. Шуннан соң гына җавап бирде:

— Белмәссең... Бик дымсу шикелле болай. Диңгез ягыннандырмы...

Моны ишетүгә барысы да, телләрдән төшмичә сөйләнә торган Кырым ягын күрергә теләгәндәй, алдагы караңгылыкка текәлделәр. Исмаевка ул якта нindидер бер зәңгәрсу яктылык балкыган кебек күренде. Аның артыңа ук ышыкланып атлаучы Шәмсинең үтә сизгер, ис сизүчән борыны бу дымлы җилдә диңгез буенда үсә торган нindидер нәфис гөлләр, иснәп туймаслык чәчәкләр хуш исен сизгәндәй булды. Вәлитов исә, шыпыртлап:

— Кара әле, җилләренә хәтле алма-хөрмә исе кушылган түгелме соң? Борынны кытыклыйсы килә,— дип куйды.

Ниһаять, Исмаев үзе сораштыра башламыйча түзә алмады. Полк комиссары аңа бу картның бик куанычлы хәбәрләр алып килүен әйткән иде. Кырымның урманлы тауларында, бигрәк тә Ай-Петри тирәсендә көчле партизан отрядлары оешкан. Коммунистларның Севастополь һәм Симферополь кебек зур шәһәрләрдәге яшерен оешмалары да Врангель гаскәренә каршы аяусыз көрәш алып баралар икән. Менә бу карттан шуларның һәммәсе турында да ишетәсе килә иде.

— Сез үзегез Кырымның үзеннәнме, әллә бу яктан, Украинадан барган кешеме?

Челемен суыра торгач, карт бик каты йөткерергә тотынды, бераздан, сулыш ала алмыйча, гыжылдап туктады.

— Аз гына... ял итеп алмыйбызмы?

Пахомов юл кырыендагы көнбагыш сабаклары чүмәләсе янына барып туктады. Бераз тын алганнан соң партизан карт, Исмаевка ымлап, көлемсерәп куйды:

— Күрәм, бу карт зимагурны сөйләтәсегез бик килә... Аңлыйм, сезгә кызык, кайдан килеп чыккан бу карт, нинди карт? Әйе бит?

Сугышчылар, берсеннән-берсе уздырырга ашыгып, башларын селектеләр:

— Дөрес, шулай, бик беләсебез килә. Бик!

Карт йомшак украин телендә акрын гына, җайлап кына сөйләп китте:

— Мин үзем Сиваш буенда туган кеше. Яшьрәк чагымда чумак * булып та йөргәләдем. Сивашта тоз чыгарырга да туры килгәләде. Төрлесен татыдык.

Бу күбесе өчен яңалык иде.

— Әле шулай дамыни? Сивашта тоз да чыгамыни әле? Ә безнең Идел буенда хәзер тоз кытлыгы... Бер кашыгы әллә ничә мең тора дип язалар...

Шәмси, олылардан узып әңгәмәгә кушылуына уңайсызланудан, кинәт кенә туктап калды.

Карт дәвам итте:

— ...Әйе, чыга. Аның суында тоз күп. Сивашны безнең тирәдә «каһәр төшкән сазлык» диләр, я «Черек диңгез» дип тә йөртәләр. Нигә алай? Үзе шундый, Сивашның тозлы суы үләннең тамырын корыта, җан иясенең канын агулый. Кайчакны карап торасың: Сиваш турысында көтүе-көтүе белән киек казлар, торналар очып йөри. Еректан зур су булып күренә бит ул. Кошлар сусыннарын кайтарырга дип килгән булалар да, кая ул, шунда ук кире китәләр. Сиваш суы бит эчәргә ярамый!

— Ә, сәер икән!

Сугышчыларның барыннан да бигрәк Сивашны кичеп чыгу мөмкинлеген беләселәре килә иде.

— Сивашны диңгез култыгы диләр. Ә үзеннән кайчагында җәяүләп тә чыгып була икән. Бик сәер бит. Нинди соң ул?

---

* Чумак — йөк белән йөрүчеләрне ул тирәдә элек шулай атаганнар.

— Ә миңа бер карт,— диде Данилов,— көз көне Сивашның суы кипкәнен үз гомеремдә ике тапкыр гына күрдем, дип сөйләде.

— Шулай булгач нигә соң аннан көймә белән чыгып булмый икән?

Бу сүзләрдән соң Данило карт, балаларының үзләре белмәгән, ләкин аларны бик кызыктырган нәрсәләр турында бәхәсләшүләрен тынлап утырган иркен күңелле атадай, елмаеп куйды.

— Хлопцы,— диде,— сез дөрес әйтәсез. Читтән килүче булсам, мин дә шулай гаҗәпләнгән булыр идем.

Картның сөйләвен йотлыгып тыңлыйлар иде.

— Ул бит Азов диңгезенә тоташкан. Диңгез ягыннан җил истеме, аңа су тула. Җил диңгез ягына таба борылдымы, су кире чигенә. Ул чагында инде Сиваш кереп булмастай сазга әйләнә.

— Хәзер нәрсә соң әле ул, сазмы, диңгезме?

— Хәзергә саз әле. Әмма озаккамы, түгелме, анысын тагын да әйтеп булмый. Диңгездән җил исә башладымы, ул берничә сәгать эчендә котырынган диңгез култыгына әйләнә. Аның өстеннән ак башлы диңгез дулкыннары чабыша башлый. Саз вакытында да ул бик үк юаш түгел. Кайбер урыннарда шундый упкыннары очрый, анда аяк баскан кеше бервакытта да исән котыла алмый, суыра, йота, берәр сәгатьтән син анда кешенең үзен түгел, эзен дә таба алмыйсың.

Исмаев барысын да кызыксындырган бу зур мәсьәләне тизрәк ачыкландырырга ашыкты:

— Шулай да, Данило бабай, Сиваштан ничек чыгарга булыр икән соң, син ничек уйлыйсың?— диде.

Карт бераз вакытка тагын сүзсез калды. Дивизия штабында аннан Кырым ягына гаскәр белән чыгарлык юл эзләшүне үтенгәннәр иде. Карт моны ишеткәч үк сизеп алды. Әһә! Кызылларның Фрунзе дигән генералы Перекопның артына шыпырт кына бәреп чыгарга уйлый икән! Шушындый зур эшне Данило карт шатланып өстенә алса да, елның бу вакытында Сиваш суының кире чигенүе бик сирәк булганлыктан, борчулы иде. Ничә мең тере кеше, никадәр корал бит ул! Абайламастан читкә тайпылсаң? Караңгыда ялгыш юлга кереп китеп сугышчыларны харап итсәң?..

— Моңа хәтле беркемнең дә Сивашның сез әйткән урыныннан гаскәр белән чыкканы юк. Ничек дип әйтергә...

— Анысы шулай. Әмма моңа хәтле большевикларга Сиваш аша чыгарга кирәк булганы да юк иде бит, Данило Михеевич!

Политрукның мондый тапкыр җавабы картны күңеллеләндереп җибәрде. Ул, утырган урынында селкенгәләп, политрукның аркасыннан сөйде.

— Дөрес, улым! Син бик тапкыр әйттең. Мин большевикларга ышанам.

Пахомов үзалдына гына көлемсерәп куйды. «Кара син аны!Ниләр ычкындыра! Я, я, үткенлә телеңне, тиктормас! Синең бит һөнәрең шул». Пахомовка үзенең әле әйткәне ошаганлыкны сизеп алгач, Исмаев әңгәмә белән тагын да кыюрак идарә итә башлады.

— Данило Михеевич,— диде,— сез бит Кырым партизаннары ягыннан чыккан кеше, шулай бит? Безнең егетләрнең бик беләселәре килә: ничегрәк анда эшләр? Аклар бик нык утыраларамы? Партизаннар ничек?

Карт акрын гына тамак кырып куйды. «Алар да ишетсен иде» дигәндәй, әйләнә-тирәсендә тезелеп утырган кызылармеецларга карап алды. Тик монда кычкырып сөйләшергә ярамаганлыгы исенә төшеп, акрын гына башлады:

— Мин анда, шулай кирәк булганга күрә, ярты ел чамасы урман каравылчысы булып эшләдем. Әле күптән түгел партизаннар кичен урмандагы мин яшәгән кордонга җыелдылар. Башлыклары чал чәчле, батыр сынлы бер кеше. «Иван Петрович» дип йөртәбез. Берәүләр әйтә, сөргендә булган, ди, икенчеләре, патша атарга хөкем иткән кеше, ди.

Бераздан карасак, шәһәр ягыннан килә торган юлны гаскәр баскан. Акларның җәяүлеләре, атлылары тузан кубарып монда таба чабалар. Партизаннар, Врангель гаскәрен фронттан алдырып, монда алдап китерү өчен, отрядларын бик зур итеп күрсәткәннәр икән... Мин партизаннарны яшерен сукмаклардан Ай-Тодор өстендәге урманлы тау кырыена алып чыктым. Аклар юлның тар урынына килеп тыгылгач, әлеге Иван Петрович яшеренгән урыннан кычкырмасынмы: «Батальон, пли!» Сизәсеңме нишли? Ә партизаннар нибары егерме сигез генә кеше иде.

Данило карт акрын гына кеткелдәп алды, йонлач бүреген арткарак этәреп куйды.

— Аклар нишләделәр соң?

— Нишләсеннәр? Алар тау арасында сугыша бел-

миләр икән, чуалышып беттеләр. Офицерлары аткалаган булып та маташтылар, тик барыбер эш чыгара алмадылар. Мәетләрен, атларын калдырып, кире чаптылар.

Уң якта туп аткан тавыш ишетелде, ул кайдадыр, бик еракта гы карангылык эчендә, авыр һәм озак гөрселдәп торды. Пахомов, кузгалырга вакыт икәнлеген сиздереп, аягүрә басты. Аның артыннан бүтәннәр дә атлый башладылар.

Данилов:

— Перекоптадыр инде бу,— диде.

Карт башын чайкады:

— Юк, түгел. Бу үндарак. Диңгездән аталар... Акларның Перекоп култыгында сугыш корабльләре бар бит.

Аннан бераз бирерәк, гүя әле генә йокысыннан уянган карт этнең кабаланып өрә башлавы шикелле, ашыгып, ярсып кольт пулеметы тыкылдарга тотынды.

— Менә монысы Перекоп тирәсендәме инде?

— Әйе, монысы Перекопта!

Әле анда берни дә күренерлек булмаса да, Перекоп исеме телгә алынгач, һәммәсе шул якка карый башладылар. Менә кайда икән ул... Пулемет, тегү машинасы кебек салмак кына тыкылдап, таң алды сорылыгы эчендә нидер һаман тектерде.

Берсе, гүя үзенә-үзе әйткәндәй:

— Алай, менә Перекопка да якынлашып киләбез...— диде.

Данило карт, дошманга шактый ук якынайганны абайлап, монда инде кычкырып сөйләргә ярамаганны бик нык төшенгәндәй, ярым пышылдап, бая башлаган сүзен дәвам иттерде:

— Менә шулай. Таулар арасында хәзер берничә партизан отряды бар. Сез Перекопта сугыша башлаганда, алар акларның тылларын җимереп кермәкче булып калдылар... Ә, начар булмастыр бу!

Тагын бераз барганнан соң сулда, күк кырыендагы болыт төркеме югары төшеп, аннан таң алсулыгы күренде. Баягы җил, яшь таңны каршыларга барган сыман, акрын гына, иркә генә уңнан исә башлады. Карт, җилгә каршы торып, иснәп карады, кулын күтәреп, җилнең көчен чамалады. Аннары, тагын да күнеллеләнеп:

— Безнең Кырымның җилләре, кич булдымы, йокларга яталар,— дип әйтеп куйды.— Хәзер менә аларның

торыр чаклары җитте. Шулай да, бәхетле кешеләр сез, большевиклар. Кырымның халкы гына түгел, җилләре дә сезнең яклы булырга чамалый.

— Нигә алай дисез, Данило Михеевич?

— Мин әйтмим, җил үзе әйтә. Перекоптан таңга карап искән җил — ул бәхет җиле. Ул суны Сиваштан диңгезгә куып чыгарачак.

— Әһә! Алай булгач, Сиваштан бәлки җәяү дә чыгып булыр әле, ә, Данило Михеевич?

Данило карт җавап бирергә ашыкмады. Бик көттереп кенә:

— Анысын инде баргач күрербез, улым, хәзер юрап торуның мәгънәсе юк! — дип әйтеп куйды.

Көн тагын да яктыра төште. Көнчыгыш ягы алсуланды, күк кырые матур буяулар белән бизәлде. Бу вакытта әлеге төркем, сөзәк үрне узып, Сиваш иңкеленә таба төшә башлаган иде.

Данило карт кулы белән алга күрсәтте:

— Әнә Перекоп!

Ул якта, Сиваш инкеленнән бераз ундарак, түбә урында бер-берсенә сыенышып куе гына утырган аксыл йортлар өеме күренде. Шәһәр өстеннән бердәнбер чиркәүнең ничектер җимерелми калган биек манарасы калкып тора. Шәһәрнең бу кырыендагы уйсулыкта һәр авылда дистәләп очрый торган әлеге шул сиртмәле кое.

Политрук, бинокльдән бераз карап торганнан соң, кулын селтәде:

— Бер дә искитәрлек урыны юк икән. Шәһәр димәсәң хәтере калыр, урта кул авылдан һич тә зур түгел,— диде.

Ләкин хикмәт шәһәрнең күләмендә түгел, бәлки аның ныгытмаларында икәнлеген күбесе белә иде. Ул турыда күп сүз булды. Перекопка диңгездән ярым җир асты юллары бар, имеш, кирәк чакта диңгездән су кертеп дошман гаскәрен батыралар, имеш...

Пахомов политрукның бинокльен үзенә алды:

— Син алай ашыкма әле,— диде.— Перекоп турында сөйләнгәннәрнең дөрес өлеше дә бар. Әнә күрәсез бит, ул табигый яктан да бик җайлы урында. Аны чит ил инженерлары, бигрәк тә французлар, соңгы вакытта тагын да ныгыттылар. Чит ил сугыш белгечләре аны «ала алмаслык крепость» дип атыйлар. Шундый ул. Перекопны җиңел генә алу турында уйларга да яра-

мый. Монда бик күп кан коелуы мөмкин. Бик күп! Беләсезме нәрсә ул Перекоп? Кырымның капкасы ул! Аның әнә уң ягында Кара диңгез култыгы, икенче ягында — Сиваш. Кырымга башка юл юк.— Командир сул якны күрсәтте: — Әнә тегендә Сиваш була бит инде, Данило Михеевич?

Карт, кечкенә зәңгәрсу күзләрен кыса төшеп, озак кына карады да башы белән ымлады:

— Әйе, шул, үзе! Әнә кайларга таба сузылып киткән!

Сиваш дигәннәре Перекоп яныннан ук башлана икән. Ул, түбәндә диңгезгә таба киткән саен киңәя барып, ике якта да култыклар, ярымутраулар ясап уза. Көнчыгышта, чамасын билгеләү кыен булган ераклыкны бөтенләе белән биләп, диңгез сыман киң мәйданга җәелә. Хәзер ул бу кырыйдагы биек ярыннан — томан эчендә аз гына калкып күренгән теге яктагы соры утрауларга кадәр, Перекоп шәһәреннән башлап кояшның сары нурлары сибелгән көнчыгыш ягына кадәр ак томан белән мөлдерәмә тулган иде.

Перекоп ныгытмаларындагы шомлы тынлыкка колак салып бераз карап торганнан соң, Пахомов башы белән ымлап әйтеп куйды:

— Нинди тын! Әйтерсең, ул биек валларның артында беркем дә, бернәрсә дә юк, әйтерсең, анда йомраннар оясы гына. Тик сез ялгыша күрмәгез! Менә күрерсез, озак та үтмәс, бүген булмаса иртәгә, анда зилзилә кубар, җир тетрәтеп орудиеләр, пулеметлар үкерә башлар. Авыр булыр моны алуы, әйе, җиңел булмас...— Командир, ниндидер уйларына җавап эзләгәндәй, кашларын җыергалап бераз тынып торды.— Ләкин ни генә булса да безгә ул кара баронның якасыннан алырга кирәк. Фрунзеның махсус приказы бар. Ишеткәнегез бармы? Безнең командующиебыз.

Карт:

— Әйе, әйе, ничек ишеткәнем булмасын? Аны бөтен җирдә беләләр,— дип куйды.

— Алайса бик яхшы. Ул әйтә: сугышны берничек тә кышка калдырмаска, Врангельне быел, менә хәзер бетерергә!

Карт челем сабын мыек чылгыена тидергәләп алды.

— Мм. Врангельнең дә әйткән сүзе бар: безнең армиябез Кырымда тыныч кына кышлар да, яз көне без, алла боерса, яңадан Мәскәүгә поход башларбыз, ди. Газеталарында шулай яздылар.

— Ха, мактанчык та соң инде! Үтмәсә үтмәс икән бу генералларның туң башына! Әйтерсең, соңгы өч елны йоклап уздырганнар да хәзер генә уянганнар!..

Исмаев, кара күзләрен елтыратып, томан астында яткан Сиваш ягына ымлады:

— Менә бу сазны гына чыгыйк, без ул кара сволочька кайда кышлыйсын күрсәтербез. Чалбарын кияргә дә өлгерә алмый калыр. Әйе бит, Данило Михеевич!

Карт юан таягын тукылдатып башын игәләде, кидер әле генә исенә төшкәндәй, кабалана башлады:

— Әйе, әйе. Тик без хәзер ашыга төшик әле. Безгә тизрәк кичү табарга кирәк. Киттек, оланнар, барыйк.

Данило карт текә генә сулга борылып юлдашларын кечкенә үзәннәр һәм ермаклар эченнән Сиваш ярына таба алып китте. Ул да түгел, аларның артларыннан үкереп килгән броневик белән җиңел автомобиль чокыр-чакыр арасыннан айкала-чайкала барып, болардан ерак түгел бер урында туктап калды. Броневиктан өстенә гади солдат шинеле, башына соры папаха кигән калын коңгырт мыеклы бер командир килеп чыкты.

Пахомов кинәт үзгәреп китте. Сугышчылар эшнең нидә икәнен абайлап өлгергәнче, ул үкчәләрен бер-берсенә «шык» иттереп бәрде дә «смирно» басты, аның уң кулы, күптәнге гадәте буенча, үзеннән-үзе папахасына күтәрелде.

Исмаев, чем-кара күзләрен зур ачып:

— Беләсезме, иптәш Фрунзе бит бу!— дип пышылдады.

Сугышчылар, яшен тизлеге белән мылтыкларын кулларына алып, якаларын, фуражкаларын төзәткәләделәр дә, икешәр күз белән генә түгел, дүртәр, сигезәр күз белән күрердәй булып, Фрунзега текәлделәр. Менә нинди икән ул Фрунзе! Дүрт-биш юлдашы белән нинди хәтәр урынга килеп чыккан. Үзенең коралы да юк бугай әле.

Фрунзе да аларны күреп алды. Көтелмәгәнчә гади, бераз карлыкканрак йомшак тавыш белән:

— Исәнмесез, иптәшләр!— диде.

Сугышчылар калынлы-нечкәле тавышлар белән, шулай да шактый ук батыр тонда:

— Исәнмесез, иптәш командующий!— дип җавап бирделәр.

— Кайсы полктан? Кая киттегез?

— 132 нче полктан, иптәш командующий, Сивашка разведкага барабыз.

— Әһә! Бик кирәк, бик яхшы!

Ул нечкә каеш белән иңенә эленгән биноклен күзенә китереп теге як ярга текәлде. Ул якны томан аша бик аз гына абайларга мөмкин иде. Аннан ара-тирә туп тавышлары ишетелгәли, анда-санда ниндидер утлар кабынып киткәли иде. Фрунзе биноклен күзеннән алды да кулы белән ишарә итте. Автомобиль арткарак чигенеп, үзәнгә төште дә күренмәс булды. Фрунзе Сивашның аргы ягына караган килеш тагын бераз уйланып торды.

— Алай... Тик ятмыйлар, димәк, көтәләр...

Шунда ук сугышчылар арасындагы партизанны күреп алды, аның уйчан йөзе кинәт яктырып китте. Картның кем булуын аңа әйткәннәр иде, күрәсең. Фрунзе аңа ачык чырай белән кулын сузды:

— Исәнмесез! — диде.— Сез Сивашны яхшы беләторгансыз инде. Сезнеңчә, бу турыдан теге якка кадәр ничә чакрым булыр?

Карт, әчпошыргыч рәвештә акрын кыймылдап, Сивашка таба борылды, байтак кына көттергәннән соң:

— Безнеңчә, ун чакрым чамасы булса кирәк, — диде.

— Гаклы чакрымнармы, әллә бу юлы гаксыз гынамы?

Карт ничек җавап бирергә белмичә күзен ачалак-йомалак китереп торганда, башкалар көлешеп алдылар. Командующийның шундый ачык чырайлы, гади кеше булуы Пахомовны рәхәтләндереп җибәрде. Элекке генераллар алтын ялтыравыгы белән күзне камаштыра, таштан койган салкын чырае, ата күркәдәй кабарынган кыяфәте белән тынычны куыра иде. Өстенә гади солдат шинеле, аягына таза солдат итеге кигән бу сөйкемле кешенең исә коңгырт-яшел күзләре сине кеше буларак санга алып, хәтта якын итеп елмая, аның талчыккан йөзеннән, бөтен кыяфәтеннән ниндидер бер җылылык, ягымлылык нуры сирпелә кебек. Пахомовка бу зур дәрәҗәле кешенең менә шул ягы аеруча ошады. Беренче империалистик сугыш башланганнан бирле һаман приказ теле, команда теле белән генә эш итеп үзеннән-үзе кырыслана төшкән, ничектер коргаксый башлаган солдат кабыгыннан чыгып, аңа кешеләрчә, гади тормыштагыча үз итеп, якын итеп Михаил Васильевич дип дәшәсе, көндәлек утырып калган юшкыннар, шик-шөбһәләр турында сөйләшәсе, сорашасы килә башлады. Тик бу көнелнең бер омтылышы гына, үзенә күрә бер эреп китүе

генә, әле хәзер аның вакыты да, урыны да түгеллеген Пахомов үзе дә белә иде.

Командующий кулын сузуга аның артында торучы кызыл түбәле озын кара папаха кигән, кара күн пальто өстеннән зур револьвер таккан адъютант Фрунзега җитез генә карта бирде. Командующий циркуль белән үлчәгән арада Пахомов аның күз кабаклары бераз җилсенгән, күзләренең кызарган булуын күреп алды.

Ул арада Фрунзе бер картага, бер Сивашка карыйкарый үлчәп бетерде дә картаны адъютантына кире бирде:

— Нәкъ сигез чакрым...— диде.— Ләкин нинди кичү була бит әле. Ярый, хушыгыз. Кичүне тизрәк табарга тырышыгыз. Шулай да бик алай күз алдында йөрмәгез. Сезгә уңыш телим.

Разведкага баручылар, Фрунзега борылып карыйкарый, партизан карт артыннан яр буйлап түбәнгә төшеп киттеләр.

Пахомов бераз киткәч үзалдына башын чайкап куйды:

— Әйбәт кеше командующий, яхшы күңелле кеше. Мин аның кайсы академияне тәмамлавын хәтерләмим, әмма чыраеннан ук күренеп тора, зур тәрбия алган укымышлы кеше. Шуның өстенә бик акыллы кеше.

Политрук Исмаев үзе белән янәшә баручы Даниловка күз кысып алды. «Сизәсеңме, янәсе, кай тирәдә йөри әңгәмә!..»

Данило Михеевич, яр буендагы тар сукмакта атлый торгач, кире борылып туктады.

— Дөрес анысы, зур укыган булыр. Белеме зур булмаса, үзенә каршы чыккан генералларны алай барысын бер куньнчка тыга алмас иде. Тик, минемчә, ул безнең шикелле буразнадан күтәрелгән кешедер. Нигә димсез? Җиргә бик нык басып тора, нәкъ крестьянча.

Исмаев, әңгәмәнең бик җайлы башланып китүенә, монда ул да үзенең кем булуын бик шәп күрсәтәчәгенә алдан ук куанып, тамагын кырып куйды, йомшак кына тавыш белән:

— Иптәш командир,— дигән булды.— Сез беләсездер инде, патша армиясендә шушындый зур фронтның командующие ни дәрәҗәдәге генерал булган булыр иде?

Пахомов, бу елтыр күз кайларга тыгылмакчы була тагын дигәндәй, политрукка күз кырые белән карап алды.

— Соң? Әйтик, беләм ди.

— Менә, менә! Алайса безнең командующий шуларның иң зурысы инде. Колчак адмирал иде бит! Аның муенын борып ыргыттымы? Ыргытты! Җыен вәзирләре, корбашилары, Англиядән килгән генераллары белән Бохара әмирен эссе табага бастырдымы? Бастырды! Менә кем ул безнең командующий! Ә үзенә утыз биш кенә яшь! Беләсеңме ничә тел белә ул? Әллә ничәне! Казахча, кыргызча, русча, инглизчә, тагын әллә кемнәрчә...

Данило Михеевич башын чайкап куйды:

— Ай, ай, ай! Башлы да кеше икән. Әйтәм бит бик зур укыгандыр дип...

Исмаев, кара күзләрен елтыратып, рухланып сөйли, ул Фрунзеның кайбер башка командирлар кебек аксөяк нәселеннән булмыйча, бәлки иң гади халыктан чыккан фельдшер малае булуы белән дә, үзенең «политический» мәсьәләләрне «кайберәүләрдән» күбрәк белүе белән дә мактанмыйча түзә алмый, шунда бер уңайдан монарчы үзе белән исәпләшмичәрәк йөрүче, үзен үзе шактый югары тотучы командирның да борынына чиертәсе килә иде.

— Зур укыган, укымыйча! Академия гынамы әле! Большевиклар университетын бетереп чыккан кеше ул.

— А, кара син, ә! Берәр чит илдә булганмы инде ул университет дигәнегез?

Политрук Даниловка күз кысып алды. «Чиерттеме?» янәсе.

— Юк, патша төрмәсендә! Аның да үлем камерасында. Беләсегез килсә, патшаның хәрби суды аны ике тапкыр асарга хөкем иткән. Фрунзе ике ай ярым буена үлем көтүчеләр камерасында яткан. Үлем көтеп, кайчан асарлар икән дип! Берәү булса елап утырыр, я васыятьләрен язар иде. Ә бу нишләгән? Патша судының хөкеменә төкереп торып инглиз телен өйрәнергә тотынган. Өйрәнмәс иде, кирәк буласы! Әйтик, озакламыйча бөтен дөньяда революция башланды, ди. Беләсез бит инде, офицерлар, элекке генераллар алар бит күбесе буржуйлар яклы. Ә монда пролетариатка үз командующие кирәк, большевик кирәк, ышанычлы кеше! Менә шул чакны бөтен дөнья пролетариаты алдына чыгып баса да бирепме бирә команданы! Кайда нинди телдә кирәк: Англиядә башланса — инглизчә, Германиядә булса — немецча... Франциядә тагын да үз теле...

Данилов политрукның җиңеннән тартып колагына пышылдады:

— Тыя төш такылдавыгыңны! Тәртәләреңне кайда сузасың?

Исмаев, бераз арттырыбрак җибәрүен үзе дә сизенеп, каш астыннан гына Пахомовка карады. Рота командиры, алдына гына караган килеш, көлемсерәп бара иде.

Бу вакытта алар үзенең билгесез һәм шомлы яклары белән ышанырга да, ышанмаска да белмәстәй табышмаклар тудырган серле Сивашның яр буена ук төшеп җиткәннәр иде.

VI

Авылда көн буе хәзерләнделәр.

Дивизия штабы Сиваш яры өстендәге җимеш бакчасына, андагы балчык өйгә урнашты.

Авылга иртә таңнан башлап берсе артыннан берсе өзлексез төрле хәрби частьлар агылып торды. Болар арасында күпчелеге җәяүле, калганнары исә атлылар, тупчылар, саперлар иде.

Башта өй эчләре тулды. Бер өйгә утызар-кырыгар кеше кереп, басып торыр урын калмый башлады. Өйләрнең ишек-тәрәзәләреннән пар бөркелде. Тора-бара ишек алларында да урын тарайды. Соңрак килгәннәр инде урамда гына туктый башладылар. Бакчаларга, тыкрыкларга поход кухнялары, орудиеләр, төрле арбалар, тачанкалар килеп бөялде. Орудие тәгәрмәчләренә, җил капкаларга, санитар арбаларына бәйләнгән атларга солы урынына арпа, печән урынына Сиваш буенда тозлы дым белән сугарылып үскән чәнечкеле кәрлә үлән салынды. Алар тирәсендә юынмаган битле, кырылмаган сакаллы, ачы җилдә озак йөрүдән күзләре кызарган, һәрбер сүзләрендә, хәрәкәтләрендә зур эшкә хәзерләнү, эчке дулкынлану сизелеп торган меңнәрчә сугышчылар кайнаша иде. Поход кухнялары, урамнарны төтенләтеп, итле аш һәм карабодай боткасы пешерергә тотынды. Койма буйларында, бәрәңге бакчаларында, бәс бәйләнгән агач төпләрендә таган астылар. Һәркайда ашау-эчү, ямау, көйләнү, төзәтенү хәстәре күрелде. Ун градус тирәсенә төшкән салкынга түземлеге бетеп, шакыраеп каткан арыш икмәген, бүкәнгә куеп, балта белән ваттылар. «Бу кемгә?»не кычкырттылар. Шунда ук, аягүрә генә торып, өшегән икмәкне ашый да башладылар. Шулай ук итеп шикәр дә, яртышар пачка махорка да бүленде. Лапас артларына, арба асларына, тирес кой-

маларга ышыкланып, әле генә бирелгән җылы күлмәкләрне киделәр; шинельләренә каптырма тактылар. Барасы юл ерак та, пычрак та икәне беленгәч, караңгыда төшеп-нитеп калмагае дип, ботинка олтаннарын телефон чыбыгы белән беркетеп куйдылар.

Башка кирәк-яраклар да онытылмады. Брезент сумкаларга, патронташларга әле генә өләшенгән патрон салынды, янга шешә сыман икешәр-өчәр граната тагылды. Һәр взводның берәр отделениесенә сугышчы саен тимер чыбык кисә торган озын, зур кайчылар бирделәр.

Хәзерләнеп беткәннәре, шинель якаларын күтәреп, учак янында кырын яткан килеш тыныч кына әңгәмә корып җибәрде. Сүз арасында кинәт кенә тынып калып:

— Андый-мондый булсам... нитәрсең инде, туган, өйдәгеләргә язарсың: шулай-шулай булды, фәлән урында җирләдек диярсең,— дип, бер-берсенә өй адресларын бирештеләр.

Тагын берничә сәгатьтән соң менә мондагы халыкның азымы, күбеме үләргә тиешлеген, батып калырга, я булмаса башкача, һәлак булуы мөмкинлеген, аларның актык көннәре, актык мәртәбә сөйләшүләре икәнлеген һәркем исендә тота иде. Хәтта үзенең дә шул кешеләр арасында булуы ихтималын да исеннән чыгара алмый. Тик ул шул ук вакытта, кояшның кич булгач баюы, иртән яңадан килеп чыгуына ышанган шикелле үк, үзенең исән калырга, яшәргә, сугышның бүген-иртәгә бетәргә тиешлегенә дә ышана, болар һәммәсе бик табигый бер төс алганга күрә, берәү дә аһ-ваһ килми, һәркем тыныч кына тәмәкесен тарта, тыныч кына кузгалганны көтә иде.

Разведкадан кайтучыларга кечкенә генә булса да бер өй калдырганнар икән. Боларга өйне күрсәтүче квартирьер *:

— Тагын бер ун минут соңга калсагыз, квартирадан колак кага идегез. Бик кыенлык белән генә саклап калдым,— диде.

Ишек алдының тирә-ягы киртәсез, урталыгы егылып төшсә, чыпчык башы ярылырлык — шәп-шәрә, бер кырыйда тәбәнәк кенә балчык өй. Аның стеналары касмакланып купкан, шунлыктан ул, кырык ямаулы иске чикмән төсле, алама булып күренә. Сыңар тәрәзәнең бака

* Квартирьер — гаскәрне квартирага урнаштырып йөрүче.

кашыгы төсле утлы-яшелле өч өлгесе өчесе өч якка кылайган. Дүртенчесе урынына яктылык үткәрүдә күршеләреннән аз кайтыш булган көнбагыш башы кыстырганнар.

Өй буенда йомарланып йокымсырап яткан салпы колаклы сары эт, ишек алдына бер төркем сугышчылар килеп кергәч, иренеп кенә башын калкытты. Яхшымы-яманмы, һәр йортның үз эте булырга, ул чит кешегә өйалдына кереп югалганчы өрергә, я ырылдап калырга тиеш булганлыктан гына, берничә тапкыр өреп алды. Аның болай каршы алуына керүчеләрнең исе китмәгәч, ризасызлык белән бер чыелдап, күзен йомар-йоммас тагын йокымсырый башлады. Тегеләр өйгә керделәр.

Йорт хуҗасы булган әбинең мондый кунакларны беренче каршы алуы түгел иде, күрәсең. Гүя ул сугышчыларның атналар буе кайнар аш татып карамавын да, аркаларындагы капчыкларының буп-буш булуын да — һәммәсен дә алдан ук белеп торган. Әби, сугышчылар кереп җитүгә, түр почмактагы өстәлгә зур табак белән әлеге дә баягы шул галушкины китерде, күпереп торган ике күмәчне телемнәргә турады:

— Ашагыз, хлопцы, ашагыз,— диде.

Бәхетлеләр урындыкка эләктеләр. Калганнарына басып кына ашарга туры килде. Әби мич буена сөялгән килеш, табак белән авыз арасында ялт-йолт уйнап торган кашыкларга күз салып, елмаеп торды. Ул арада күмәч өеме, күз алдында эри барып, әби икенче карaганчы, бөтенләй юк булды. Карчык өченче күмәчне китерде. Мин капкачы яңадан ачылды. Аннан, зур чуен белән, сөттә пешкән хуш исле кайнар бәрәңге килеп чыкты.

Әбинең нәкъ менә шушы егетләр кебек яшь кенә бер улы бар икән. Врангель офицерлары, чигенә башлагач та, әбинең улын, аты-ние белән, олауга алып киткәннәр. Әби йортта соры песие белән үзе генә калган. Моннан бер атна чамасы элек аның улының бричкасына офицер хатыны белән зур авызлы дәү бер эт утыртып Сивашка таба узуын күрше авылныкылар күреп калганнар. Шуннан соң исәне-үлесе турында бер хәбәр дә ишетелми, ди. Әбинең улы озын буйлы, сары чәчле икән. Әгәр ак дуңгызлар үзләре белән диңгез артына алып китмәгән булсалар, бәлки ул кызыл солдатларга да очрар. Кайдан беләсең, бәлки... исән калган булса... Карчык, сөйләнә торгач, бераз балавыз да сыгып алды. Кызылармеецлар аны, сугышның озакламый бетәчәге турында сөйләп,

юатырга тырыштылар. Сугыш беткәч, малаең да кайтыр, диделәр. Карчык, күзен сөрткәләп:

— Бетерегез инде, хлопцы, сугышны, җитәр инде. Бик күп кан коелды бит инде. Минем улым да кайтыр иде бәлки,— диде.

Соңгы атналарда акларның үкчәләренә баса-баса куып барганлыктан, көннәр, төннәр походта, сугышта узган иде. Атналар буенча, ашык-пошык кайнатылган, төтен тәме килә торган кайнар су һәм берәр кисәк сохари белән генә тукланып йөрелде. Санап бетергесез чакрымнарны узган, кантарлар арасында, көзге янгырда, юеш окопларда, туп чокырларында аунаган өс-баш һәм аяк киемнәре туздыы, ертылгалап бетте. Соңгы тапкыр мунча керү, былтыр күргән төш сыман, күптән онытылган иде инде. Кешеләр каралдылар. Аларның сакалмыек баскан битләрендә кызарган күзләре, юкарган борыннары гына күренеп калган иде.

Җылы өйгә кереп тамак туйдырып алганнан соң, ничектер барысының да тазарынасы, юынасы, җиңеләеп каласы килә башлады. Хәер, бүген көне дә шундый, аеруча бер тантаналы көн, күңелләр күтәренке көн иде. Политрук Исмаев өй саен кереп Октябрьның өч еллыгы белән котлап йөрде, сугышчыларга тылдан килгән бүләкләрне өләште. Кемгә җылы күлмәк, кемгә исле сабын, тәмәке, я папирос.

Күңелләрнең дулкынлы, йөрәкләрнең ашкынулы булуына тагын бер сәбәп бар иде. Ул турыда беркем дә ачык кына итеп сөйләми, әмма һәркем аны истә тота, һәр сугышчы үзенчә иң элек шуңа хәзерләнә, хәтта уйнаганда-көлгәндә дә ул аны исеннән чыгармый. Алай гына да түгел, һәр сугышчы барыннан да бигрәк шуңа хәзерләнә, иң якты өметләрен шуңа баглап, шактый ук дулкынланып шуны — төнге сугышны, иң соңгы сугышны көтә иде.

Шунлыктан өстәл янынная кузгалуга төзәтенү, яману, кырыну, күптән көтелгән әлеге шул зур эшләргә хәстәрләнүдән китте. Кайсы кая урнашып, һәркем үз эшенә керешге. Капчык төпләреннән пәке, кайчы, бритва шикелле солдат кирәк-яраклары чыкты, фуражка кырыена кадалган энәләр эшкә кушылды.

Шәмси тез башына куеп кына, карандашының очын тешли-тешли, Нәсимәсенә кечтеки генә хат язып ташлады:

«...Каз өмәсенә кайтып җитәрсең бәлки, дигәнсең икән дә, кайтып булмас ахрысы, Нәсимә, үпкәләмә, җаныем. Вакыты ул түгел. Аклардан бер генә генерал калган бит инде дигәнсең диюен дә, беләсең килсә, бер булса да берәгәйлесе калган. Әнә, Кырым бутылкасы эченә кереп алган да бик яман гайрәт чәчеп ята. Анда бәреп керәсе бар, ул кара йөрәкнең муенын борып ыргытасы бар. Менә шул контрны җиңик, Кырым безнеке булсын, аннары менә кайтсаң да оят булмас. Ә хәзергә — бигайбә. Икенче хатны, исән калсам, сугыштан соң, Кырымнан язармын. Бүген таңда сугышка керергә торабыз. Бик, бик сагындым үзеңне. Күндезләрен күз алдымда, кичен төшкә керәсең. Ярый, җаныем, исән бул. Моннан соң бәлки хатым тиз булмас...»

Әйтәсе сүзләре бик күп иде әле. Байтак кына вакыт, тәрәзәгә караган килеш, уйланып, Нәсимәсен күз алдына китереп утырды. Каз өмәседер... Нәсимә, киенеп-ясанып, кыр казлары шикелле иптәш кызлары белән берсе артыннан берсе тезелеп, юргалый-юргалый, тау астындагы чишмәдән су китерәдер... Ә кичен алар янына егетләр керер, Нәсимә янында бүтән бер егет утырыр... Шәмси авыр сулап куйды да иптәшләренә таба борылып утырды.

Әхмәди: «Көрәк хәтле сакал миңа пычагыма кирәкмени?» — дип, күптән үк зарланып йөри иде. Хәзер кырынмакчы булды.

Шинелен салып, гимнастерка белән генә калгач, сәерсенеп, иңбашларын җыергалады, күкрәген, билләрен капшап карады; айлар буенча өстән төшмәгән шинельне салгач, тәне бик сәер булып, бөтенләй җиңеләеп калган иде.

Шәмсидән кечкенә генә көзге ватыгын алды, аны ашыкмыйча гына чалбарына ышкып, битен карады. Аңа кызарган, шешенгән күзле, конгырт сакал баскан йонлач бер бит күренде. Ул кәефсезләнеп, кашын җимерде:

— Тфү! Кара инде бу битне! Урманда-мазарда шушындый йолкышны очратсам, мин аны... валлаһи дип әйтәм...

Аннан соң ул, сөйләнә-сөйләнә, кырынырга тотынды. Ул арада Шәмсигә күзе төште дә, шаяртырга шул җитә калды:

—Ниләр актарынасың анда, Шәмси туган? — дигән булды.— Беләсеңме, безнең Шәмси, паегына тигән махоркасы белән дуңгыз мае салган боткасын шикәргә алыштыра торгач, баеп бетте бит! Аның капчыгында хәзер елан мөгезе генә юктыр. Чын. Өйгә кайткач монысы фәлән эшкә ярар дип, әллә нәрсәләр җыя торгандыр әле, борынгы денщиклар шикелле, баеп кайтмакчыдыр. Шулай түгелме, Шәмси?

Шәмси бик җитди кыяфәт белән обмоткасын ямарга керешкән иде. Борылып кына карады да авыз чите белән генә көлеп куйды:

— Әйдә, тарттыр тегермәнеңне, тарттыр! Оны чыкмаса чыкмас, анысы чорт с ним!..

Әхмәди, песи табаны хәтле көзгесе каршысында кырына-кырына, шаяртуында дәвам итте:

— Син төпчек ул бугай әле, Шәмси, әйе бит? Төпчек улны әниләр бик якын күрә торган була бит. Чын. Менә син монда чүпрәк ямап утырасың, ә анаң коймак пешерә торгандыр. Бүген җомга көн бит! Татарча атна көн. Әйе. Коймак пешергәндә табагачын юллыкта болгыйдыр, «Улым, кайт!» дип кычкырадыр. Шулай иткәч, тизрәк кайтырга насыйп була, ди.

Барысы да шаулашып бер көлешеп алдылар.

— Әмма тел үзеңдә,— диде Митричев.

— Бәй, яратканга шаяртам бит мин, энекәйләрем, якын иткәнгә. Белмәссең, бик ошап китсә, исән-сау сугышны бетереп кайткач, Шәмсигә кызымны бирергәме әллә дибрәк тә йөрим әле мин. Ык буенда юачалар, җиләк-җимешләр генә ашап үскән бик тә чибәр кызым бар минем.

Кайсыдыр:

— Кияү, кияү! — дип кычкырып җибәрде.

Данилов, уены-чыны белән:

— Юк, юк! — дип кычкырды.— Нигә егетнең күңеленә шик саласыз?! Мин беләм, Шәмсинең сөйгән кызы бар. Тимәгез, ике куянның койрыгын тотам дип, Нәсимәсеннән колак какмасын!

Шәмси эшен ташлап авызын ерган килеш, рәхәтләнеп тыңлый иде. Сакаллы, бала-чагалы бу олы кешеләрнең, сугыш вакытында аяусызлыктан башканы белмәгән бу таш йөрәкле, каты куллы сугышчыларның, монда, җылы өй эчендә, кием-салымнарының гына түгел, үзләренең дә бөтенләй чишелеп китүләре Шәмсине рәхәтләндереп җибәрде. Ул сикереп торды да җилтерәп барып

Әхмәдинең каршысына килеп басты, уены-чыны белән кулын сузды:

— Вәгъдәме?

— Нәрсәгә?

— Кызыңны ярәшергә?

Әхмәди булачак кияүне башыннан аягына кадәр карап чыкты да бот чабып көләргә тотынды:

— Кара әле бу калай әтәчне! Ансат кына өйләнеп ташламакчы, ә! Вәгъдәме, имеш! Кыз бирүне бозау сату дип белгәнме? Бәй, егет булсаң, башта җолаларын китер: бер балагын читегеннән асылындырып, икенче балагын читек кунычына кыстырып бик шәптән бер яучы җибәр. Күпме мәһәр бирәсеңне әйт; өч бикле, кыңгыраулы калай сандыгыңда чәмчәле читек белән бер пар кәвеш булсын, ике кәшәмир күлмәк белән Орынбур шәл булсын, бишмәтлек, хәтфә камзуллык булсын. Менә шуннан соң уйлап карасa карар Әхмәди абзаң!

Шәмси, кулын селтәп, кире урынына барып утырды.

— Һи, шулкадәр мәһәр биргәч, мин «кыдыл бодау» * ягыннан өйләнеп тә тормыйм, камыт аяклы булса да, Казан баеның кызына өйләнәм.

Шау-шуга, көлешүгә Митричев килеп кушылды:

— Ә, синең купец кияве булыргамыни исәп? Әйткән ди бит анда сезнең бер князь: «Мы казанский сын купца. Держим три лафка. Одна лафка два булафка, другой лафка сам сидим, третий лафка гуляйт ходим».

Тагын шаулашып көлеп алдылар.

Әхмәди, бераз уйланып утырганнан соң, көзге кисәге белән бритвасын кулына тоткан килеш, иптәшләренә таба әйләнеп утырды. Бу вакытта аның сөйкемле генә озынча бите сабын күбегеннән арынып килә, ул яшәребрәк киткәндәй күренә иде. Шушы көлешү, шау-шулар аның күңелен күтәреп җибәрделәр булса кирәк, тагын нидер әйтәсе килүе күренә иде.

— Эх, егетләр! Сезнең урында булсам, беләсезме нишләр идем мин сугыш беткәч?! Китәр идем укырга, командир булырга. Дөнья күреп, илләр гизеп йөрү, Кызыл Армиянең командиры булу үзе ни тора! Ул бит, энекәйләрем, элек безгә тәтемәде. Фәлән авылдан фәлән агайның улы, әйтик, дивизия командирына укып чыкса, ә? Без бит аны хәзер булдыра алабыз. Чын. Әйтәм

---

* «Кыдыл бодау» ягы — «з» урынына «зәл» куллланучы көнчыгыш ягын элегрәк шаяртып шулай атыйлар иде.

бит, әгәр яшем утызның түбән ягында булса, аннары сугышта кәкрәеп калмасам, зур командир булмыйча авылга аяк та басмас идем. Яңа тормыш шуны сорый, энекәшләр. Күтәрелергә кирәк безгә. Һәммәсен дә үзебезнең кулга алырга! Менә ничек бит ул, энекәшләр...

Данилов идәндәге саламда кырын ята иде, торып сары көдрәләрен саламнан арындыра-арындыра:

— Дөрес әйтәсең, туганкай,— диде.— Сугыш бетүгә, барыбызга да эш муеннан булачак. Берәүләр армиядә калыр, берәүләр укырга китәр. Ә мин сезнең һәммәгезне дә үзебезнең Донбасска чакырам. Вәгъдәме? Менә кайда җәеп җибәрергә була колачны! Шахтер буласың киләме? Рәхим ит! Укып инженер, я механик буласың киләме? Анысына да ярдәм итәрбез. Чыннан, әйдәгез, туганнар, безнең Донбасска!

Шәмси сүзгә кушылып:

— Донбасс бик шәптер анысы, сүз дә юк,— диде.— Безнең татарлар да бик күп анда, бик мактыйлар да, баеп та кайталар. Шулай да, авылда да эш күп бит хәзер. Сугыш белән ачлык илне әнә ничек бөлдерде. Күреп йөрисез бит, әнә анда көн саен никадәр ат кырыла, никадәр терлек-туар әрәм була. Хәзер безгә бик күп итеп иген үстерергә, терлек үрчетергә кирәк... Һи! Крестьянны аякка бастырганчы әле!.. Менә безнең кавалерист ни әйтер тагын...

Митричев, иреннәрен пешерә-пешерә тәмәке төпчеге суырып, лежанка миче каршында кызынып утыра иде. Боларның әңгәмәсенә сул кулын гына селтәде:

— Мескеннәр, бичаралар! — дип куйды.— Канатыгыз юк бит сезнең, ичмасам, хыяллана да белмисез, мукәләп кенә яшисез бит сез. Тере килеш шушы яшемнән әрлән шикелле җир астында казынаммы соң мин, я менә бу малай кебек буразна корты булырга кызыгаммы?! Юк! Сугыш беттеме, барам Буденныйга да әйтәм: «Семен Михайлович! Ал мине кавалериягә! Бөтен дөнья буржуйларына каршы җибәр, барам, йөз Махнога каршы берүземне җибәр, анда да курыкмыйм, барам! Тик мине үз яныңа гына ал!..» Эх! Астында шыгыр-шыгыр иткән яхшы ияр, янында кылыч, билеңдә маузер...

Данилов, нәкъ Митричев тавышы белән:

— Кесәң тулы борчак!..— дип өстәп җибәрүгә бөтен өй эче гөрләп көләргә тотынды.

Ул арада Вәлитов та кырынып бетте. Иптәшләренә борылып:

— Я, Донбасска да барып кайттык, бутылкалы кызыл чалбарлар киеп, кавалерист та булып алдык,— диде.— Хәзер инде Әхмәди абзагызның битенә смотр ясагыз, кай җире килмәгән?

Аны, тәрәзә янына алып барып, әйләндерә-әйләндерә карагач, һәйбәт кырынган дип мактадылар. Әхмәди мыекларын бөтергәләп, кыскарып калган сакалын сыйпап, әйбәтләп куйды.

Кырынып, ямангаинан соң, әби кайнатып куйган җылы су белән юынып өс-башны да алмашып җибәргәч, үзләрен җиңеләеп һәм яшәреп киткәндәй сизә башладылар.

Әхмәди тәмәке төрергә тотынды, шунда, сүз арасында:

Украина,
Хлебородная,
Хлеб беляки отобрали,
Сама голодная...—

дип такмаклап та алды.

— Дөрес бит, хозяйка?

Әби карчык, лежанкадагы соры песие янына утырып көнбагыш ашый, боларның гәпләренә кушылмаса да, көлешкәндә аларның күңеллелегенә бирелеп, елмайгалап куя иде.

— Дөрес,— диде.— Аклар безнең ашлыкны гына түгел, терлегебезне дә таладылар. Кая куеп бетергәннәрдер аны...

— Кая куйсын? Сезнең байлыкны биреп үзегезне дә, безне дә үтерер өчен чит ил буржуйларыннан корал алдылар!

— Шуның өчен дә без аларның кирәген бирәбез. Ул килмешәкләрнең монда иң актык мәртәбә аяк басулары булыр!

— Сезнең якны мин үзем бик яраттым,— диде Әхмәди.— Ни чәчсәң, шул үсә. Халкы да бик яхшы. Булды шундый чаклар, менә сезнең шикелле иркен күңелле украинкалар ач чагында безгә актык сыныгын бирде, походта арып-талып, эсселектән әлсерәп узып барганда, татлы суын эчерде, көзге салкын төннәрдә җылы өендә йоклатты, туганнары кебек якын итте. Бик шәп халык.

---

* «Украина — икмәкле як. Икмәген аклар талап алды, үзе ач калды».

Иле дә бик матур, һич тел тидерә торган түгел. Шулай да мин сездә бер нәрсәне ошатып бетермәдем...

— Беләбез, мунчалары юк.

— Дөрес. Юынырга мунчагыз, чәй эчәргә самоварыгыз юк. Менә минем кәҗәле булганыма ике-өч кенә ел, сыерның миндә үзе түгел, ишек алдында эзе дә булганы юк, ә самоварым бар. Дөрес, шәптән түгел түгелен, борыны да кәкрәйгән, кабыргасы да бераз яньчелгән, шулай булса да — бар. Тормышмыни ул самоварсыз?!

Тагын бераздан өй эче тына төште. Кайсы-берсе, идәндәге саламга сузылып, черем итеп алырга булды, Митричев кебек мутраклары, бары белән спайланып-төзәтенеп, кызлар тирәсендә чуалырга чыгып китте.

Өстен-башын төзәткәләп, бил каешын ныграк буып Шәмси дә урамга чыкты. Алар Казанның Игумный урманында солдат уены уйнаганда Митәй исемле бер чуваш егете белән танышканнар иде. Шәмси күрше ротага шул әшнәсен эзләп китте. Урамдагы исәпсез-сансыз пушкалар, тачанкалар, пулеметлар арасыннан борыласарыла ул шактый ук озак сорашып йөрде. Ниһаять, пулеметын майлаштырып яткан бер сугышчы аңа тыкрык башындагы шәп каралтылы зур бер йортны күрсәтте.

Шәмси барып кергәндә, аның әшнәсе Митәй, лапас астындагы арба үрәчәсеннән аякларын салындырып, винтовкасын тазартып утыра иде. Шәмсине күрүгә, ул сикереп төште. Аның какча ябык чырае яктырып китте.

— Һа, якташ килә бит, якташ!

— Исәнме, Митәй!

— Саумы, Шәмси!

Авыл егетләречә алмаш-тилмәш бик озаклап кул кысышканнан соң, Шәмси аның янына утырды да винтовкасын тазартыша башлады. Чувашларның күбесе шикелле үк, Митәй дә татарчага оста иде. Алар бик тәмләп сөйләшергә тотындылар. Авылдан килгән хатларда туганнары ниләр язуын да, иген уңышлары ничек булуын да, бүтәннәрне дә телгә алдылар. Аннары полктагы хәлләргә күчеп, Врангель армиясенең күпме гомере калуын исәпләп чыгардылар, чама белән сугышның кайчан бетәсен дә билгеләп куйдылар.

Бу әңгәмә бәлки озакка да сузылган булыр иде, әмма күрше йортның зур сараендагы хәрәкәт егетләрнең игътибарын үзенә тартты. Алар коймадагы ярыктан

сарай эченә күз салдылар. Анда полк комиссары Карпов белән берничә политрук үзара ни турындадыр сөйләшеп торалар иде. Алар янына берсе артыннан икенчесе бүтән коммунистлар да җыела башлады. Данилов белән Исмаев да шунда иде.

Шәмси әшнәсе Митәйнең җиңеннән тартты:

— Әйдә киттек, Митәй. Монда коммунистларның җыелышы буласы икән. Яхшы түгел.

Митәй елмаеп аңа күз кысты:

— Я, печтик кенә тыңлыйк инде. Без дә бит чит кешеләр түгел. Каян беләсең, бәлки үзебез дә коммунистка языларбыз әле.

Шәмси, бүтән берни дә әйтмичә, Митәй шикелле үк коймага елышып тыңлый башлады.

Комиссар, кайры туны өстеннән буган бил каешына әледән-әле тотынгалап һәм уң кулын айкаштырып, кайнарланып Октябрь революциясенең өченче еллыгы турында сөйли иде. Кызу сөйләгәнлектән, Шәмси комиссар әйткәннәрнең һәммәсен дә аңлап житкерә алмады. Әмма бер яңалыкны бик яхшы төшенде: полкның коммунистлары бу зур бәйрәмне ничектер үзләренчә билгеләп үтәргә җыеналар икән. Коммунистлар шуны хәзер үк һәр кызылармеецка житкерергә тиешләр. Анда да тегеләй-болай гына түгел, моның әһәмиятен һәм шулай кирәклеген һәр сугышчы үзенең йөрәге белән аңларга тиеш.

Кинәт Шәмсигә Данилов нәкъ аңа текәлеп тора кебек тоелды да, ул җәһәт кенә читкә тайпылды. Күрдеме икәнни соң? Шәмси сак кына Митәйнең икенче ягына чыкты. Юк, Данилов аңа түгел, комиссарга текәлгән икән. Комиссар Карпов хәзер инде ниндидер коммунистлар отряды турында сөйли башлаган иде. Шундук Митәй дә Шәмсине үзенә табарак тартып ым какты: яхшырак тыңла, янәсе. Алар комиссарның һәр сүзен йотардай булып, тыннарын да алмыйча ярыкка сарылдылар.

— Безнең командующийга, димәк, иптәш Фрунзега, беләсезме Ленин нәрсә әйткән? Врангельне Кырымда кышларга калдыру Совет власте өчен үлем куркынычы белән бер, дигән. Чөнки әгәр Врангель Кырымга кереп бикләнсә, аның армиясе исән калачак. Аннан да битрәк, ул вакытта Кырым бөтен дөнья империализмының Советлар иленә һөҗүм итү өчен җайлы плацдармына әвереләчәк. Менә нәрсәдән сакланырга кирәк! Шундый хәл

булмасын өчен нишләргә куша Ленин? Акларның армиясен менә шушы бәйрәм көннәрендә үк кырып салырга кирәк! Аңлашыламы? Иптәш Фрунзе әмере дә шулай. Әйе! Бүген төнлә без акларның тылына бәреп керергә тиешбез. Алдан коммунистлар барачак, дошманга иң беренче булып алар ташланачак!..

Митәй күзен елтыратып әшнәсенең колагына пышылдады:

— Аңладыңмы? Безнең турыда Ленин үзе уйлый икән? Кара син аны, һәммәсен күреп, һәммәсен белеп тора? Их, Шәмси, синең белән без бераз уйлап житкермәгәнбез. Элегрәк безгә дә коммунист булып язылась калган икән. Менә хәзер без дә шулар белән киткән булыр идек.

Ике егет, берәр нәрсәгә сөртенмәгәек, тавыш чыгармагаек дип сак кына атлый-атлый, лапас астыннан чыктылар да урам буйлап киттеләр. Малайлыктан чыгып житмәгән бу ике яшь егетне әле генә ишеткән яңалык бик дулкынландырган иде. Алар иң зур сугыш серен үзләре генә белүгә горурланып як-якларына тәкәббер генә караналар, елмаеп бер-берсенә ым кагалар. Әйтерсең, күрмәгәйләр иде дип әле генә койма буена посып тыңлаган кешеләр бөтенләй алар да түгел.

Озак та үтмәде, аларның артыннан Данилов белән Исмаев та килеп життеләр. Нигәдер аларның чырае караңгы, кашлары жыерылган иде. Нигә алай икән? Аларның бит хәзер иң куанычлы вакытлары булырга тиеш. Ләкин Митәй белән Шәмсигә бу турыда гәпләшеп алырга туры килмәде. Данилов кинәт кенә борылды да ачуланып кычкырды:

— Нишләп йөрисез монда сөрән сугып? Марш үз роталарыгызга!

Егетләр, тегене-моны әйтмәстән, шыпырт кына тайдылар. Исмаев көлеп жибәрде. Бераз тын торганнан соң, ул өзелгән әңгәмәне яңадан ялгап жибәрде:

— Борчылма, Гриша. Әле өметне өзеп бетерергә ярамый.

Данилов караңгы чырай белән генә:

— Нәрсә инде... әйтте бит,— диде.— Тагын нишли аласың?

— Әйдә полк командирына керәбез!

— Комиссардан зарланыргамы?

— Юк, нигә зарланырга? Без үз теләгебезне генә әйтербез.

Алар шундук кире борылдылар да стенасына зәңгәрсу каз сурәте белән чәчәкләр төшерелгән биек ак өйгә таба атладылар.

Исмаев белән Данилов кунак өенә кергәндә, полк командиры Кириченко, френч якаларын чишеп җибәргән хәлдә, өстәлгә җәелгән картага караган килеш уйланып утыра иде. Аның уйларыннан аерыласы килми иде, күрәсең. Ул теләр-теләмәс кенә башын күтәрде:

— Я, нәрсә әйтмәкче буласыз?

Данилов аңардан Исмаев белән икесенә коммунистлар отрядына керергә рөхсәт итүен үтенде.

— Минем урынга Бачилоны калдырырга мөмкин. Ул менә дигән тәҗрибәле сугышчы.

Командир җавап бирергә ашыкмады. Ул аларның икесенә дә озак кына сыный карап торды. Аннары картага күз салды. Караватка салып ташлаган шинель кесәсенә үрелеп папирос алды.

— Комиссар ни әйтә соң?

Исмаев белән Данилов бер-берсенә карашып алдылар. Менә бит кайдан китереп эләктерде!

— Иптәш комиссар җибәрми. Ул үз ротагызда каласыз, ди. Әмма без коммунистлар булганлыктан...

Командир, кулын күтәреп, туктарга ишарә итте:

— Комиссар дөрес әйтә,— диде.— Роталарда калган коммунистларга җиңел булыр дип уйлыйсызмы әллә? Шулай булмыймы соң! — Ул яңадан картага карап алды.— Сиваш аркылы чыгу уен эш түгел. Бик хәвефле, хәтәр операция бу! Шундый кыен вакытта кем сугышчыларның рухын күтәрер? Кем аларга батырлык, кыюлык үрнәге күрсәтер? Билгеле инде, сез, коммунистлар! Сезнең урыныгыз сугышчылар янында булырга тиеш! Менә шулай!

Өйдә калганнар янына, кулына хат тотып, Данилов кайтып керде. Аңа төрле яктан куллар сузылды:

— Кемгә?

Данилов, хатны артына яшереп:

— Кем иң зарыгып көткән булса, шуңар! — диде.

Вәлитов, ышаныр-ышанмас, әмма күңеле нидер сизеп:

— Алай булгач миңа! — дип кычкырды.

Хат чыннан да аңа икән.

Әхмәдинең өеннән хат алмавына байтак вакыт булган иде. Ул үзе рәттән берничә хат язса да, җавап кил-

мәде дә килмәде. Төрле шикләр, шомлы уйлар аны өзлексез мазасызлап тордылар.

Инде юньле хәбәр алудан өмет өзеп, кайгы хәбәрләре көткәндә, менә бәхет! Ул озак йөрүдән читләре киселә башлаган соры конвертны кабаланып ачарга тотынды. Шунда бармакларының дерелдәвен күрде. «Нәрсә яздылар икән? Үлем-житем юкмы икән?» Итәгенә ике саргылт кәгазь кисәге килеп төшүгә, ул аларны тирән дулкынлану белән кулына алды. Бу кәгазьләр матча ярыгына кыстырылып озак торганга шулай саргайганнар бит. Алардан аның өенең исе, аның үзенә генә билгеле бер якын ис килгән сыман. Таушалган бу саргылт кәгазьләр аңа хатыны Галимәсен, күптән бирле юньләп күрергә җай килмәгән олы кызын, ике бөртек кечкенәләрен, гөл чәчәкләрен, күз нурларын хәтерләтәләр...

Әле генә яуган кар өстендәге тавык эзедәй чытырман бизәкле, чолгап-чолгап язылган хатка түземсезлек белән күз йөртеп чыкты. Бу серле сызыкларга озаграк карап торган саен, тынычсызлана, шиге зурая барды; икенче яктан, түземсезлеге дә көчәйде.

Ниһаять, икеләнеп торды да Шәмсине йокысыннан уятып, хатны аңа тоттырды.

— Укы әле, энем, мә әле!

Шәмси, күзен угалап, җайлабрак утырды, хатны караштыргач, башын чайкап куйды:

— Ай-яй. Әмма кулы да кул икән! Ташка үлчим. Мәзин-мазар булыр бу, бер дә бүтән түгел, я элекке перкәшшек.

— Әйдә, күп сайрама, энекәш! Анысы — чорт с ним! Укый бир!

Шәмси, «Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү хәләл җефетемез Әхмәдигә...» дип башлап китте дә, бала-чагадан, туган-тумачадан, кардәш-ырудан, ил картларыннан «күптин-күп, чукдин-чук» сәламнәрне бик озын итеп тезеп барганнан соң, ниһаять, көч-хәл белән тормыш хәлләренә килеп җитте.

Вәлитов, Шәмси янына идәнгә утырып, аның авызыннан чыккан һәр сүзне йотып алырдай булып текәлгән иде.

— «Янә шул да мәгълүм булсын үткән кече атна көн таң алдыннан баладан котылдым монысы малай булды инде алла боерса бәхете-тәүфигы белән туган булсын хәзергә болай үзе бик чибәр таза-сау тавышы да

бик көр нинди ат кушарга белми йөрдек-йөрдек тә куштык Илдус дип...»

— Тукта, Шәмси. Стоп! Ничек дигән? Илдус дигәнме?

Әхмәди урыныннан торды, тагын утырды, папахасын салып тезенә бәрде:

— Значит, малай? Әй! Һе, кара син әй, чын! Нинди хәбәр көткәндә, ә! — Ул хатны Шәмси кулыннан тартып алды да, үз күзе белән күрергә теләгәндәй, бик җентекләп әйләндерә-әйләндерә карагач, кире бирде.— Мә, шул төшен тагын бер укып кара әле, тәгаен малаймы? Ялгыш түгелме?

Шәмси бер хатка, бер кинәт җиңеләеп киткән сакаллы солдатка елмаеп карап алды:

— Илдус булгач, кыз була диме инде, син тагын...

— Һа! Тәгаен малай алайса, ә, якташ? Менә сиңа мә, ә?! Кая әле, тәрик әле берне, йөрәк түзми! Бир әле!

— Тартмыйм ич мин...

— Әй, истә дә юк... Син тәмәкеңне шикәргә алмаштырасың бит!..

Әхмәди, кайсы йоклаган, кайсы болай гына кырын яткан сугышчыларны төрткәләп, кузгатып, шаулап тәмәке таптыра башлады:

— Әйй, братва, кая әле, төрдерегез әле!

Шәмсинең аны мондый хәлдә күргәне юк иде әле. Озак еллар сугышта йөреп каты куллыланган, кырысланган бу гаяр кеше балаларны шулай өзелеп ярата торгандыр, йөрәгендә шундый нечкәлекләр саклангандыр дип кем уйлаган?

Көйрәтеп җибәргәч, Әхмәди яңадан Шәмси янына тезләнеп, тагын тыңларга тотынды.

— «...Сарык ике бәрән китерде берсе саулык берсе тәкә инде бишәү булдык кашык саны ишәйде ирең-атың янында булмагач анысы да исәп шуны ишеткәч советтан биш аршын ситсы тагын бәбигә күлмәккә акбүз белән бер кисәк бумаҗи китерделәр яңа җиткәнче ашарга бер подаука он бер капчык бәрәңге биргәннәрие халык өчен үзен кызганмаган кешегә бернәрсә дә җәл түгел дип бик сөендерделәр шуның белән яңага килеп төкәштек күрше Галимҗанның Апушы Тәкәрлек Гыйлаҗиның күпер төбе Мәүләви Дәүләтшасыннан кайткан сеңелесе Гөлҗамалга өйләнде туйларына мине дә чакырдылар бөтенесе парлы-парлы мин генә моңлы-зарлы дип парын югалткан сыңар күгәрчендәй мин генә моңаеп утырдым совет

персидәтеле Рәхим әйтә Әхмәди кайтса ди дөньясын җимертеп ди бер эшләп алыр идек ди каршы килгән дошманнарның тамырын корытыр идек ди алар да сине бик көтәләр мине советка сайладылар безнең өчен борчылма аклар бөтенләй бетсеннәр берүк муеннары асларына килсен исән-сау кайт сугышны бетерешеп кайт күпкә түзгәнне аңынчы гына түзәбез.

Сандугачкай сайраулары
Бигрәк ямансу итә,
Бу хат бездән бәхетле икән
Синең янарга китә.

Шуның белән сүзебез бетте хатыбыз сезнең янга китте хәләл җефетең Галимә дип беләсең».

— Бир, Шәмси туган! — Вәлитов сикереп торды да кызу-кызу атлап урамга чыгып китте. Бу шатлыкны ул үзенә генә сыйдырып кала алмады. Ир бала тууны да, авыл советының бүләк бирүен дә, хатынының советка сайлануын да — һәммәсен дә өй саен кереп сөйләп йөри башлады.

Шулай йөри торгач, нидер уйланып килгән политрукны күрде. Аны туктатып сөйләргә тотынды:

— Өйдән хат алдым әле, Исмаев туган. Укып карасак, хатын малай тапкан, понимаешь, иптәш политрук, малай! Менә, иптәш политрук...

Политрук Исмаев өченче взвод сугышчыларының өс-башларын тикшереп чыгып килә иде. Ул бөтен киемле бер генә кеше дә очратмады. Ботинкалар тетелеп төшкән, чалбарлар тишелгән, берданбер җылы кием булган шинельләрнең дә күбесе эштән чыккан. Тик шунысы гына юанырлык: берсе дә зарланмый, булмаслыкны сорап та маташмый. Ботинкасы төшеп калса — чабата кия, шинеле тишелсә — ямый... Шулай да сугышчыны болай йөртү ярамый лабаса инде. Бигрәк тә хәзер. Көннәр суык, бүген-иртә сугышка керәсе. Каян алырга соң ул киемне? Полкта юк, тиз көннәрдә вәгъдә дә итмиләр...

Әхмәди аңа әнә шулар турысында уйланып килгәндә очрады. Бу сакаллы кешенең балаларча шатлануы аңа да йокты. Ул Әхмәдигә хат килүгә дә, аның баласы тууга да, шатлыгын уртаклашу өчен аңа, политрукка, килүенә дә сөенде. Аның күңелен ничектер тагын да күтәреп җибәрәсе, аның шатлыгы бөтен ротаның да шатлыгы икәнлеген сизәрлек итәсе иде бит!

Тегө кызып сөйләгән арада политрук аның өс-башына күз салды. Сәлдерәгән иске шинель, җиң төпләре

умырылып төшкән. Ә үзе шат күңелле, һичбер борчуы юк кешедәй рәхәтләнеп, ашыгып-ашыгып малай тууы турында сөйли.

Уйлана торгач, политрук үз-үзенә куанып: «Иң яхшысы шул!» — диде, тиз генә рота командиры янына китте.

Очраган бер кешедән сөенче алып йөри торгач, Әхмәди бераздан кире кайтып керде. Хат әле һаман да кулында иде. Килеп керүенә күңелләнеп сөйләп китте:

— Политрукны күрдем әле, Исмаевны, аңа сөйләп бирдем. Минем шатлыкны ул да белеп торсын дидем. Мин аңа баштан үткәннәрне дә сөйләрмен әле. Безнең тормыш гыйбрәтле хәлләргә бик бай бит ул. Чын. Шулай менә, малайлар... Әле сез күп нәрсәне белмисез...

Ул хатны бик пөхтәләп папахасының колагы артына кыстырды. Тик күңеле тынычланмады булса кирәк, аннан кире алып, куен кесәсенә салды. Аннан соң лежанкага җайлап утырды да тәмәке көйрәтеп җибәрде.

— Менә Врангельне генә дөмектерик, Әхмәди абзагыз берсен дә онытмас, алла боерса, тем боле хәзер малай да булгач...

Шунда, өр-яңа шинель алып, политрук килеп керде.

— Әһә, кайттыңмы? Мин сине бөтен Строгановканы әйләнәсеңме әллә дип торам.

Политрук яңа шинельне сөйләнә-сөйләнә Әхмәдинең җилкәсенә үлчәп карагандай итте, якаларын төзәткәләде, хлястигын тигезләп куйды.

— Кешенең малае туган, нинди зур шатлык, ә ул шундый куанычлы көннәрдә ертык шинель киеп йөрсен, имеш! Шулай килешәмени?! Әллә безнең атай булган кешене котлап бүләк бирерлек тә хәлебез юкмы? — Ул берни дә төшенмичә бер шинельгә, бер аңа карап торган Әхмәдигә ике куллап шинельне сузды.— Мә, иптәш Вәлитов, бөтен рота исеменнән сиңа бүләк! Син батыр кызылармеец булу өстенә яхшы күңелле ата да икәнсең. Шулай кирәк! Молодец! Синең шатлык — безнең дә шатлык. Малай ни исемле әле?..

Аңа төрле яктан малайның исемен кычкырдылар:

— Илдус, Илдус!

— Әйе. Илдусың ел үсәсен ай үссен, ай үсәсен көн үссен, үзең шикелле батыр булсын! Кем белә, бәлки ул менә синең белән без сугышып саклап калган Советлар иленең, үз вакыты җиткәч, иң батыр сугышчыларыннан берсе булыр... Мә, озак яшә, җылы тәнеңдә тузсын!

Әхмәди ни әйтергә дә белмичә каушабрак калды.

— Бу ничек инде тагын, иптәш политрук! — Әхмәди гаҗәпләнеп иптәшләренә карады. Ләкин бирәү дә шаяртмый, иптәшләре аны чын-чыннан котлап шинельне кидерергә торалар.— Бәй, малай тудыру дим, әллә ни зур батырлык түгел инде ул, кемдә дә була торган бер хәл дигәндәй... шундый гына бит ул. Мин бит аны сөенечтән генә, якын итеп кенә сөйләдем. Һе... алай булгач, нишләргә соң? Чын...

Ләкин аңа сүзен әйтеп бетерергә дә ирек бирмәделәр, төрле яктан эндәшләр, киңәшләр, шаян сүзләр ява башлады:

— Я, я, кызлар шикелле кыстатып маташма инде! Ал да ки!

— Бирәүләргә ялынып сорасалар да эләкми, ә син китереп биргәнне алмыйча кәнфитләнәсең. И уңмаган!

— Әй шинеле дә шинеле! Өр-яңа, жып-жылы! Кызлар куенымыни? Ал тизрәк! Ки тизрәк!

Әхмәди, сөйләнә-сөйләнә, кояш кебек ялтырып, иске шинелен салырга тотынды.

— Соң... хезмәтемне дә килештергәч, малайны да котлагач, кая алайса...

Ул сүзләрен әйтеп бетергәнче, Шәмси җилтерәтеп шинельне киертеп тә куйды.

— Менә шулай! Җае чыкканда мин дә картның күңелен күреп калыйм әле. Исән-сау кайтсам, шулай юмалаштыргалап, кызын алып булмасмы...

Әхмәди аңа бармак янады. Данилов, Әхмәдигә күз кысып, шаяртып алды:

— Күрдең, Вәлитов, ничек килеп чыкты? Бер атуда ике куян алдың: малайлы да, шинельле дә булдың.

VII

Менә түземсезлек белән көтелгән кич тә якынлашты. Кояшның кызыл түгәрәге, соры болытлар арасыннан күренер-күренмәс кенә шуа торгач, Перекоп ягында калку артына кереп юк булды. Сиваш өстен, иртәнге төсле үк, куе томан басты.

Меңнәрчә сугышчыларны эченә алган гаскәр берләшмәләре бер-бер артлы кузгала башладылар. Ишек алларында, тыкрыкларда, урамнарда кызу хәрәкәт башланды. Тыныч кына кичне көткән кешеләр, кузгалу вакыты җиткәч, үзләре дә сизмәстән, бераз кабалана төшеп, вин-

товкаларын астылар, авырайган патронташларын, сумкаларын җайлап сафка тезелделәр.

Иң башта, озын һәм киң колонналарга тезелеп, тавышсыз-тынсыз, музыкасыз һәм җырсыз, җәяүлеләр чыга башлады. Алар артыннан тачанкаларга көйләнгән пулеметлар, иң актыктан тупчылар кузгалды. Бик тын иде. Бары тик анда-санда аяк дөпелдәве, басынкы команда тавышлары, атлар пошкырып куюы, ара-тирә бәрелешеп тимер чыңгырдаулары гына ишетелгәли иде.

Авыл халкы озатырга чыкты. Урам чатларына, капка төпләренә җыелышкан ир-ат, хатын-кыз төркемнәре узган бер частьны сөеп, якын итеп күздән уткәрделәр.

Кырыйдагы балчык өй янында яшь кенә бер хатын, авыз эченнән нидер көйли-көйли, кулындагы нәни баласын юата. Аның йөзендә әйтеп бетергесез сагыш, тирән моң иде. Кем белә, бәлки аның нәниенең атасы да әнә шулай караңгы төнгә каршы походка чыгып киткәндер дә шуннан кайтмагандыр...

Йонлач бүрекләрен басып, тын гына карап торган ирләр арасында чал сакаллы бер карт әле өзлексез узып торган колоннага, әле соры томан белән капланган шомлы Сиваш ягына карый. Ул бөтен гомерен менә шушы Сиваш буенда уздырган. Тик елның бу вакытында аның да Сиваш иңкеленә аяк басканы юк. Ул борчулы кыяфәт белән, күршеләреннән сораган сыман:

— Кая баралар болар, кая баралар!— ди.

Аның бу сүзләре: «Нигә анда керәләр алар, ни буласын беләләр бит инде!» дигән кебек ишетелә. Аңа берәү дә дәшми. Чөнки дәшмичә дә аңлашыла.

Сиваш өстенә ишелердәй булып салынып торган калын болытлар астыннан каршыга салкын җил исә, ул, кызган битләргә бәрелеп, якадан, шинель ертыкларыннан кереп, авылдан алып чыккан барлы-юклы җылыны сөреп чыгара. Томанның теге ягындагы ераклыктан әледән-әле пулемет тавышлары ишетелгәләп куя. Карасу-соры болытларның җиргә кушылган кырыенда, Перекоп турында, орудиеләр гөрелде. Тына да тагын гөрелдәп ала.

Авылдан чыккач, сул яктагы бакча эчендә дивизиянең штабы урнашкан кечкенә ак өй күренеп калды. Унда виноград бакчасы яныннан узып аска, Сивашның караңгы, текә ярына төшеп киттеләр. Түбәнрәк төшкән саен томан куера барды, битләргә сыланды, күзгә вак яңгыр кебек шинельләргә салкын дым булып сырышты.

Яр буе төшкән бер колоннаны упкындай йота барды, полкларның төшкән берсе куе томан эчендә тавышсыз-тынсыз югала барды. Монда сәер бер тынлык иде. Болай бер тавыш та юк шикелле, әмма чынлабрак тыңлаганда, нидер шупырдаган, бөтен яр буе умарта эчедәй тоныкк кына гөжләгән кебек.

Алдагыларның юеш аркаларына барып терәлгәч, рота туктады. Аяк астында баскан саен, юеш ком сыман, нидер кыштырдый иде.

Пахомов ротаны тыгызлап дүртәр кешедән тезде дә өзеп-өзеп кенә бер-ике сүз әйтте:

— Бер-береңнән аерылмаска, артка калмаска! Тартырга ярамый! Аңлашылдымы?

Аңа шыпыртлап сүлпән генә җавап бирделәр:

— Аңлашылды...

Әмма Исмаевның сизенүенчә, бик үк аңлашылып бетмәде шикелле. Сугышчылар тагын нидер көтәләр, күңелгә бераз өмет яктысы сирпепме, ике араны якынайтыпмы җибәрә торган тагын нииндидер бер җылы, ягымлы сүз кирәк кебек сизелә иде.

Исмаев, баскан саен тозлы комны шыгырдатып, әле бер взводка, әле икенчесенә сугылды. Шул туктап торган арада, гүя үзара гына әйткәндәй, якын итеп кенә сөйләгәндәй шыпыртлап байтагысы белән сөйләшеп чыкты.

— Бүген таңнан торып бу юлдан бер барып кайттык инде без. Ну, бик үк коры түгел, конечно, бераз пычрак ерырга да туры килер. Тик читкә генә тайпылырга ярамый. Башка ягын нәрсә дисең... Без бит инде мондыйны күп күргән егетләр, күпегәсе түгел. Ә тәмәкене теге якка чыккач иркенләп тартырбыз, яхшысын, менә дигән Кырым тәмәкесен! Шулай бит?!.

Сивашның төпсез караңгысы, аның ниндидер борчулы тынлыгы Исмаевның үзен дә бераз шүрләтә иде. Тора торгач җир астында нидер гүләгән, нидер күкрәгән сыман тоелып китә, ул үзләрен җир уба кебек, әбисе сөйләгән әкияттәгечә, бөтен яр буе белән бергә астагы коточкыч караңгы дөньяга иңеп баралар кебек хис итә башлый. Шунда Исмаев яңадан кеп-кечкенә Хәсби булып кала, аның бөтен тәненә салкын йөгерә. Тик ул моны сизмәмешкә салынып, гүя әлеге йомшаклыкны куып җибәргәндәй, батыр гына тамак кыргаларга тотына. Чөнки бик тирәннән чыккан горурлык белән эчке бер тавыш аңа әйтә: мин коммунист бит! Коммунист!..

Политрук Исмаев тыңламас чәчен сыңар кулы белән сыпырып куя да аңа гына хас бер осталык һәм ягымлылык белән тагын әлеге шул сугышчыларын кайгырта башлый: берсенә исеме белән дәшә, икенче бер сугышчыга күңелен эретерлек нинди дә булса берәр ягымлы сүз әйтә, кайберләренә бүген иртә белән менә шушы яр өстендә үз күзе белән Фрунзены күрүе турында сөйләп ала. Ни турында сүз кузгалмасын, сугышчылар аннан тынычлыкмы, киләчәккә өметме, ягымлылыкмы — ниндидер бер яхшы нәрсә йогып калуын сизәләр иде.

Томаннан башка берни дә күренмәсә дә, Исмаевның сүзен тыңлый-тыңлый еш кына алга, барасы якка да күз салгалыйлар иде. Кая барасын күптән беләләр иде. Ни өчен шундый тәвәккәллек кирәген дә, Врангельнең арт ягына бәреп керү өчен башка юлның юклыгын да, Перекопның алынуы һәм Врангельнең җиңелүе шушы төнге походка бәйләнгән булуын да кычкырып сөйләмәсәләр дә сиздергәннәр иде. Менә бу калын томанның теге ягында Врангельнең пулеметлары, пушкалары, бу якка төбәлеп, көтеп торулары да билгеле. Турысын гына әйткәндә, хәтта аклар хәзер куркытмый да. Алар белән беренче очрашу түгел. Инде менә Сиваш — бөтенләй башка нәрсә. Әнә ул уңнан да, сулдан да, өстән дә җитереп баскан ерып узгысыз калын томан астында, ул мәңгелек сазлыкта ниләр бар? Нинди упкыннар, нинди мәкерле чокырлар сагалап тора? Менә анысын беркем дә белә алмый иде әле. Бары аяк астындагы тозланып каткан, кыймылдаган саен кыштырдый торган яр балчыгы гына ышанычлы, ул гына үзенең ныклыгын һәм чынлыгын сиздереп берникадәр тынычландырып тора иде.

Шул ук вакытта элек берәүнең дә кулыннан килмәгән, берәүнең дә йөрәге җитмәгән менә бу тәвәккәллек, серле дә, кыен да булган шундый операциягә бару ничектер дәрт өсти, җилкендереп тора иде.

Алда, менә шул басып торган урыннан ерак та түгел караңгыда сагалап торган ниндидер упкыннар турында, диңгез дулкыннарының басып керү ихтималы турында уйламас өчен, бер-берсенең аркаларындагы капчыкларын, винтовка каешларын төзәтештеләр. Хәзер алар бер-берсен тагын да якынрак хис итәләр, һәркемнең күршесенә нинди дә булса бер җылы сүз әйтәсе, күңелен күтәрәсе килә иде.

Аз-маз рәтләнгән арада кузгалырга да команда булды. Төньякның март төнен хәтерләтеп, аяк астында бертуктаусыз тоз катлавы шытырдап тора башлады.

Полклар бере артыннан бере Сивашка кереп киттеләр.

Караңгы куерганнан-куера бара, янәшә атлаучылар да шәүлә генә булып күренәләр иде. Караңгының куесы, гүя баш очында эленеп, папахаларга орынып, авырайтып торган шикелле. Икенче караганда куе томанны ерып, аның эченнән тәбәнәк түшәмле тар коридор ясап барган шикелле. Шул тар коридордан аз гына кырыйга тайпылдыңмы, анда төпсез упкындыр кебек.

Куе агым булып салмак кына керә бардылар. Ярдан ерагайган саен тынлык та тирәнәя барды.

Кузгалып киткәннән соң Шәмсинең тәне иң беренче булып сизгән нәрсә — Сивашның юеш салкыны булды. Гүя тәнгә шинель аша аның салкын юеше тиядер, биткә юеш чүпрәк ышкыладыр кебек. Ул, кулының ялангачлыгын шунда гына исенә төшереп, перчаткасын киде, якасын торгызып куйды. Җирнең өстен генә чылатып китә торган узгынчы яңгырдан соңгы кебек, җиңелчә генә пычракта аяклар таеп киткәли, табанга салкын дым үтә иде.

Ара-тирә сагаеп кына, шыпыртлап кына сөйләшкәләп алалар, аннары нидер буласын көткәндәй, як-якка карангалыйлар. Монда ни дә булса булырга тиеш бит. Ул «нидер» менә шунда, шушы минутта, менә хәзер үк булырга мөмкин. Аның булырга тиешлегенә һичкем шикләнми. Шулай да нәрсә ул?

Үзе белән янәшә барган Даниловның җитди чырае, бераз гына барган саен: «берәр нәрсә күренмиме?» дигән сыман, алга һәм як-яктагы караңгыга күз салып алуы, рота командирының политрук белән үзара шыпыртлап кына сөйләшүе, аннан соң, я алга китеп, я артка калып, ротаның ничек баруын өзлексез күзәтүләре, тынычсызланулары; элемтәче кызылармеецларның ашыгып, мышный-мышный кырыйдан йөгереп узулары — болар һәммәсе дә бөтен полкны һәм һәрбер кызылармеецны нидер көтәргә, сагаерга мәҗбүр итә. Яр буеннан бирле ияреп килгән киеренкелек эчкә кергән саен көчәя генә бара иде.

Атын камчылап колонна яныннан алга таба бер атлы узды. Якындагылар аның комбат икәнен таныдылар. Ат

аягын пычрактан суырып алган саен каты шартлаган тавыш килә иде. Шинеленең итәген биленә кыстырып, җәһәтләп Исмаев тагын алга узды.

Эчкәрәк киткән саен пычрак тирәнәя барды, аяклар бата башлады. Ботинкаларга авыр балчык сыланды, шинель итәкләре авыраеп, аяк арасында лыпырдап йөдәтте.

Үзенең артында кемнеңдер бик авыр сулавына пошынып, Шәмси борылып карады. Әхмәди абзасы икән. Олы кешегә аз булса да ярдәм итү өчен җай чыгуга күңеле булып, Шәмси аның мылтыгына сузылды.

— Бир, Әхмәди абый, үзем күтәреп барыйм.

Әхмәди шыпыртлап:

— Сиңа авырга килер бит? — диде.

— Юк, юк! Кая, китер.

— Мәйлең тагын, кияү... Болай бик яхшы күңелле кеше булып чыксаң, тәки кызны бирмичә булмас.

Шәмси «кияү» сүзен колак яныннан гына уздырды да Вәлитовның мылтыгын иңбашына асып, аның белән янәшә атлый башлады.

Кинәт Вәлитов ялгыш басты да сыны катудан ыңгырашып куйды:

— Нәләт! Ахрысы минем ярага...

Әхмәдинең хәле чыннан да җиңел түгел иде. Аягының төзәлеп бетмәгән ярасына Сиваш суы үттеме, бүтән берәр нәрсә булдымы, аягы яман ачыта башлаганлыктан, тешен кысып, үкчәсе белән генә атлый башлады.

Тик шунда Перекоп ягында туплар гөрселдәп китүгә, әйтер сүзен әйтмәенчә, тынып калды. Шушындый ук караңгыда, шушы мәңгелек сазлыкның пычрагын ерып, дошманның ут ыргып торган тупларына каршы баручы меңнәрчә сугышчылар күз алдына килде, бу тиңсез фидакарьлекнең бөеклеге ничектер берьюлы аңында чагылып китте дә ул аягының сызлавын оймаска тырышты.

— Беләсеңме, Шәмси...— дип пышылдады.— Моңарчы бу җәһәннәм сазын бер яуның да җәяү ерып чыкканы юк бит әле.

Шәмси шомлы төпсез караңгыга карап, туплар үкерүгә колак салып бара иде; ул, кемнедер үчекләгәндәй, малайларча ярсу дәрт белән:

— Ә менә без чыгабыз! — диде.— Бөтенесенә үч итеп чыгабыз!

Әхмәди, «әйе, әйе!» дигәндәй, аңа кат-кат баш иде. Яшь иптәшенең иңбашына таянган килеш, кинәт кенә

килеп бөялгән татлы да, сәер дә уйларын әйтеп бирергә сүз таба алмыйча берникадәр вакыт дулкынланып баргач, ул шыпыртлап тагын әйтеп куйды:

— Әйе, чыгабыз, Шәмси энем! Бәлки тора-бара бик кыен да булыр, тик барыбер чыгарбыз! — Әхмәди бераз тынып барды. — Ммм... без менә шундый караңгыда диңгез кичәбез. Ә тегендә, өйдә дим, минем кечтекием, Илдусым, үзенең бишегендә, иреннәрен чеп-чеп китереп, рәхәт кенә йоклап ятадыр, ә?!.

Шәмси нәкъ аныңча итеп:

— Каян беләсең бит, Әхмәди абый, — дигән булды. — Каян гына беләсең? Бәлки синең кечкенә улың бу минутта бишегендә җылы диңгездә балык сөзеп ята торгандыр әле!..

Әхмәди каты гына итеп аның аркасына төртте:

— Юньсез малай. Үзең әти булып карамагач, нәрсә беләсең соң син!

Шәмси аның колагына ук иелеп, ничектер күңелгә үтеп керердәй ягымлы итеп пышылдап куйды:

— Әнә кызыңны һаман ярәшмисең бит. Күзле-башлы булсам, бәлки миңа да бераз акыл керә башлар иде.

Әхмәди әле күңелендәген әйтеп бетермәгән иде бит. Малаена әнә шулай рәхәт булуын белеп торганга күрә дә үзенең менә бу азапларны җиңел күтәрүе турында әйтәсе килгән иде аның. Аннары ул күршесендә атлаучы бу яшь егет турында да әйбәт кенә уйлар уйлап куйган иде. Сугыштан исән-сау калсак, кем белә, бәлки, тәвәккәлләп... Егете начар булмаска охшый бит, болай әйбәт күңелле, яхшы җанлы малай шикелле.

Шул вакыт сул яктан елаганга охшаш бер тавыш ишетелде. Ул, буранда адашып, котылуына өмет өзгән кеше тавышы сыман, үтә аяныч булып ишетелә, җитмәсә зәгыйфьләнә дә башлаган иде.

Бу тавыш йөрәкләргә килеп бәрелде, тәннәрне чиркәндерде, якын иптәшнең үлем авызыннан биргән иң соңгы хәбәре булып, аяныч булып ишетелде.

Колоннада ул кешене кайгырту, аның өчен борчылу башланды.

— Полк командирына хәбәр итәргә кирәк, — диде берсе.

Караңгыдан аңа шундый ук шыпырт тавыш белән борчылып җавап бирделәр:

— Ул синнән алданрак ишеткәндер инде...

— Ишетеп ни эшләмәкче буласың? Анда барыбер кереп булмый бит.

— Әйтте бит командир: бер адым читкә атладың, беттең...

Сугышчылар гаепле кеше сыман башларын иеп, аска карап кына атлыйлар. Кешенең бата баруын белә торып, актык сулышында аңа ярдәм кулынны суза алмавың нинди гаҗизлек! Язмышның шундый ерткычлыгына төшенне кысып баш иярга мәҗбүр булудан да газаплырак тагын ни булырга мөмкин?

Тавыш берничә кабатланды да, зәгыйфьләнә барып, тора-бара бөтенләй тынды.

Комсыз Сивашка озакламыйча тагын бер корбан бирергә туры килде. Комбатның колоннага орыныр-орынмас барган аты, нидәндер өркеп, читкә тайпылды, ул да түгел, аның аяклары кинәт сазга батты. Комбат атының башы аркылы егылып төште. Ат куркуыннан ярсып тыпырчына башлады.

Бу хәлне күреп, колоннадан берничә кызылармеец булышырга ташландылар. Кайсыдыр, иярен салдырмакчы булып, атның ызмасын капшады. Ул арада инде алаша алгы саны белән пычракка иңеп бара иде.

— Әй, бата бит!

Кемдер бау алып килергә дип, артка таба йөгерде. Берсе атны ялыннан һәм койрыгыннан сөйрәргә киңәш бирде. Алай да барып чыкмады. Ат баткан тирә басып тора алмаслык сыек пычрак булганлыктан, аның янына һич барып булмый иде. Ул тыпырчынган саен пычрак тагын да изри төште.

Бер сугышчы, атның бөтенләй батып баруын күргәч, кызулык белән:

— Әй! братва!..— дип кычкырып җибәрде.

Комбат кысылган тешләре арасыннан:

— Молчать!— дип пышылдады.— Нәрсә син, полкның башына җитмәкче буласыңмы?

Аның кабыргасына төрттеләр, саксызлыгы өчен төрле яктан сүгеп ташладылар.

Бауга киткән сугышчы һаман килеп җитә алмады. Алаша, үзен һәр яктан кыса һәм аяусыз суыра барган пычрактан котылу өчен, бөтен көче белән тыпырчынды, башын як-якка бәргәләргә тотынды. Әмма аның саен төпкәрәк батты. Берничә минуттан соң инде аның башы белән сырты гына күренә иде. Ат коточкыч аяныч тавыш чыгарып гыжылдый башлады.

Булышырга килүчеләрдән берсе, сузылып, атның имәнгеч булып тырпаеп калган борынын тотып карады.

— Мескен, бөтен гәүдәсе белән калтырый, озакка түзә алмас, — диде.

— Йөрәгенә суык тиде инде аның, чыгарсаң да үләр иде.

— Кая инде ул чыгару? Бетте алаша, Сиваш суырды үзен, йотты.

Аты тирәсендә түземсезлек белән әйләнгәләп йөргән комбат бер батып барган атына, аннан колоннага карап алды. Хәзер инде арттан куып җиткән полк та узып бара иде. Шул арада нәрсә булганны карар өчен узышлый туктаучылар байтак ук җыелган иде.

— А ну, урыныгызга! Марш! — диде комбат.

Ул, тез тиңентен бата-бата якынаеп, атының башын, маңгай чәчен, колакларын сыйпады. Атның күзләре зур ачылган иде. Алар нидер өмет итеп тилмереп карыйлар. Нинди авыр юллар, нинди каты сугышлар кичкән көрәштәш юлдашы иде бит... Атының башына сузыла төшеп, гафу үтенгән сыман тагын бер тапкыр маңгаеннан сөйде:

— Прощай, милок, прощай! —диде.

Ат пычракка күмелә башлаган борыны белән авыр итеп гыжылдый, ә маңгае һаман тетрәнә иде.

Бара торгач, юл буенда гына пычракка тезләнгән ялгыз бер кеше күренде. Ул телефонист булып чыкты. Телефон трубкасын учлап тоткан да кайдандыр җавап килгәнне көтә. Шулай бераз көтә дә тагын дәшә. Аннан тагын тыңлап карый. Колонналар, өзлексез агым булып, һаман узалар, ә җавап, күрәсең, ишетелми дә ишетелми.

Ул шулай озак кына азапланды да узып баручы колоннага дәште:

— Иптәш командир! Рота командиры!

Аның янына Пахомов килде.

— Я, нәрсә сиңа?

Сугышчы түшенә аскан аппараты белән аягүрә басты.

— Элемтә өзелде. Сивашның пычрагы кабельны ашый икән, — диде телефонист. Үзенең телефон аппаратын һәм кабельны ташлап китә алмавын, якын-тирәдә элемтәчеләрдән берәү дә булмауны әйтеп, шушыны белдерер өчен дивизиягә бер кызылармеец җибәрүне үтенде.

Данилов донесение илтү өчен яшьрәк, талчыкмаганрак сугышчылар арасыннан Шәмсине җибәрергә булды. Шәмси, телефонисттан язу алып, кире Строгановкага таба йөгерде.

VIII

Шулай биш-алты чакрым чамасы киткәч, алда һәм бераз уңдарак бертуктаусыз орудиеләр үкерешүе башланды.

— Гаубица тотынды,— диде Данилов.

— Бик яман үкерә. Бәлки диңгездәндер? Акларның анда диңгез артиллериясе дә бар диләр бит.

— Бәлки безнекеләр шулай дөмбәсли башлагандыр? Перекопны аласы бар лабаса.

Данилов безнеке булуга ышанмый иде.

— Һи, кая инде ул безгә андый артиллерия! — диде.— Әле пулеметы күбрәк булса да бик ярап куяр иде.

Каршыда, ике-өч чакрым ераклыкта булып, берничә урында пулемет тыкырдый башлады. Ләкин боларга бөтен дөньяны басып яткан бу караңгыны нәрсәдән генә атсалар да тишеп керә алмас кебек тоела иде.

Шәмси киткәннән соң Вәлитовның хәле тагын да кыенлаша төште. Ул үзәгенә үтеп сызлый торган яралы аягын көч-хәл белән генә сөйрәп атлый, һәр адымы, кызган кадак очларына баскандай, йөрәгенә барып кадала иде. Шунлыктан пулемет тавышының якыная баруына ул сөенде генә.

— Болай булгач... бәлки ерак та түгелдер инде.

Арттан, бата-чума барудан авыр сулап, политрук Исмаев килеп чыкты.

— Менә болары безне каршылыйлар инде...— Ул Вәлитовны бераз җитәкләп барды, ничектер бик ягымлы итеп:— Беләм, аңлыйм хәлеңне, Әхмәди абый. Әле менә таза кешегә дә бик кыен,— диде.— Беразга гына түзсәң... бер-ике чакрымга гына... аннары дөнья безнеке. Менә күрерсең, арт сабакларын укытырбыз әле ул эттән туганнарның.

Бераз тын алганнан соң йөгерә-йөгерә тагын алга китте.

Пычрак тирәнәя барды. Ул аякларны суырып ала, әчпошыргыч булып өзлексез чапылдый, авыр йөк булып ботинкаларга ябыша иде.

Бара торгач, Сиваш сазының тагын бер хыянәте ачылды. Моңа Митричевның коточкыч сүгенә башлавыннан соң гына игътибар иттеләр. Ул аягына иелә-бөгелә карап бөтен дөньясын каргый иде:

— Кайсы алла гына каргады икән бу җәяүлене, ә? Әйтерсең, каторжан, әйтерсең, йөк ташучы ишәк! Чәнчелеп, кадалып, муены астына килеп...

Данилов түзмәде, аны каты гына әрләп ташлады:

— Якын-тирәне сасытмыйча гына диңгезне дә кичеп булмый инде, ә?!. Ничек түзә, ничек чыдый синең ул телең?

— Синең телең тузмый бит, минеке туза, нигә кыршыласың?

— Ачуың килмәслекмени? Кавалерист, имеш! Җәяүлене сүгә, имеш. Беләсең килсә, дөньяның тоткасы атлы түгел, җәяүле! Бик беләбез! Бутылкалы кызыл чалбар киеп ат өстендә кем дә маймылланырга булдыра аны. Менә син шушылай ике потлы йөк күтәреп, менә шушындый җәһәннәм сазын ерып дошманның тылына бәреп чык! Син шуңарга түз, шунда күрсәт син революциягә хезмәтеңне!

Митричев, кинәт тураеп, Даниловның борын төбенә ниндидер бер сәләмә әйбер сузды:

— Мә, күрәсеңме менә моны?! Монда сугышчының итеге таралган, сугышчы ялангач аягы белән пычрак ера, ә ул тегеләй бул да, болай бул... Һе! Командир! Сүгенмә, имеш.

Данилов күзләрен челт-челт йомгалады, аркасындагы капчыкларын төзәткәләде.

— Синдә генәмени!.. Әнә, барыбызның да таралып бара. Кем гаепле? Бар әнә, ябыш бугазына!

Митричев ачуыннан төкерде дә, авыз эченнән бөтен дөньясын каргап, төпсез итеге белән шапыр-шопыр су ерып алга китте. Аның аягы башта чирканды, бераздан туңа башлады. Тора-бара исә берни дә сизмәс булды.

Тора-бара аяк атлавы мең бәлагә әйләнде. Үтелгән чакрымнарның исәбе күптән үк чуалган, тагын күпме барасын, алда ниләр көтүен берәү дә белми иде. Күбесе көч-хәл белән генә атлый, кайберәүләре егылып калу хәленә үк җиткән. Ләкин ял итеп алу турында хәтта уйлап та булмый, чөнки туктарга берничек тә ярамый, берсән, колоннаның читендә үлем сагалап тора, икенчедән, берәр генә минутка туктаганда да соңыннан иптәшләреңне куып җитү мөмкин булмаячак иде.

Менә алдагы сафларда кинәт кенә барысы берьюлы тавышлана башладылар. Анда ниндидер борчылу, каушау сизелә иде. Ни бар? Колагына кергән өзекләрдән Вәлитов сүзнең ниндидер җил турында баруын абайлады. Башта ул аңа игътибар итмәде. Ул эштән чыгып арыган, тозлы су аягының ярасын ачыттырып, йөрәгенә төшеп бара, кыскасы, аның үз хәле үзенә җиткән иде. Бераздан, Данилов белән сөйләшкәндә политрукның, тынычсызланып:

— Җил борылган!—диюен ишеткәч кенә, җил көнчыгыштан исә башласа, ниләр булырга тиешлеге күз алдына килеп, Әхмәди эсселе-суыклы булып китте.

Сул яктан дымлы авыр җилнең шактый ук көчле бәрә башлавына ул шунда гына игътибар итте. Җил минут саен көчәя барды. Сиваш өстен басып яткан калын томан Перекоп ягына таба авышты. Күз алдыннан кара япма алып ташланган сыман булды. Караңгыдан җәяүлеләр, атлылар калкып чыкты, кызу атлап ашыга-ашыга алга баручы меңнәрчә шәүләләр күренә башлады.

Рота командиры авыр атлап, тая-тая алга таба китте. Тагы ике кеше, атларын гыжлатып, бата-чума чабып уздылар.

Батальон командиры, бер кырыйда туктап, колоннаны ашыктырып торды:

— Живо! Бегом! Артка калмаска!

Ул арада диңгез ягыннан, еракта гы ташкын тавышы сыман, тонык бер шаулау ишетелде. Аның ни икәнен, аннан соң тагын нәрсә булачагын абайлап өлгергәнче, сулда пычрак өстендә озын булып сузылган ак буразна күренде. Ул, астыртын чагарга хәзерләнгән елан дай, шомлы кыштырдап боргалана-боргалана аяк астына ташланды.

— Күбек!

— Су баса!

Ул арада күбек буразнасы полкның барасы юлын кисеп тә чыкты; сугышчыларның аягына су бәрелә башлады. Диңгез ягыннан ишелеп килгән дулкыннарның тавышы көчәйгәннән-көчәя барды.

Бу — җил белән котырынып ярсыган диңгезнең Сиваш сазына төнге һөҗүме, Сиваш иңкеленә су тутыруы иде.

Су өзлексез арта, дулкыннар шаулавы торган саен якынлаша. Менә су аяк йөзенә менде, балтырга үрмә-

ләде, аның ак күбекләре, алга барасы юлны кисеп, шаулап һәм чиркандырып аяк араларыннан ага башлады.

Батальон командиры, алга йөгереп чыгуга, көтелмәгән хәлгә шаккатып туктап калды. Алда барасы юлны кисеп шаулап су ага, тирә-якта берни күренми иде. Ул арада инде алдан баручы полклар күренмәс булганнар, бу полкның үзенә аерым юл күрсәтүчесе юк иде.

Юлына очраган һәммә нәрсәне батырып, җанлыны, җансызны пычрак белән тигезләп килгән бу һәлакәт алдында каушап калмас өчен, зур батырлык һәм егетлек кирәк иде.

Командир, ниндер башына килгәндәй, шпорлы итекләре белән су ера-ера алга таба йөгерде, ул да түгел, тиз үк борылып килде дә, авыр сулап, рота алдына туктады. Сугышчылар, бер-берсенә сыенган килеш, тешләрен кысып команда көтәләр иде. Нишләргә? Тәнгә үлем суыгыдай аяусыз үрмәләүче бу куркыныч алдында тынып калган меңнән артык кеше менә хәзер дә, шушы минутта да, аның командир булуын телиләр. Бозлы су аның балтырына таба үрмәләде, әмма аңа бу өшеткеч су аның үз тәненә генә түгел, бәлки полкның йөрәгенә таба үрмәли кебек тоела иде. Тавыш чыгарырга ярамаганны искәрмәстән, комбат кинәт кычкырып җибәрде:

— Командирлар! Рота командирлары, бирегә! Тиз!

Аның янына, су ерып йөгерә-йөгерә, шинельләре суга чыланган Пахомов һәм тунының билдән түбәнге өлеше җебеп, асылынып төшкән тагын бер командир килеп басты.

Комбат аларга:

— Кайда йөрисез?— дип кычкырды.— Күрмисезмени?! Компас бирегез, тиз, тиз!

Пахомов кесәләрен актарган арада, кинәт бик якында гына, ап-ачык булып пулемет тавышы ишетелә башлады. Комбат сискәнеп башын калкытты, нәрсәгәдер куанып командасын кычкырды:

— Булды! Әйдәгез, минем арттан! Туктамаска, артка калмаска! Йөгер!

Үзе пулемет тавышы килгән якка борылды да, шинель чабуларын күтәреп, йөгерә дә башлады.

Кинәт бөтен тирә-як хәрәкәткә килде. Аяк астында су чупырдаганы, бик күп кешеләрнең берьюлы ухылдап, гыжлап, авыр мышнаганы ишетелә, бер-берсенә тиеп штыклар чыкылдап куя, пулеметлар ата. Караңгы басып яткан Сиваш сазлыгында гаҗәп бер ыгы-зыгы, нин-

дидер бер башка сыймаслык, күз алдына китерә алмаслык авыр көрәш, каты тартыш бара иде.

Сиваш иңкеле күп урынында тигез төпле булганлыктан, аның кайсы ягына киткәндә дә су ташкыныннан котылу мөмкин түгел иде. Ләкин утрауның кайсы юнәлештә икәнен чамалап булса, шуның өстенә, су тирәнәйгәнче яр белән ике араны йөгереп узарга полкның көче җитсә, батып калу куркынычыннан да котылырга һәм приказда күрсәтелгән вакытта дошман ягына бәреп чыгарга да мөмкин булачак иде. Шунлыктан батальон командиры туп-туры пулеметларга каршы йөгерде.

Ул арада диңгез җиле катырак ыжгыра башлады. Шундый караңгы төндә диңгезнең тынычлыгын бозарга батырчылык иткән бу башсыз кешеләргә ачулангандай, ярсып, ул аларның битләренә бәрелде, штык очларында жуылдады. Шинель итәкләре торган саен авырая барды. Диңгезнең тозлы суы битләргә, күзләргә чәчрәде. Боларның берсен дә сизмәс булдылар. Аякларны өшеткән бозлы су салкыны да, арыганлык та онытылды. Атлаган саен эченә суырырга көтеп яткан чаклакларга бату куркынычы да адымнарны акрынлата алмады. Бөтен көчләрне җыеп алга, пулемет тавышлары килгән якка йөгерделәр.

Су туктаусыз арта барды, бераздан тезгә менде, аякларны читкә сөйри башлады.

...Бугазын пешереп чыккан кайнар сулыш Әхмәдинең иреннәрен киптерә, суларга ирек бирми, тынын куыра иде. Ул шабыр тиргә батты. Сул аягының үзәккә үтеп ачытуы бөтен тәненә таралды, йөрәген сыкрата башлады. Ләкин озакламый ул да тоелмас булды. Тәненең билдән түбәнге өлеше ничектер бик сәер туңып, тора-бара берни дә сизмәс булды. Аяклары су ерып йөгерүче менә бу телсез-өнсез кешеләр артыннан, аның, Әхмәдинең, ихтыярыннан тыш, аңа һич билгеле булмаган, каяндыр читтән килеп кергән сәер бер кодрәт белән генә ияреп баралар кебек иде.

Ул, яр буе күренмәсме икән, дигән өмет белән күтәрелеп карады. Сөек томан эчендә кара суны шупырдатып, берсеннән-берсе узышып, ахылдашып, ава-түнә барысы бер якка таба йөгерешкән төнге күләгәләрдәй соры гәүдәләрдән башка берни дә күренмәде, дулкыннар шаулавыннан башка берни дә ишетелмәде.

Янышнан, томан һәм су чәчрәмәсе эченнән, авыр сулап, төштә күренгәндәй, бер кеше йөгереп узды. Су шау-

лавы белән бергә буталып, Әхмәдинең колагына берничә ягымлы сүз чалынып калды:

— Туганкайлар, иптәшләр! Бирешмәгез!.. Ерак калмады.

Кеше тавышы булганлыктан, бу тавыш аңа бик якын булып ишетелде, ул аның аякларына хәл кертте. Ул үзенчә тагын да тырышыбрак, тагын да кызурак йөгергәндәй була, ләкин чынында бер урында гына диярлек таптана иде.

Унда, Перекоп ягында булса кирәк, атыш тагын да көчәя башлады. Артиллерия канонадасына пулеметлар тавышы кушылды. Ләкин болар һәммәсе дә каядыр, икенче дөньяда, болытлар өстендә ишетелгән шикелле иде.

Вәлитовның хәзер үз кайгысы кайгы, кургашын таккандай авырайган аякларын бер генә атлау да бик кыен, ярым йомылган күзе алдында, күңел болгатып, кызыл түгәрәкләр бөтерелешә иде.

Шул чак аңа авыр бер дулкын килеп бәрде дә, Әхмәди тезләнде. Ул тезләренең пычракка батуын, күкрәгенә, аркаларына су керүен тоеп, калтыранып китте. Икенче дулкын аны баштанаяк коендырып узды. Авызына, борынына су тулды.

Дулкыннар, берсе артыннан берсе ишелеп килеп, аны егарга теләгәндәй, өсте-өстенә бәргәли һәм коендыра башладылар. Ул аягына басарга омтылды, тик аның винтовкасы таеп китте дә, ул чак кына егылмый калды. Әхмәди, бөтен көчен җыеп, күзен ачарга теләде. Аяк тавышларын ишетәсе килеп, тирә-ягына колак салды.

«Кая китте соң болар?..» Ләкин берни дә күренми иде, әллә колак шаулый, әллә сулыш саен килеп бәрелгәләп торган дулкыннар шаулый... Ул шунда, гомерендә беренче мәртәбә, үзенә үзе бик кызганыч, бик бәхетсез кеше булып тоелды.

«Их, кеше булдым дигәндә генә... Сугыш беткәндә... сазга батып...» Каяндыр каршысына күзләрен зур ачкан Галимәсе килеп басты, аның итәгенә ябышкан кечкенәләре күренеп китте. Әхмәди ыңгырашып куйды. Аааййй... Юк, аның бөтен җаны-тәне моңа каршы тора, болай үлүне аның акылы сыйдыра алмый иде. Ул, актык көчен җыеп, тагын бер тилпенде. Ләкин су сеңгән авыр киемнәре аны кургашындай аска тарта, аның куллары, аяклары өзлексез калтырый, тезләре батканнан-бата бара, ул хәзер гәүдәсен күтәрә алмый иде инде.

Бу хәл аңа бик озакка сузылган сыман тоелды. Соңыннан бу вакыйганы искә төшергәндә, аның тәненә салкын тир чыга иде.

...Менә кемдер, арттан килеп, аны торгызды, кемдер винтовкасын алды. Дулкыннар шаулавы, су шупырдавы арасында ул Исмаевның ягымлы тавышын ишетте.

— Әй, Әхмәди абый, туганкай, ни булды сиңа? Әй, әй, әй! Синең шикелле карт солдатка болай килешәмени?! Әйдә, киттек кеше-кара күргәнче!..

Исмаев аны култыгыннан эләктереп алды да алга таба әйдәде. Вәлитовның бу изге күңелле яхшы кешегә бик күп рәхмәтләр, җылы сүзләр әйтәсе килде. Тик ул теле белән нинди генә ялкынлы итеп әйтсә дә, рәхмәтенең уннан берсен дә белдерә алмаган булыр иде.

Каршыдан кинәт пулемет уты ачтылар. Моңа кадәр каралып кына күренгән урында, гүя болытлардан аткандай, бик югарыда кызгылт ут чаткылары җемелди башлады. Баш очында пулялар көтүе безелдәште. Алар тора-бара түбәнәйделәр, чыжылдашып суга бәрелештеләр.

Исмаев Әхмәдине ашыктыра башлады:

— Тизрәк! Ул тинтәкләр тидереп тә куярлар, белмәсләр монда... безнең үләсе килмәгәнне.

Куркыныч һәм шомлы су стихиясе белән көрәшеп эштән чыккан тәнгә, кайда икәне, ничек каршы алуы билгеле булган, ничә тапкырлар кара-каршы килеп якалашкан явыз дошман элекке көчен кайтарды. Монда инде һәммә нәрсә дә үз урынында, бөтенесе дә күз алдында иде. Тизрәк чыгарга да ташланырга!

Яр буена җитәрәк, суга тезләнгән тагын берәү күренде. Ул куллары белән су төбенә таянган, аның бүреге юк, озын чәчләре суга тияр-тимәс асылынып тора иде.

Арттан Данилов килә икән. Ул әлеге сугышчының аркасыннан кочаклап алды да җиңел генә аягына бастырды.

— Ах, Петрусь туган! Бу ни эшең бу?— диде.— Нигә шулай сынаттың син, ә?

Митричев кай җирләредер сызланудан ыңгырашып башын түбән иде.

— Аяклар бозылды... басып булмый. Эш начар.

— Син бигрәк инде. Начар, имеш. Синең белән минем хәлнең начар булуына кем ышансын?

Данилов аз гына иелде дә Митричевны җитез генә аркасына атландырып яр буена таба китте.

— Менә хәзер син, Петрусь туган, почти кавалерист инде. Тик минем аркада ияр булмавы гына бераз фасонны боза...

Яр өстендәге дошман пулеметлары тончыга-тончыга аттылар. Су өстенә, эре яңгыр кебек, шыбырдап пуля ява башлады. Прожекторның озын теле, томан эченә сузылып, су өстеннән кызылларны эзләде. Ләкин ул, никадәр тырышса да, яр буендагыларны күрә алмады. Хәер, күрсә дә хәзер соң иде инде.

Менә битләренә туң җирнең салкын, коры җиле килеп бәрелде. Аяк астында, күңелләрне тынычландырып, вак ташлар, тоз катылары кыштырдады. Кешеләрнең өсбашларыннан шыбырдап су ага иде.

Яр буена аяк басуга, Вәлитов тезләнде. Ул җирнең каты балчыгын, салкын ташларын кулы белән капшады, үз тәнендә аларның салкынын һәм ныклыгын сизде; анасына сыенган бала шикелле, сагынып, ышанып, аның туфрагына битен куйды.

Бу вакытта алданрак чыккан роталар, яр буена ышыкланып, дошман өстенә ташланыр өчен өскә таба үрмәлиләр иде.

IX

Текә яр кырыеннан кармаланып диярлек атлый торгач, Шәмси, ниһаять, менеп җитте. Сивашка әйләнеп карамакчы булып борыла гына башлаган иде, куаклар арасыннан тавышсыз-тынсыз зур гына бер папаха калкып чыкты.

— Тукта! Пропуск?

Шәмси пропускны әйтеп часовойдан дивизия штабына юл сорады.

Өстә җил тагын да көчлерәк икән. Ул куакларның шәрә ботагында сызгыра, коры яфракларны кыштырдатып үзәнгә куа, агач башларын атындыра иде.

Аны, штабка барып җиткәнче, тагын ике-өч урында туктаттылар. Пропускны ишетү белән генә чикләнмичә, кайсы частьтан икәнен дә сораштылар, төсен-битен дә караштырдылар. Шушындый ашыгыч арада юлдан бүленеп, часовойлар белән аңлашу башта аның ачуын китерсә дә, ул күңеленнән моның белән килеште: «Җентекләп тикшермәгәндә шпионнар узуы да бар бит!»

Карт алмагачлар арасында Сивашка түре белән утырган тәбәнәк кенә кечкенә балчык өй. Түр тәрәзәдән

бөтенләй якты күренми. Өй янындагы агачка бәйләнгән берничә иярле ат, туп тавышларына әсәренеп, ара-тирә колакларын уйнаткалап, хуҗалары чыкканны көтәләр.

Ишекне ачуга, Шәмсинең борынына махорка төтене кушылган парлы җылы килеп бәрелде. Өйнең алдагы кечкенә бүлмәсе вестовойлар, ординарецлар белән тулган. Алар акрын гына үзара сөйләшеп утыралар. Эчке бүлмәдән телефонистның «Сахалин! Сахалин!» дип, кайсыдыр частьны телефонга чакыруы ишетелә. Ләкин «Сахалин», күрәсең, җавап бирмәгәндер, чөнки телефонист ул исемне өзлексез кабатлый иде.

Шәмси ырып-ерып алгарак чыкты. Почмактагы әрҗәгә утырткан шәм яктысында уч төбе хәтле генә кәгазьнең әле бер ягын, әле икенчесен әйләндерә-әйләндерә бик кыенлык белән укып маташучы озынча йөзле бер командирга якынлашты. Шәмсигә аны штаб башлыгы диделәр. Дивизия командиры һәм комиссар кичтән үк Сивашның теге ягына чыгып киткәннәр икән.

Кәгазь укылып беткәч, Шәмси штаб башлыгының каршысына барып, алып килгән хәбәрен әйтеп салды. Аннары әйтергәме, юкмы дигәндәй, бераз икеләнеп торды да бер-ике сүз үзеннән өстәде:

— Мин монда килеп җиткәндә, Сивашка су бәрә башлады...

Башлык, сискәнеп киткәндәй, Шәмсигә кинәт кенә күтәрелеп карады. Аннары башын иде, нидер уйланды.

— Каты бәрәме? Ничек, тирәнме?

— Юк, әлегә балтырдан узмый.

— Юлда артиллерия очраттыңмы?

— Әйе, күрдем, ике пушка узып китте, батып ятучылары да бар иде.

— Мм... Бик начар хәбәр алып килгәнсең син, бик, бик!..

Ул Шәмсигә тагын берничә сорау бирде дә, көтеп торырга кушып, өйнең эчке бүлмәсенә кереп китте.

Ординарецлар, моны ишетүгә, төрле яктан сырып алып, берсен берсе бүлдерә-бүлдерә сораша башладылар:

— Син нәрсә: су кергәнне үз күзең белән күрдеңме?

— Тукта әле, бу бит, беләсеңме нәрсә дигән сүз? Чынлап та керә башладымыни?

Ординарецларның аңа ышанмауларына, ялганламыймы икән, аяклары коры түгелме икән? дип кайсының-

дыр иелә-бөгелә аның обмоткаларын, шинель итәкләрен капшап каравына Шәмсинең ачуы чыкты.

— Чынлапмы, имеш. Юк, чынлап түгел, шаяртып кына! Андый нәрсә белән шаярырга сез әллә... сез мине әллә... Әнә төшеп карагыз: орудиеләр бата, атлар батып кала, пулемет тачанкаларын чыгара алмыйча азапланып яталар, әле ул гынамы, кешеләр батып үлә!..

Кинәт барысы да тынып калдылар. Болар күбесе шул ук Инза дивизиясенең төрле полкларыннан элемтәгә килгән сугышчылар иде. Һәр кызылармеецка үзенең туган йорты шикелле ук якын һәм кадерле булган үз дивизиясенең, нинди каты бәрелешләрдә дә исән чыккан якын иптәшләренең, ниндидер бер табигать капризы аркасында, бер дә юкка әрәм булу мөмкинлеге барысын да борчый башлады.

Штыгына таянып стенага сөялгән озын буйлы, сакаллы сугышчы, берсенә дә карамыйча, тирән борчу белән әйтеп куйды:

— Бу яктан су басса, теге яктан аклар китереп кысса, менә сиңа!

Почмакта чүгәләп утырган шлемлы, әле мыек та чыкмаган япь-яшь егет сикереп торып сакаллы сугышчы янына килде:

— Беләсезме нәрсә! Анда Буденныйны чыгарырга кирәк. Әйеме? Менә ул акларның арт якларына кыстыра да кыстыра инде утны!

— Әйтеп торалар бит сиңа, Сивашта атлар бата дип!

— Мм.

— Анда бит ышыкланыр урын да, эчәргә су да юк...

Сакаллы кулын гына селтәде.

— Әйтмә инде, безнекеләр патронсыз, снарядсыз шәп-шәрә яр кырыенда ята, ә ак сволочьлар җылы блиндажларда гына яталар. Патроннары күп, снарядның исәбе дә юк. Их...

Бу турыда сүз кузгалуга Шәмсинең Әхмәди абыйсы, аның аягы ачытуга түзә алмыйча, ыңгыраша-ыңгыраша атлавы күз алдына килде дә нәрсәдер йөрәген чеметтереп алды. Чыгар юлларын шулай су баскач, егылып калган булса?!. Ярый ла иптәшләрнең җитәкләп чыгарга башларына килсә...

Перекоп ягындагы орудие тавышлары хәзер тагын да көчәйгән кебек ишетелә башлады. Шәмси, ниндидер бер яңалык ачкандай, чын күңелдән куанып:

— Beləсезме,— дип куйды,— бүгенге сугышның кендеге Перекопта бит! Əгəр илле беренче Перекопны алса... ул чагында безнекелəр исəн-сау!

Башкалар сөйлəгəнне тыңлар-тыңламас почмактагы нярлəр өстендə тəмəке тартып утыручы берəү, битен сары йон баскан, йончыган кыяфəтле бер сугышчы, үчеклəп аны бүлдерде:

— Алса, имеш... Белəсеңмени син Перекопны?!— Ул тəмəке төпчеген ачу белəн идəнгə ыргытып, аны үкчəлəре кыйшайган ертык ботинкасы белəн тибə-тибə сүндерде.— Ансат кына! Белəсеңме син, безнең илле беренче көнгə ничəшəр тапкыр атакага күтəрелə!? Унар тапкыр, унбишəр тапкыр! Күтəрелə дə яртысы тимер чыбыкка эленеп үлеп кала...— Ул ачудан идəнгə төкерде, беркемгə дə карамыйча, карлыккан тавыш белəн тагын дəвам итте:— Алса, имеш! Син башта Перекоп каршысында үзең сугышып кара! Синең алдыңда ун кат заграждение, синең өстеңə əллə ничə орудиедəн, мең пулеметтан өзлексез ут ява, кургашын явып тора, ə син шул җəһəннəмгə каршы уч төбедəй шəрə җирдəн бер винтовка белəн үрмəлисең... Менə шуннан соң тел озайтырсың илле беренчегə!..

Шəмсинең дə яшь əтəчтəй очып кунасы килə башлады.

— Нəрсə син чарт та чорт килəсең, эссе табага салган борчактай? Башта син сугышып, алып күрсəт! Шуннан соң кəпəренерсең.

Стенага аркасы белəн сөялеп торучы сакаллы сугышчы сары йон баскан сугышчыга кулын селтəде:

— Һəй ташласана, зинһар, солдат сүземени бу!.. Безнең унбишенчедə менə шулай зарлану гадəте юк. Командующий иптəш Фрунзе безгə җəяүлəп диңгез кичəргə кушты, без кичтек. Инде илле беренчегə Перекопны да алып бирешегез, егетлəр, дип əйтə икəн, əйдə, пожалуйста!.. Без бер дə алай зарланып тормабыз.

Теге сугышчы сикереп торды да аңа күзлəрен елтыратып ачу белəн карап алды:

— Юк инде, сакал!.. Анысы булмас! Илле беренче башкаларга салынмас! Юк!

— Соң шулай булгач...

Ихтимал, бу əйткəлəшү тагын байтакка сузылган булыр иде, əмма шул вакыт тышта автомобиль фырылдаганы ишетелде. Һəммəсе дə, нинди дə булса яңа хəбəр көтеп, ишек ягына борылдылар. Ишектəн урта буйлы, йомры гына гəүдəле, түгəрəк битле бер кеше килеп кер-

де. Үзен күрүгә «смирно» баскан кызылармеецлар белән бармакларын җәһәт кенә папахасы янына китереп исәнләште дә, туктап тормастан, нык басып өйнең эчке өлешенә узды.

— Командующий!

— Иптәш Фрунзе!

Аның артыннан кайсы шинель, кайберләре кызыл күн тужурка кигән, револьверлар, кылычлар таккан тагын берничә кеше кереп китте.

Бу як берьюлы җанланды. Командующий күренгәнче кайсы кайда сөялеп боегып утырган сугышчылар берьюлы күңелләнеп киттеләр. Хәтта битен сары йон баскан әлеге караңгы чырайлы сугышчыга хәтле ачылып китте.

— Кара әле син аны, кайда килеп чыккан.

— Менә, ичмасам, монысы шәп!

— Менә ул җаен таба да таба инде!

Фрунзе үзе белән шатлык һәм күңел күтәренкелеге алып килде. Әле бер генә минут элек котылгысыз булып күренгән һәлакәттән аның, һичшиксез, котылдырачагына хәзер төпле ышаныч туып килә иде.

Төрле дивизиядән, төрле милләт улларыннан, төрле яшьтә булган бу кешеләр арасында, берсен берсе бүлдереп, ашыга-ашыга аның турында сөйләшү башланды. Аның исемен әйтүләрендә, ул кереп киткән якка зур хөрмәт һәм якынлык белән карауларында сугышчыларда аңа зур ихтирам саклануы сизелә иде. Шәмси күңелендә, үзе моңа бик үк ышанып җитә алмаса да, бәлки иптәш Фрунзе нинди булса да берәр йомыш кушар, дигән өмет тә туды. «Менә шулай булса, э!» диде ул. Фрунзе нинди генә авыр йомыш кушса да, ул, һич икеләнмәстән, бөтен җаны-тәне белән: «Була, иптәш командующий!»—дип хәзер чыгып йөгерер иде.

Шәмси Фрунзены беренче тапкыр моннан бер ай чамасы элек, Фрунзе бу фронтка килеп төшкән көннәрдә үк, сугышка керер алдыннан күргән иде. Командующий боларның авыл кырыенда тезелеп торган полклары янына килеп туктады да тезмә буенча сугышчыларның хәлен сорашып йөрде.

— «Ашау-эчү бик начар түгелме? Туган җирләрегездән хатлар аласызмы?..»

Тик эңгер-меңгер чак, шуның өстенә бик тиз дә узып киткәнлектән, Шәмси аны ул чакта күңеле булганчы күрә генә алмаган иде. Шуннан соң күрше полкның кы-

зылармеецлары «Фрунзе безнең белән үзе дә сугышка керде!» дип бик озакка кадәр мактанып йөрделәр.

Шәмсинең кинәт политрук Исмаев сөйләгәннәр исенә төште:

— Беләсезме,— диде.— Иптәш Фрунзе безнең Казанда да булган бит, бик күптән, патша заманында ук. Политрук шулай ди. Аны кулга алып полиция күзәтүе астына җибәргәннәр. Тик ул икенче көнне үк китеп барган... полициягә әйтеп тормыйча гына...

Ләкин Шәмси монын белән берәүне дә шаккатыра алмады. Нәрсә ул бер-ике көн! Әнә Иваново шәһәре белән Шуяда ул әллә ничә ел яшәгән, эшчеләргә революция ясауда җитәкчелек иткән, Петербургта, Мәскәүдә идән астында акыл җитмәслек хәтәр эшләр башкарган, Стокгольмга партия съездына делегат булып барган. Алар анда Ленинның үзе белән бергә булганнар.

Сакаллы сугышчы:

— Бер сүз белән әйткәндә, революционер инде, аның да иң зурысы,— дип йомгаклап куйды.— Мин аның белән Колчак фронтын буйдан-буйга айкап чыктым. Минә ичмасам командир! Солдат шинеле генә киеп йөрсә дә, бик башлы генерал ул, Кутузов шикелле! Акларның нинди зур генералларына тын да алырга ирек бирмәде, ботарлап кына ыргытты!

Битен сары йон баскан теге сугышчы урыныннан торып арлы-бирле йөренгәли башлады.

— Кая, дивизиягә кайтасы иде. Болай булгач, илле беренче Перекопка бәреп кермичә туктамый инде! Юк! Хәзер приказ да булыр.

Сакаллы, күңеле булып, сакал очын сыпыргалап алды:

— Менә ичмасам монысы солдатча!

Фрунзе килеп кергәч, эчке бүлмәдәгеләр аягүрә бастылар. Штаб башлыгы, итек үкчәләрен бер-берсенә бик шәп бәреп, тантана белән рапорт бирергә тотынды. Командующий кулы белән ишарә итеп аны шунда ук бүлдерде:

— Алары турында беләм. Иң соңгы хәбәрләрдә нинди яңалыклар бар?

Штаб башлыгы тагын бер тапкыр аягын аякка орып куйды.

— Дивизия Литовский ярымутравына чыгып җиткәннән соң һөҗүм башлады. Атаканың нәтиҗәсе билге-

ле түгел, чөнки Сивашка бәреп кергән диңгез суы дивизияне теге якта бүлеп калдырды, элемтә өзелде, Сиваш суы телефон кабелен ашый...

— Ә пулеметлар, артиллерия?!.

— Теге якка чыгып җитүләре турында тулы хәбәр юк әле.

Фрунзеның түгәрәк дип әйтерлек тулы йөзе ничектер берьюлы сулыгып, агарынып китте, ул, гүя тыны буыла башлагандай, шинель якаларын чишеп җибәрде. Әгәр дошман, унбишенче дивизиянең шундый кыен хәлдә калуын белеп, бөтен көче белән аңа ташланса? Гаскәре әле һаман да көчле бит аның. Дроздовның офицер полклары, генерал Барбовичның атлы армиясе... Кургаш, чуен давылы... Ул вакытта... Әйе, ул вакытта эш начар. Ул инде катастрофа. Бөтен дивизия кырылып бетәчәк. Ул гынамы әле? Бөтен план сүтеләчәк, тар-мар киләчәк... Тукта әле! Хәзер үк нидер эшләргә кирәк. Командующий, Сиваш ярыннан ялангач кул белән генә диярлек дошманның окопларына таба үрмәләп менүче, йончыган, күбесе яраланган сугышчыларын артиллерия һәм пулемет утыннан үз гәүдәсе белән саклап калырга омтылгандай, бөтен ихтыярын җыеп чытырдатып кыскан йодрыклары белән өстәлгә таянды. Өстәл шыгырдап китте. Юк! Алай булырга тиеш түгел, булмас та!

Фрунзе аның әмерен көтеп тын калган штаб башлыгына һәм бүтән командирларга таба борылды. Аның тавышы кискен, сүзләре яңгырап ишетелде:

— Строгановканың ревкомына командующий исеменнән әйтегез: авылның эшкә яраклы барлык халкын Сиваш кичүен ныгытырга алып чыксын. Хәзер үк! Күрше авылларга да шундый ук боерык җибәрелсен!

— Тыңлыйм, иптәш командующий!

Штаб башлыгы чыгарга дип борылганда, Фрунзе кулын күтәреп аны туктатты:

— Дивизиягә атлы элемтәчеләр җибәрегез. Монысы да хәзер үк!

Штаб башлыгының бераз икеләнүен күреп, командующий аңа текәлебрәк карады.

— Нәрсә әйтмәкче буласыз?

— Гафу итегез, Михаил Васильевич! Су шушылай өзлексез өстәлеп торганда, Сивашны атлылар кичә алырмы икән дигән шигем бар...

Фрунзеның коңгырт кашлары сизелер-сизелмәс кенә тетрәнеп китте, тавышы яңгырабрак ишетелде:

— Ә сез ул шигегезне башыгыздан чыгарып ташлагыз, бу эшкә дә шикләнеп тормаслык батыр сугышчыларны җибәрегез! Бардыр бит сездә андый егетләр?

— Тыңлыйм, иптәш командующий! Бар, бар, табарбыз!

Штаб башлыгы чыгып киткәннән соң, Фрунзе яңадан өстәл янына килеп басты. Тәрәзә ярыкларыннан кергән җил өстәлдәге кечкенә лампаның утын җилпендерә иде. Димәк, җил көчәйгән, димәк, су тагын да көчлерәк керә башлаган... Фрунзе сәгатенә күз салды. Төнге унбер тулып килә. Унбер... Аның исәбенчә... Шул вакыт тышта ниндидер дөпелдәү, берьюлы бик күп кеше узып киткәндәй тонык кына аяк тавышлары ишетелә башлады.

— Карап карегезче, атлы дивизия килмәдеме икән анда?

Озак та үтмәде, әлеге дөпелдәү тавышлары ишетелмәс булды, ишектән озын йонлы кара бүрек кигән, шпорлы, кылычлы бер командир килеп керде.

— Җиденче кавдивизия сезнең боерыгыгыз буенча килеп җитте, иптәш командующий!

Михаил Васильевич үз каршысында басып торган атлының чын кавалерия командирына хас пөхтә һәм җыйнак өс-башына, егетләрчә килешле буй-сынына бик ошатып карап торды.

— Яхшы!— диде.— Сезнең дивизияне зур тәвәккәллек, чиктән тыш фидакарьлек сорый торган ифрат катлаулы сугышчан бурыч көтә. Мин уйлыйм, сез моңа хәзердер?

Дивизия командиры, зур гәүдәсен турайтып, кулын җәһәт кенә козырегына куеп алды. Аның шпорлары зыңгылдап куйды.

— Кавдивизия, бөек революция казанышларын саклап калу өчен, утка да, суга да керергә әзер, иптәш командующий!

Фрунзе, бу зур сүзләрне ишетүенә куанып, әмма боларны дивизия командирының да ул аңлаганча тирән һәм чын мәгънәсендә әйтүенә ышанасы килеп, дикъкать белән, бераз елмая төшеп, командирга карап торды.

— Гади су гынамы әле!— диде.— Мин уйлыйм, сезгә хәзер диңгез кичәргә туры килер, чын диңгез!

— Революция солдатларын берниндн кыенлык та туктата алмый, Михаил Васильевич! Атлы дивизия диңгез кичәргә дә әзер!

Командующийның йөзе яктырып китте, ул, ихтирам белән башын иеп, командир булып түгел, бәлки өлкән иптәш һәм остаз булып, чын күңелдән аның кулын кысты:

— Рәхмәт, бик рәхмәт!— диде.— Безнең дошманнарыбызда була алмый торган иң көчле, иң җиңелмәс коралыбыз да шул: туган илгә чиксез мәхәббәт, көрәштә тиңе булмаган фидакарьлек! Мин сезгә ышанам! Әйдәгез, күрсәтегез лачыннарыгызны!

Фрунзе чыкканда, кавалерия дивизиясе, берничә саф булып, бакча алдындагы мәйданга тезелгән иде. Төн караңгысында тоташ кара масса булып күренгән атлылар ягыннан авызлыклар чылтыраганы, атларның пошкырулары ишетелгәләде.

Командующий, уң канаттан башлап, сафларның алдыннан әйләнеп чыкты. Аты янына баскан килеш, тын гына аңа карап калучы кызылармеецларның йөзен күрәсе, хәлләрен сораштырасы килде. Ләкин, кызганычка каршы, күреп булмый, караңгы, вакыт та бик кысан иде.

Командующий аларның алдында йөри-йөри басынкы гына тавыш белән берничә сүз әйтте:

— Безнең атлы армиябез дошманны әзәрлекләп урманнарны, далаларны, ком сахраларын кичте. Атлы армия үз юлында контрреволюцияне кырып-себереп меңәр чакрымлы походлар узды. Мин ышанам, иптәшләр, без сезнең белән бу соңгы дошманны да юк итәрбез. Сезнең җәяүле иптәшләрегез теге якта бүленеп калды. Дошманның каршылыгын сындырыр өчен, аларга ярдәм кирәк, сезнең, атлыларның, шул якта булулары кирәк!

Фрунзеның бу сүзләренә меңнәрчә сугышчы басынкы гүләп җавап бирде.

Командующий кулын папахасына күтәрде:

— Хәерле сәгатьтә, иптәшләр!

Шунда ук команда тавышы ишетелде. Дивизия, җәһәт кенә кузгалып, Сиваш ярына төшеп китте. Михаил Васильевич, атлыларны озата барып, Сиваш ярына килеп басты. Сиваш өстендәге томан күтәрелә башлаган. Астан ат аяклары чупырдаганы, акрын гына сөйләшүләр ишетелә иде.

Фрунзе, гүя Сивашның аръягында барган каты бәрелешне үз күзе белән күрергә, сугыш авазын үз колагы белән ишетергә теләгәндәй, бөтен барлыгы белән шунда омтылып канонаданы тыңлый башлады. Теге якта, бер дә тынып тормастан диярлек, туп тавышы гөрсел-

ди, командующийга хәтта Сивашның аргы як ярында ялкыннар күренеп киткән төсле була, арада ашыгып-ашыгып пулеметлар тыкылдый, шушы аяусыз бәрелеш, шушы үлем сугышы торган саен көчәя бара. Бая штаб башлыгының артиллериянең теге якка чыгып җитүе турында хәбәр юк диюе исенә төште. Әйе, аяныч хәл. Ләкин, нишләмәк кирәк, дөресе шулай. Аклар артиллериясе ата, бары аларныкы гына. Алай да... шул арада гына бу кадәр артиллерия Литовский ярымутравына кайдан килергә мөмкин? Перекоп белән ярыматауның ике арасы еракмы соң әле? Тукта, әллә... Фрунзе, аркасына салкын үткәндәй, хәтта иңбашларын җыерып куйды. Әнә бит ничек! Перекоптан күчерәләр булса кирәк. Мөгаен, шуннан...

Командующий, башына ниндидер әһәмиятле бер уй төшүгә, җәһәт адымнар белән әлеге кечкенә өйгә кайтып керде. Үзе белән йөрүче адъютантына:

— Илле беренчене! — диде.— Тизрәк!

Ул, ниндидер бер кискен карарга килгәндәй, нык адымнар белән тәрәзә каршындагы кечкенә өстәл янына килеп басты. Адъютант аның алдына дошман ягының картасын китереп җәйде.

Михаил Васильевич соры папахасын салып, картадан күзен алмыйча гына, өстәл читенә куйды, бераз күшеккән бармаклары белән щеткадай туры басып торган куе коңгырт чәчен артка сыпырды. Ул хәзер картадагы сызыкларны түгел, бәлки сугыш кырының үзен күрә иде. Фрунзе, тәҗрибәле командирга хас бер сиземләү көче белән, Инза дивизиясе Сивашны кичеп өстенә ташлануга дошман ягында каушап калуларын, анда ыгы-зыгы кузгалуын сизә. Ләкин дошман тәҗрибәле, шул арада ул инде аңына килеп тә өлгергән. Ул диңгез кичкән дивизияне, ныгып өлгергәнче, Сиваш буенда кырып салырга ашыга. Аның артиллериясе, пулемет тачанкалары Перекоптан Сиваш буена агылалар. Командир меңнәрчә, ун меңнәрчә сугышчыларны үз теләгенә буйсындыра ала торган, хәзер аның акылына, бөтен күңеленә җиңелмәстәй булып тупланган ихтыяр көче белән дошманның бу явыз ниятен җимереп ташларга омтыла. Ул Сивашны кичүче атлы дивизия алдына, гүя аңа ашыгырга боерык биргәндәй, кулын бер тибрәтү белән атылган яшендәй кызыл ук ясап куйды. Фрунзеның җитез карандашы Сиваш ярындагы Инза дивизиясенә тукталды. Ул башын бора төшеп:

— Элемтә булдымы инде? —диде.

Штаб башлыгы шпорлы аякларын ачу китерерлек дәрәҗәдә зыңгылдатып бергә басты:

— Һаман да юк әле, иптәш командующий!..

Фрунзе, үзенең боерыкларын көтеп торучы адъютантына һәм башкаларга борылып карауга, аларның кызарган күзләренә, арыган, йончыган кыяфәтләренә күзе төште. Аның үзенең дә ике тәүлеге йокламыйча аяк өстендә узды, кайчандыр полиция яралаган тез башы әле хәзер дә үзәккә үтеп сызлый, кайвакыт күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китә иде. Михаил Васильевич, каты бәрелмәскә тырышып, шулай да кискен итеп һәм кистереп, баягы боерыгын тагын бер кабатлады:

— Илле беренчене алмыйча һич ярамый! Һич!

Почмактагы телефонист ярым кычкырып, аннан тагын шыпыртлап, бер ачулы, бер ялынулы тавыш белән әллә сиксәненче, әллә йөзенче тапкыр илле беренчене дәшәргә тотынды.

Кайсыдыр урындыкны тавышсыз гына командующийга якынрак этәреп куйды. Ләкин Фрунзе картаның Инза дивизиясе барып чыккан җиреннән күзен дә алмады. Аның күңеле сизә: Перекоп өчен барган сугыш әнә шунда хәл ителә, менә хәзер, шушы сәгатьләрдә хәл ителә! Гүя командующийның бу фикерен раслагандай, Сивашның аръягындагы канонада тагын да дәһшәтлерәк, тагын да шомлырак булып ишетелә башлады.

Шул вакыт почмактагы телефонист, куанычыннан балкыган йөз белән, телефон трубкасын Фрунзега сузды.

— Иптәш командующий! Илле беренче линиядә!

Фрунзе тагын сәгатенә күз салды. Төнге унике тулып килә. Ул, иң җаваплы, иң авыр сугыш операцияләрен хәл иткән вакыттагыча үз өстендә чиксез җаваплылык һәм рух күтәренкелеге сизгән хәлдә, җиңел атлап телефон янына килде. Трубкада таныш командирның тавышы ишетелде. Исән, таза-сау икән! Михаил Васильевичның арыган йөзе иң якын кешесен очраткандагы кебек яктырып, матурланып китте. Тик ул шунда ук янадан сүрелә, тоныклана башлады. Таныш командир куанычлы хәбәрләр сөйләми иде. Перекопны атакалау һаман да уңышсыз чыга икән, чөнки тимер чыбык киртәләрен, орудие һәм пулемет ояларын җимертү өчен пушкалар җитми, снаряд та бик аз. Шуның өстенә, җир туңган, окоп казып булмый, югалтулар бик зур...

Бүлмәдә Фрунзеның басынкы, әмма нык тавышы яңгырый башлады:

— Әгәр кыен булмаса, монда безнең кирәгебез дә калмас иде. Сез аңлыйсызмы? Литовский ярымутравына бәреп чыккан дивизияләрнең хәле начар, бик начар! Дошман үз артиллериясенең байтагысын сездән алып, шунда күчерде. Сез, шуннан файдаланып, барлык кораллар һәм гаскәр көче белән хәзер үк өзлексез, туктаусыз штурм башлагыз. Перекопның Төрек валын хәзер үк алыгыз! Мин сезне бер-ике сәгатьтән я Кырымга бәреп керүегез белән тәбрик итәм, я без бүтән күрешә алмыйбыз! Хушыгыз!

Фрунзе моны шундый тирән ышаныч, каршы әйтү мөмкин булмаган шундый тавыш белән әйтте ки, бүлмәдәгеләр башта бөек тантана минуты кичергәндәй тынып калдылар, аннан соң күңелләләнеп, үзара шыпыртлап сөйләшә, фикерләрен уртаклаша башладылар.

Бүлмә җанлана төште. Алдагы бүлмәдә приказ көтеп торучы ординарецлар, өс-башларын төзәткәләп, йомыш белән китәргә хәзерләнә башладылар.

Михаил Васильевич картадагы кызыл укларга тагын күз салды. Әнә шул уклар барып туктаган урында сусыз, юлсыз, кыргый бер урында, ун меңнәрчә сугышчылар җаннарын аямыйча сугышып яталар. Аларның артында суы ишәеп килә торган Сиваш сазы, алларында — дошманның ныгытмалары, йөзәрләгән пулеметлары, орудиеләре. Менә шундый вакытта аларның җиңүгә ышанычларын ныгытырга, дәртләндереп җибәрергә кирәк...

Фрунзе, гүя үз янындагылар белән киңәш иткәндәй:

— Менә бит ярлылык нишләтә,— диде.— Дивизиядә радиостанция булса, без хәзер дошманга сулыш алырга да ирек бирмәс идек!

Штаб башлыгы, бүлмәгә кереп:

— Атлы элемтәчеләр хәзер кайтырга тиеш, иптәш командующий!— диде.

— Ярый, утырыгыз әле. Ул гына җитми бит. Даими элемтә кирәк, телефонны эшләтергә кирәк! Нинди чаралар күрдегез?

Штаб башлыгы яңадан сикереп торды, аякларын бик тырышлык белән бер-берсенә бәреп зыңылдатты, уң кулын ялт иттереп фуражкасына күтәрде.

Фрунзеның калын коңгырт кашлары сизелер-сизелмәс кенә җыерылып куйды:

— Утырыгыз, зинһар!

Башлык, Фрунзе каршысындагы урындыкның бер почмагына гына утырып, Фрунзега текәлде.

— Я, сөйләгез!

— Элемтә башлыгының бер тәкъдиме бар барын. Дөресрәге, аны кызылармеецлар үзләре уйлап тапканнар. Ләкин... белмим. Устав күзлегеннән караганда...

— Бәлки уставка салып соңыннан үлчәрбез?.. Сөйләгез, нинди тәкъдим?

Штаб башлыгы сөйләгәндә, Фрунзе, аның сүзен бүлдермичә, картада нидер үлчәде. Аның күзләрендә, эчке ялкынны, дулкынлануны чагылдырып, җитез очкыннар күренеп узды. Чыраенда нәрсәнеңдер тирән мәгънәсен төшенергә тырышу киеренкелеге, шуның белән бергә куану сизелә иде. Ул торды. Шинель кесәсенә кулын тыгып, берничә мәртәбә ишек ягыннан әйләнеп килде.

— Безнең сугышчыларыбыз искиткеч кешеләр! — диде. — Миңа алар белән Колчак фронтында да, Төркстан фронтында да һәрвакыт янәшә торып сугышырга туры килде. Андый кешеләр ничек җиңмәсен? — Ул штаб башлыгы каршысына килеп басты. — Сезнең дивизиянең элемтәчеләре тиңсез батырлык эшләргә җыеналар. Сугышчыны революциягә хезмәт итү куанычыннан мәхрүм итәргә безнең хакыбыз юк. Алар күрәчәк кыенлыкларны җиңеләйтү өчен, мөмкин булган бөтен чараларны күрегез!

— Тыңлыйм, иптәш командующий!

Штаб башлыгы алгы бүлмәнең ишеге төбендә чүгәләп утырган элемтәчеләргә нидер әйтте. Тегеләре шунда ук чыгып йөгерделәр.

Фрунзе приказын илтү өчен тагын берничә ординарец күрше авылларга һәм дивизияләргә чыгып чапты.

— Кара, нинди тиз тота! — диде сакаллы.

Алдагы бүлмә бушап калды. Анда хәзер теге, битен сары йон баскан сугышчы да, яшьрәге дә юк иде. Бик еш кереп-чыгып йөрергә туры килгәнлектән, эчке бүлмәнең ишеген ябмый гына калдыра башладылар. Шәмси ишек янагына килеп сөялде.

Командующий, өстәлгә таянган килеш, тәрәзә аша каядыр еракка карап, һәр сүзен аеруча түгәрәкләп әйтә-әйтә боерык яздыра иде:

— ...Сез төнге караңгыда, искиткеч кыен шартларда, су һәм пычрак ерып, дошманның өзлексез атып торган артиллерия һәм пулемет уты астында, баһадирларча

батырлык һәм соклангыч түземлелек белән Сиваш сазын кичтегез, дошманның тылына бәреп кердегез. Сезнең шушы бөек фидакарьлегегез белән бөтен Россия, барлык эшче-крестьян халкы горурлана. Революцион халык бу батырлыкны мәңге онытмас!..

Шәмси белән сакаллы сугышчы командующийның сүзләрен, гүя стройда тыңлагандай, аягүрә басып, дулкынланып тыңладылар. Фрунзеның теге як яр буенда сугышчы иптәшләренә рәхмәте аларда горурлык уятты. Алар: «Тизрәк кайтып сөйләргә иде бит!» дип уйладылар.

Фрунзе, кулларын артына куеп, бүлмәдә әйләнгәли башлады. Ул ихтирам белән читтәрәк басып торучы адъютантны да, бүтәннәрне дә күрми иде бугай. Аның уйлары еракта, теге якта, ул үзен хәзер дошман белән якага-яка килеп үлем сугышына ташланган батыр сугышчылары янында кебек хис итә, ул аларга дәрт өстәргә, аларның рухларын күтәрергә тели иде.

— ... Дошман никадәр генә мәкерле булмасын, нинди генә каршылыклар күрсәтмәсен, ул хәзер актык сулышын сулый, аның актык минутлары җитте. Врангель армиясен, революция казанышларына кул сузучы иң соңгы, иң мәкерле бу ак генералны шушы көннәрдә үк тар-мар итеп, ирекле Россия халкын сугыш бәласеннән коткару өчен...

Шәмси, Фрунзедан күзен ала алмастан, аның гадилегенә гаҗәпләнеп карап тора торгач, аның йөзендә, бөтен торышында ниндидер бер олылык, ниндидер бер гаҗәеп куәт барлыгын сизде. «Революционер булганга, Ленин белән бергә эшләгәнгә шулайдыр... Менә нинди икән ул!..»

Командующий әйтеп яздырганнарын укып чыкты да кул куйды. Штаб башлыгы, бу якка чыгар-чыкмас, ишекне киңрәк ачып сакаллыны үз янына чакырды:

— Кайсы полктан?

— Йөз дә утыз икедән.

Башлык шул ук сорауны Шәмсигә дә бирде.

— Мин дә шул полктан.

— Алай...

Штаб башлыгы язып утыручыдан пакетны алгач, гүя ике сугышчыны бер-берсенә чагыштыргандай, боларның икесенә дә карап алды. Әмма яшьрәк тә, ныграк та күренгәнгәме, пакетны Шәмсигә сузды:

— Инза дивизиясенең командирына бирәсең, үз кулына!

— Тыңлыйм. Әгәр командир үзе... ни булса?

Шәмси, сорауны штаб башлыгына бирсә дә, бер күзе белән Фрунзены күзәтә, аның да ишетүен, үзенә игътибар итүен тели иде.

— Ул чагында аның урынына калган командирга, я комиссарга тапшырасың. Аңладыңмы?

— Әйе, аңладым!

Фрунзе чыннан да игътибар итте. Ул, җитез генә, сакаллы белән Шәмсинең өс-башларына күз төшереп алды. Шәмсигә аеруча төбәлеп карады, хәтта шинеленең сүтелә башлаган җиң төбен дә күрде. Һәрхәлдә, Шәмсигә шулай тоелды. Ул командующий алдында оятлы булудан кызарып китте. Әмма Фрунзеның коңгырт-яшел күзләре ягымлы карыйлар иде. Тик Шәмсинең ботинка сымак нәрсәсенә күзе төшкәч кенә, аның кашы җыерылды.

— Туңмыйсызмы? — диде ул.

— Юк, туңмыйбыз! — диде Шәмси. Болай гына аңлашылмас кебек тоелды да тагын өстәп куйды: — Туңып торырга вакыт калмый, иптәш командующий.— Тик болай дию дә канәгатьләндермәде. Фрунзены чынчыннан ышандыру өчен тагын нидер әйтәсе килә иде.— Туңа башласак, йөгерәбез, иптәш командующий.

Адъютант нигәдер читкә карап кына көлеп куйды.

Фрунзе, гүя Азов диңгезеннән искән җилнең җуылдавын тыңлагандай, бераз тышка колак салып торды да Шәмсигә сорау бирде:

— Сивашның суы һаман тирәнәя. Юлны таба алырсыңмы?

Шәмси «смирно» басты.

— Табармын, иптәш командующий! Мин аннан бая бер узган идем инде.

— Тиз чыгып җитәргә кирәк, бик тиз!

— Йөгерәм генә, иптәш командующий.

Фрунзе, көлемсери төшеп, сизелер-сизелмәс кенә баш какты.

X

Бая килгән туры сукмактан Сивашка төшкәч, Шәмси чыбык-чабык һәм салам төягән атлар, кирәк-сәнәк күтәреп эчкә таба кереп барган бик күп авыл кешеләрен күрде. Аларның байтагысы эшкә дә тотынган, ашыга-

ашыга канау казыйлар, балчык белән салам өеп, юлны биекләтәләр иде.

Хәзер инде томан күтәрелә төшкән, кичке төсле үк караңгы түгел иде. Аяк асты пычрак, күп урыннарда су ерып чыгарга туры килгәли.

Аңа фронт ягыннан кайтып килүче яралы сугышчылар очрый башлады. Бер кызылармеецтан сорап, ул үз полкының да хәлен белде. Алар Литовский ярымутравына моннан өч-дүрт сәгать элек үк чыгып җиткәннәр, анда хәзер каты сугыш бара икән. Яралы сугышчы аңа кайбер күңелсез нәрсәләр дә әйтте: патрон бетеп бара, гранаталар да җитми. Кирәк-яракны арттан китерүе бик кыен. Диңгездән бәргән көчле җил, суны Сивашка куып, күп урында юлны өзгән.

Дивизия бу кыенлыктан ничек котылыр икән? Иртәгә таң атканда кем кайда булыр, кем кырылып бетәр, кем җиңәр?

Юл кырыенда батып калган арбалар, тачанкалар эчкәрәк кергән саен ешрак очрый башлады. Бераз баргач, Шәмси ал тәгәрмәчләре белән чаклакка килеп кергән орудие янынннан узды. Тупчылар аны тартып чыгармакчы булып азапланалар. Әнә тагын берәү, әнә тагын...

Шәмси, дулкынланып һәм борчылып, атыш тавышына колак салды. Перекоп ягында өзлексез орудиеләр гөрселди; аның дивизиясе сугышкан якта да каты бәрелеш бара иде булса кирәк. Шәмсине шунда тартты. Әйе, ни күрсә дә иптәшләре белән, үз дивизиясе белән бергә күрер иде. Бу инде иң актык сугыш буласы бит. Бүгенгесе бәлки иң ахыргы сугышның да иң соңгы көнедер. Аннан соң яңа тормыш, тыныч көнкүреш башланырга тиеш. Әнә шул яңа тормыш ниндидер зур эш башкарырга өндәп, күңелне кытыклый, ашкындырып тора иде.

Каршыдан ике кызылармеец килеп чыкты. Аларның берсе иптәшенең иңбашына тотынган, аягын көч-хәл белән генә сөйри, ара-тирә ыңгырашып куя иде.

— Я, ничек анда?

— Әнә, ишетәсең бит! Үлем сугышы бара... Кыл өстендә.

Алар, башка сүз әйтмичә, акрын гына атлап узып киттеләр.

Эчкәрәк кергән саен, орудиеләр тавышы һаман якынлаша барды. Хәзер инде ара-тирә винтовка тавышлары белән гранаталар шартлавы да ишетелгәли иде.

Менә аның уң ягында кинәт кенә бер шәүлә калыкты. Шәмси карангыда аеруча зур булып күренгән бу кешенең монда, Сиваш уртасында, берүзе нишләп торуын төшенеп өлгергәнче, ул, карлыккан тавыш белән:

— Кабельгә бәрелмә! — диде.

Шәмси гаҗәпләнеп калды. Ул телефон чыбыгын күрмәгән иде.

Бая, ул штабта чагында, иңнәренә кабель кәтүкләре аскан берничә кызылармеец штаб башлыгы белән телефон турында нидер киңәшкәннәр иде. Шунда ул бер кызылармеецның, башлыкны ышандырырга тырышып, ялкынланып сөйләвен ишетеп калган иде.

— «Беләсезме, бүтән чара юк, телефон чыбыгын башкача саклап калып булмый. Безгә ышаныгыз!»

Тик ул әңгәмәнең шуннан соңгысын тыңламый калды. Сивашның авылга якын җирендә пычракка кадалган озын таяклар да күренгән иде. Күрәсең, телефон кабеле анда шул таякларга эленгән булгандыр.

Бераз гына баргач, юл кырыенда тагын бер карамчык күренде. Кызылармеец бер кулын куенына яшергән, нәрсәнедер изгәндәй аягын алмаш-тилмәш атлый, аның аяк астында баскан саен су шупырдый. Бер кулы белән ул, бик кадерле нәрсәне саклагандай, иңенә салынган телефон кабелен тотып тора иде.

Баганалар урынына — ертык ботинкалы, алама киемле, дерелдәп, туңып беткән кызылармеецлар үзләре басканнар. Кыргый утрауда бүленеп калган дивизия җиңсен өчен, Кызыл Армиянең исеменә «җиңелде» дигән тап төшмәсен өчен, Фрунзеның боерыгы ул әйткән вакытта, нәкъ ул әйткәнчә үтәлсен өчен, алар, бу бер төркем гади кешеләр, үз карамакларында булган иң соңгы һәм иң кыйммәтле, башка берни белән дә алмаштырып булмый торган нәрсәне — үзләрен, үзләренең тәннәрен, җаннарын, ялкынлы йөрәкләрен, туган илләренә тирән мәхәббәтләрен корал итеп, авыр постка басканнар.

Төн. Яр буендагы учаклар күптән үк сүнгән. Сивашның өстен кара болытлар каплаган. Су уртасы. Ул су бөтен тирә-якка җәелгән. Тозлы суның зәһәре тәнне ашый, сыкратып ачыттыра, салкыны сөякләрне сызлата. Аякларны Сиваш сазы суыра, аның суы күтәрелә-күтәрелә, үлем салкыныдай, һаман югарырак үрмәли. Ә алар баскан урыннарында нык торалар. Аларны берни дә, хәтта үлем үзе дә постларыннан ала алмас кебек.

Шәмси телефон чыбыгы күтәреп торучы сугышчыларны утыз-кырык адым киткән саен очрата башлады. Аларның кайберсе баскан урынында тик тора, кайберләре җылынып өчен сикергәлиләр, кайсылары, авыз эченнән нидер көйләп, баскан урынында марш атлый. Шулай да алар монда булганга, әнә шулай батыр торганга, җансыз Сиваш җанланган, аңа тереклек кергән иде.

Берсенең янынпан узып барышлый Шәмси, аның бөкрәеп торуына гаҗәпсенеп, акрынлый төште. Аның бер аягы тез тиңентен баткан, икенче аягы белән пычрактан чыкмакчы булып азаплана, бөтен гәүдәсе белән дерелди иде. Шәмси килгәч ул, тыныч булырга тырышып:

— Кабель суга төшә... Алда безнекеләргә әйт! — диде.

Шәмси аңа катырак урынга чыгарга булышты. Тик ул инде җылына алмаслык булып туңган иде.

Шулай бата-чума бара торгач, Шәмсинең колагына таныш бер көй чалынды. Көй якынайган саен ачыклана барды. Бераз карлыккан калын тавыш белән әлеге элемтәче сугышчыларның берсе көйли икән.

Смело, товарищи, в ногу...

Җырлаучы баскан урынында җыр көенә атлый, аның гәүдәсе салмак кына тирбәлә, аяк астында су тавышлана иде.

Җырга Шәмси дә кушылды. Ул, авыз эченнән җырлый-җырлый, кызурак атлый башлады. Җырга әллә Сиваш эчендәге һәммә кызылармеецлар да кушылдылар, әллә ул бөтен җаны-тәне, йөрәге белән җырлаганга шулай ишетелде, әмма җыр торган саен көчәя барган кебек иде.

Духом окрепнем в борьбе...

Перекопта туплар гөрселдәде. Ярымутрауда, берсен-берсе бүлдереп, гел якыная барып пулеметлар тавышландылар. Шәмси, Фрунзеның приказын күкрәгенә кысып, күңеленнән җырлый-җырлый шунда таба йөгерде.

XI

Кояшның кызыл-сары түгәрәге уңдагы түбә артына иңә башлады. Якын-тирәгә, көннең яктылыгы әле сүнеп бетмәгән, караңгылык әле куерып җитмәгән бер кыска

вакыт эчендә, көзге җилсез кичләрдә генә була торган йомшак бер тынлык урнашты. Җир өсте, тирә-юньдәге барлык әйберләр, кешеләрнең арыган, йончыган йөзләре — һәммәсе дә тынлыкка, ялга өнди торган тыныч төскә өртелделәр. Су өсте шундый тын, шундый тыныч, әйтерсең, ул мәңге шулай, әйтерсең, монда әле узган төндә генә ак башлы дулкыннар чабышып йөрмәгән, ул дулкыннар кешеләрне, атларны батырмаган. Тик әллә нидә бер, әле тегендә, әле монда, ялангач кылыч ялтырап киткәндәй, көзге кыйпылчыклары тибрәнеп куйгалый.

Ничектер, нәкъ шул вакытка туры килеп, атыш тавышы да тынды. Билгеле, аның туктавына үз сәбәпләре булгандыр. Шулай да ул бөтен тирә-якны урап алган шушы тынычлык йогынтысына буйсынып тукталгандыр кебек хис ителә иде.

Кызыл-сары түгәрәк, иңә барып, күздән үк югалды. Ул офыкта дугайланып эленеп торган йомшак алсу бизәген калдырды. Бизәк торган саен саргая барды, бераздан сарысы уңып төссезләнде, җир өстенә караңгы төшә башлады.

Данилов, шинель якасын тарткалап, окобыннан торып утырды. Бу гаҗәеп тынлыкка, күптән булмаган бу хәлгә сәерсенеп як-ягына колак салды. Ник бер генә шылт иткән тавыш ишетелсен! Шундый тынлык, хәтта, мондыйга күнекмәгәнлектән, колаклар чыңлый.

Ләкин шундук яр астыннан ыңгырашкан тавышлар ишетелде. Взвод командиры авыр сулап көрсенеп куйды. Яр кырыена арка биреп, гүя сугышның мингерәтүеннән айнып җитмәгәндәй, тавышсыз-тынсыз гына бөрешеп утырган сугышчыларына күз салды, күзләрен генә йөртеп аларны яңадан барлап чыкты... Унөч, ундүрт, унбиш, уналты... Егерме биштән уналты... Бер көн эчендә...

Сугышчыларның чиктән тыш эштән чыгып арудан һәм тирән кайгыдан әнә шулай башларын иеп утырулары тагын бер фаҗигане исенә төшерде, аның тәне эсселе-суыклы булып китте. Кояш баешына, аннан караңгы каплый башлаган яр өстенә карап торды да, командир, урыныннан торып, карабинын иңенә алды.

— Кемнәр бара?

Винтовкаларына таянып, тавышсыз-тынсыз гына башта Шәмси белән Әхмәди, алар янына тагын берничә сугышчы торып бастылар.

Взвод командиры берсенә дә төбәп карамыйча гына:

— Кайчы кирәк булыр,— диде.

Шәмси аңа бил каешына эленгән шактый ук зур кайчысын күрсәтте.

Алар, тагын бераз өскәрәк күтәрелеп, акларның ашыгыч казылган сай окоплары буеннан киттеләр. Калку бер урында, унлап сугышчы тирән тынлык эчендә озынча чокыр казып яталар. Шунда таба төрле яктан носилкалар җыела, носилкаларда авыр йөк булып атына-атына, гомер юлларының иң соңгы адымнарын узучы сугышчылар, туган иленең бәйсезлеге, аның кадерле туфрагы өчен һәлак булган, әле тәнпәре дә суынып өлгермәгән батырлар җыела.

Данилов, як-ягына карангалап, кичә төнлә Сивашны ерып чыккач яр өстенә кайдан үрмәләп менүләрен, дошман белән кай төштә якага-яка килешүләрен күз алдына китерергә тырышты. Әнә шул тирән чокыр эченнән күтәрелгәннәр иде бугай. Менеп җитүгә, тынны буардай пулемет уты җиргә егылырга мәҗбүр итте. Ләкин алар барыбер чигенмәделәр, шушы салкын, шәрә җирдән, кулларын каната-каната, тешләре белән алга үрмәләделәр. Дөресен генә әйткәндә, чигенер урын да юк иде. Әнә аяк астында канга буялган марля кисәкләре, буш гильзалар аунап ята, адым саен диярлек дары исе бөркеп сасып яткан снаряд чокырларын әйләнеп үтәргә туры килә. Менә монда, менеп җитүгә, күп кеше кырылды, арырак узгач, әнә ул кашлак җирдә, икенче атака вакытында — тагын да күбрәк... Әмма иң кыены алдарак булып чыкты. Таң алдыннан алар, ике күл арасындагы тар урында, уза алмастай койма булып калкып чыккан чәнечкеле тимер чыбык киртәсенә килеп төртелделәр. Менә шунда гына, калку өстендә...

Күтәрелеп карауга, аякларын җир тоткандай, башларын иеп туктап калдылар: аларның иптәшләре иртә беләнге хәлендә үк тимер чыбык киртәсе өстендә йөзтүбән ята иде. Сул кулы белән, гүя дошман пулясыннан сакланып калырга теләгәндәй, башына ябышкан, куе бөдрәләре тимер чыбык арасыннан аска салынып тора, тимер чыбык өстенә ыргыткан шинеле читкә авышкан...

Митричевның шинелен кизәнеп торып тимер чыбык киртәсе өстенә ыргытуы Шәмсинең дә күзенә чалынып калган иде. Тик ул шинеле өстенә сикереп менүгә, кинәт пулеметтан аттылар. Әйе, теге якка сикереп төшеп, пулеметка граната ыргытыр өчен тагын бер генә сулыш ва-

кыт та җитәсе иде. Бер сулыш, бер генә тын. Ләкин Петруська караганда үлем өлгеррәк булып чыкты...

Тимер чыбык киртәсенә тәмам якынлашып, үле гәүдәне алырга кулларын сузганда, кинәт кенә, бөтен тирәякны биләп алган авыр тынлыкны бозып, дошман ягыннан пулемет ут ачты. Данилов, ачудан ярсып, ниндидер коточкыч тавыш белән:

— Егыл! — дип кычкырды.

Җиргә ауган чагында Шәмсинең сул балтырын нидер үзәгенә үткәреп пешереп алды. Аннан соң ул урын ничектер бераз кызган сыман, осган сыман тоела башлады. Ләкин баш өстендә, тимер чыбыкка тиеп, черт-черт пулялар ярыла, мәетнең суынып каткан гәүдәсен дошманның ерткычларча яңадан тишкәләве җенләрен чыгара, аякны кайгыртыр вакыт түгел иде. Даниловның сүгенгәне ишетелде.

— Кайдан ата ул бандит! Кайда посынган? Бачило, Перебейнос, тончыктырыгыз әле шуны!

Тегеләр бер-берсенә ышыкланып калкурак урынга үрмәләделәр. Данилов коры гына:

— Кайчы! — дип кычкырды.

Аннары алар Шәмси белән, үрмәләп, тимер чыбык киртәсе арасына кереп киттеләр.

Мәетне эләктереп торган тимер чыбыкларны як-яктан кистереп җиргә төшергәч, Шәмси имәнеп китте: яны белән яткыргач Митричев иптәшләрен шаяртыр өчен генә шулай кулын яңагына куеп кырын ятадыр кебек күренә иде. Ләкин чалкан салгач, сул кулы шыксыз булып тырпаеп калды, кашлары да, бу хәлгә бик гаҗәпләнгән сыман: «Нишләп болай булды? Ә, нишләп?!» — дигән сыман, ачулы сорау белән югары күтәрелгән иде.

Пулемет уты астыннан алып чыкканнан соң, бераз арткарак чигенеп, кабер казырга җыена башладылар. Ләкин Шәмси бер Кырым ягына, бер бу якка карангалап торды да туктаган урынны ошатмады. Моннан Кырым ягы күренми иде. Карт сугышчыларны көлдермәгәем дип икеләнә торгач, калкурак урында казырга кирәк, диде. Шуннан соң байтак кына өскә күтәрелделәр.

— Менә моннан Сиваш кына түгел, Кырым ягы да күренер... Кырымны ул да бик күрергә теләгән иде бит.

Иптәшләре кабер казыганда, Саша, бармакларын сәер итеп бөдрәләренә батырган килеш, гаҗәпләнгән

кашларын караңгы күккә текәп, бераз кырыйдарак үзенә соңгы өйне житештергәше көтеп ята торды. Шәмси иптәшләренең үзен шулай кайгыртулары аңа ошарга тиеш дип уйлый иде. Кырым иле һәркайсының да хыялында яшел бакча булып гәүдәләнә иде бит. Соңгы торагын диңгездә искән җылы җилләр сирпелеп китәрдәй биек урында салуларына ул да канәгать булырга тиеш иде.

Ротага кушылып бераз баргач ук, алдагы сугыш кырының утлары-ялкыннары күренә, орудиеләр үкерешүе, пулеметлар тыкылдавы ачыграк ишетелә башлады. Сугыш ерак та түгел, күп булса ике-өч чакрым чамасында гына иде.

Данилов фронт ягына башы белән ымлап:

— Юшунь дигәннәре әнә шул инде,— диде.— Хәзер Врангельнең бөтен көче шунда тупланган.

Алда дүрт-биш чакрым җир, кинәт янгын капкандай, буйдан-буйга яктырып китә дә шундук тагын сүнә, тагын гөрселди башлый, кыр өстендә бер кабынып, бер сүнеп тагын ут кибәннәре биешергә тотына.

Әхмәди башын чайкады:

— Ай-ай!.. Перекоптагыдан хәтәррәк бу. Әллә йөз орудие, әллә мең... Барысы берьюлы. Чын.

Данилов, кырыйда туктап, юлсыз җирдән көч-хәл белән атлап баручы арыган, йончыган сугышчыларын яныннан уздырды. Өч көн йокламаган. Тамакның да күптән туйганы юк. Ул сугышчыларын чын-чыннан кызгана иде. Ләкин аннан ни файда?! Түзәргә кирәк. Юк, түзү генә җитми, бирешмәскә, сугышта җиңеп чыгарга кирәк.

Ялкыннар шәүләсе аеруча көчле балкыганда, кинәт күзенә чалынып калды: Шәмси нигәдер аксый башлаган иде. Данилов җилтерәп аның янына килеп басты.

— Тукта, ни булды сиңа? Егылдыңмы, аягың бозылдымы, әллә ялгыш басып тамыры сузылдымы, ә? Нигә болай аксыйсың?

Шәмси сак кына, йомшак кына итеп аны читкә этәрде:

— Алай да, болай да, тегеләй дә түгел. Бетәр әле.. Ямаулыгы өстендә. Әнә теге якка кара син, минем аякка түгел.

Ул взводныйның шиген юкка чыгарыр өчен йөгереп китмәкче булып талпынды. Ләкин аяк дигәнең җибәрми

икән, балтырның нәкъ урта бер төшен утлы эскәнҗә бик каты авырттырып кысып тоткан иде.

Данилов үзсүзләләнеп аны туктатты, үз янына санитарны дәшеп китерде. Караңгыдан Кызыл Хач билгесе ябыштырган брезент сумкасын асып, лап-лоп басып, берьюлы өч кешене күтәрердәй бер баһадир килеп чыкты. Шәмсинең аягына баса алмыйча егылып китүен күрүгә, гүя үзенә эш чыгуына куанып, болардан сөенче алгандай, кычкырып җибәрде:

— Та це же рана! Хлопче! Ты же ранен!

Данилов моңа бик гаҗәпләнде:

— Яра? Нинди яра? Кайдан килгән яра?

Шәмси, болай килеп чыгуына бик уңайсызланып, обмоткасын сүтә башлады. Әйтерсең, ул юри кылана. Шулай дип уйлаулары мөмкин бит.

— Исегез киткән икән. Чебен тешләп китте... тегендә, бая. Акбаш, нечкә борын.

Даниловның сугыш бетте дигәндә генә шулкадәр кешесенең сафтан чыгуына болай да йөрәге әрни иде. Взводта сугышчылар кими дә кими. Тиздән әнә шул ут эченә барып керәсе. Кем белән сугышырга?.. Әнә бит ничә генә калдылар... Бу малайның яралануын башта ук белдермәве яңадан ачуын кабартып җибәрде. Ул төкеренде, сүгенде, Шәмсине әйләндерә-әйләндерә орышырга тотынды:

— Молокосос! Тапкан кыланыр вакыт! Чыдам, имеш, революция өчен һәммәсен дә тавышсыз гына күтәрә, имеш! Дурак! Аяксыз калсаң, синең кемгә кирәгең бар?

Данилов, тәмам кәефе кырылган хәлдә, Шәмсигә әйләнеп тә карамастан, кызу-кызу атлап взводын куып китте.

Санитар арбасында тагын бер яралы бар икән. Шәмси шуның янына, печәнме, саламмы өстенә менеп ятты. Тик шунда ук яңадан торып утырды. Сугышның иң кызган чагында, сугыш менә бетә, менә туктый дип зарыгып көткәндә, иптәшләреңнән аерылып кал, имеш. Ул кемгәдер чын күңелдән рәнҗеде, кемнедер яман сүзләр белән сүгеп ташлады. Тик ул шундук ничектер акрын-акрын ойый башлады. Әйтерсең, аның бөтен гәүдәсе камыр сыман булып йомшый барды, йомшый барды да, ниһаять, рәхәт кенә сызлатып торган ниндидер татлы бер караңгы эченә иңеп, эреп бетте, бөтенләй югалды...

XII

Ялкынлы, гөрелтеле фронт сызыгы һаман якыная барды. Хәзер инде орудиеләрдән залп биргәндә, Данилов шәүлә яктысында сугышчыларының кызгылт йөзләрен, очкын кабынгандай елтырап киткән күзләрен дә күрә иде. Унда да, сулда да — ашыгып алга баручы роталар, батальоннар. Алар өстендә, кечкенә йолдызлар булып, бик күп штык очлары кабынып китте, кызгылт нур бөркелгән бик күп соры шәүләләр күренеп калды.

Рота командиры Пахомов, тырпаеп калган көнбагыш сабакларына абына-сөртенә, сугышчылар белән янәшә атлый, алда чакрымга сузылган ялкын урманы күтәрелгән саен дәртләнеп әйтеп куя:

— Шәп, егетләр, шәп! Менә болары безнеке инде. Утка бастыралар! Болай булса, без кергәнче тимер чыбык заграждениеләренең көле күккә очачак.

Ниһаять, бу тирәдәге бик күп тозлы күлләрнең берсе буена килеп төштеләр. Яр астындагы тар сукмактан йөгерә-атлый узганнан соң, ниндидер чокырлар, үзәннәр кичеп, сугыш кырының нәкъ артына килеп чыктылар. Ундарак, кызыл ут шәүләсендә канатларын тырпайтып, җил тегермәне басып тора, аның янында ниндидер кодрәт белән янмый да, җимерелми дә калган берничә каралты кызарып күренде. Болар килеп җитүгә, берәр генә кешелек сай окоплардан сугышчылар күтәрелә башлады.

— Кайсы полк?

Даниловка тез башларын, шинель итәкләрен каккалап торучы калын кара кашлы, базык гәүдәле башкорт егете җавап бирде:

— Йөз дә утыз өченче.

— Кара, иң якын күршебез икәнсез бит. Хәерле юл сезгә, туганнар. Сугыштан исән чыгарга булсын!

— Шулай булсын... — Башкорт егете сугыш гөрелтесенә колак салды да башын кагып куйды:— Әйе, шулай булсын. Тик мин уйлыйм, сезгә дә кизү тиз җитәр. Сугыш тегермәне әнә ничек шәп тарта!..

Күрше полкның сугышчылары, әледән-әле кабынып торган куе кызыл ут шәүләсе астында поса төшеп, винтовкаларын әзер тоткан хәлдә алгы сызыкка киттеләр.

Данилов, сугышчыларын окопларга урнаштырып бетергәннән соң, Әхмәди янына килеп утырды.

— Я, нихәл, картлач?

Вәлитов, окопка сузылып яткан җиреннән, башын күтәрер-күтәрмәс, тамак кырып алды:

— Менә дигән, егетләрчә... Тиз керербезме, синеңчә?

Данилов бераз дәшмичә торганнан соң гына җавап бирде:

— Каян беләсең? Бәлки хәзер үк, бәлки ярты сәгатьтән. Күршеләр әле генә китте бит әле. Заграждениене үтә алырлармы, юкмы...

— ... Алар артыннан ук безме?

Данилов башын чайкап телен чартлатып куйды:

— Безен без дә...

— Соң... Шуннан?..

— Күрәсең бит, егетләр бик арыды, ничек беразга гына йоклатмыйча түздерергә? Изеләләр дә төшәләр... Син карт солдат бит, әйт әле, шундый чакларда нишләргә?

Вәлитовның җавап бирмәвенә гаҗәпсенеп иелебрәк караса, картлач шул арада үзе дә йоклап киткән. Данилов аны шинель якасыннан тартып, уены-чыны белән селкеткәли башлады:

— Әй син, мактанчык! Бу ни хәл бу? Ичмаса син генә йоклама!..

Вәлитов башта күзләрен ача алмыйча азапланды, аннары бик арыган, тәмам изелгән кыяфәт белән торып окоп кырыена утырды. Гаепле кеше сыман елмайды да кинәт йодрыклары белән әле янтауларын, әле күкрәген, әле ботларын дөмбәсләргә тотынды:

— Менә сиңа, менә, менә! Йоклама командир алдында, арыш камырыдай изелеп төшмә, җебемә!

Данилов рәхәтләнеп бер көлде дә сугышчыларын уята-уята окоп буйлап китте. Ләкин ул борылып килгәндә, алар янадан йокыга китеп өлгергәннәр иде инде. Ул арада алгы сызыкта гөрселдәүләр кинәт тынып калды, шундук бөтен фронт буйлап «ура» кычкырган тавышлар ишетелде. Күршеләр атакага кузгалды. Ни булыр? Кырып бетермәсләрме?.. Нишләргә? Ничек уяу тотарга?

— Беләсеңме, командир,— диде ана Әхмәди,— вакыт кына җитсен, сәгать кенә суксын, солдатларың ут булыр, давыл булыр!..

— Күреп карыйк.

Уңнан һәрвакыттагыча эре адымнар белән, әмма кызу атлап рота командиры Пахомов килеп чыкты. Аның

артыннан ук Исмаев та күренде. Аларны да шул ук хәл борчый иде булса кирәк.

Рота командиры Даниловка:

— Взводыңны монда җый,— диде. Ә сез, кем...

Үзенең янында басып торган политрукны моңарчы һаман «сез» дип кенә дәшеп нигәдер читләтеп килүе хәзер аңа гаделсезлек булып тоела башлады. Дөресен генә әйткәндә, бу терс, тынгысыз егет җанын бирердәй булып чын күңелдән тырышып йөри бит. Командир, ничектер үзе дә сизмәстән, йомшак кына итеп Исмаевның иңбашына кагылып куйды. Беренче мәртәбә аңа, бу татар малаеннан бик күп өстен торучы командир булып түгел, үзе белән тиңләп ягымлы тавыш белән дәште:

— ...Син, туганкай, монда кал, мин икенче взводка киттем.

Политрук, кара күзләрен зур ачып, командир күренмәс булганчы карап торды. Аннары елмаеп Даниловның шинель җиңен тартты:

— Гриша, җанкисәгем, беләсеңме, мин бит бүген өченче революциядә катнашам!

— Нинди өченче тагын ул? Әле элеккесен ныгытып җиткермәгән.

— Аполлинарий Петровичның күңелендә чын-чыннан революция булды. Ул хәзер безнең кеше! Бөтенләе белән!

— Ә элек акларныкы идемени?

— Юк, түгел иде. Шулай да ул бит алпавыт нәселеннән, патша офицеры. Аңа революцияне бөтен җаны-тәне белән үзенеке итеп, үз эше итеп аңлау җиңел иде дип беләсеңмени? Менә хәзер аның йөрәге безнеңчә тибә башлады. Әйе, безнеңчә диярлек. Революция түгелмени бу? Нинди генә әле!

— Беләсеңме нигә шулай ул?

— Азрак төшенә торганмын дип уйлыйм. Сугыш дәвалады аны. Халык белән кулга кул тотынып шушындый дәһшәтле җәһәннәм утларын кичкәндә, минемчә, кешедәге әшәке сыйфатлар янып, көеп юкка чыга, кешенең рухы, җыен әшәкедән арынып, сафланып кала.

— Нәкъ минемчә уйлыйсың икән...— Данилов политрукны Әхмәди тирәсенә җыйналган сугышчылар янына әйдәде.— Отделениеләп җыярлык чама калмады, секреттагыдан башкалары һәммәсе дә шушында... Я, менә шунда барысы бергә йоклап китсәләр, нишләрсең?..

— Йоклатмаска тырышырмын...

Исмаев җиңел генә атлап Әхмәди окобының кырыена килеп утырды. Аның тирәсенә, түгәрәк ясап, башка сугышчылар җыелган иде. Аларның байтагысы яраланган. Берсе кулын иңенә аскан. Икенче берсенең марля арасыннан борыны белән күзләре генә күренеп тора. Һәммәсенең кулында винтовка. Кайсы аны кочаклап утырган, кайберсе янына сөяп куйган. Билләрендә гранаталар, көрәкләр, патронташлар. Исмаев аларның һәммәсен дә бик якыннан белә иде. Сугыш ялкыны менә шулай әледән-әле йөзләренә кызыл шәүләсен сирпеп торганда, туган минут саен утка ташланырга хәзерләнеп торган чакларында Исмаевка алар бигрәк тә якын иделәр. Ул аларның һәрбер сүзендә, бөтен торышларында эчке бер ныклык, кычкырып тормый торган батырлык сизә иде.

Кинәт көчәеп киткән атыш тавышына Исмаев борылып карады. Нәрсә бу? Күршеләр әле генә атакага күтәрелгән иде бит! Кырып ташлыйлармы икәнни?.. Исмаев торып басты, тик шунда ук кире утырды.

— Менә, дуслар,— диде,— сез миннән элегрәк сугыш кайчан бетә дип сорый торган идегез. Әйтимме хәзер? — Исмаев кулы белән сугыш барган якны күрсәтте.— Әнә актык сугыш шушы инде. Без сезнең белән, Врангельне куа-куа, Таврия далаларын үттек, Сиваш сазын ерып чыктык. Врангель хәзер, арт аягына таяк эләккән биләмче эт шикелле, ырылдый-ырылдый менә шушы соңгы өненә кереп качты. Кай төш соң бу? Юшунь була инде бу, Карпова Балка дигән җир. Әгәр Перекоп Кырымның тышкы капкасы булса, монысы эчкесе. Әмма ныклыгы ягыннан Перекоптан һич кайтыш түгел. Дошманның гаскәре дә, коралы да бик күп. Безнекеләр Перекопны алгач, Врангель бөтен армиясен менә шушында күчергән.

Окоплар буйлап берсе артыннан берсен ике пулемет тартып уздылар. Исмаев полк комиссары әйткәннәрне исенә төшерде. Бу полк каршында торган Дроздов дивизиясе безнең һәр тупка каршы унике туптан атачак. Аларның дивизиясендә аз дигәндә йөз илле пулемет бар икән, әле артык булмаса. Бездә исә ротага бер генә пулемет туры килә... Ләкин политрук шуларны әйтергә дип авызын ачкач, теле бөтенләй башкача сөйләп китте:

— Безнең алда катлы-катлы чәнечкеле тимер чыбык киртәсе булыр. Безгә аларны кисеп, җимереп үтәргә

кирәк. Безгә каршы Россияне буржуйларга саткан, большевикларга каршы сугышып үләргә ант иткән иң явыз контрлар штык белән ташланыр. Безгә аларны да сытып узарга кирәк. Бүгенге көндә Советлар иле бездән шуны көтә. Ленин да, сугыштан йончыган, туйган халык та безнең җиңүебезне көтә. Менә шулай, туганнар!

Бите марляга чорналган Перебейнос, гүя иптәшләре өчен җавап бирүне дә үз өстенә алгандай, як-ягында утырган иптәшләренә карангалап алды:

— Нәрсә сөйләп торырга? Без хәзер! Башлансын гына. Без аларны, ул к...ләрне...— Ул, кызып китеп, әчкелтем-тозлы сүзләр тезеп китте.

Аңа кушылып Әхмәди дә бер-ике сүз әйтеп куйды:

— Әйе, анысы бездән эш калмас. Актык сугыш та булгач... Тик патрон гына җитсен.

Кырыйдарак утырган Бачилоның да әйтер сүзе бар икән:

— Аннары, иптәш политрук, яралылар, нервыга тиеп, янында акырып ятмасын иде. Штобы үз вакытында җыйсыннар!..

Исмаев җавап бирмәкче иде, кинәт якын гына снаряд ярылды. Сугышчылар егылган урыннарыннан торып та өлгермәделәр, икенчесе килеп төште. Гөрселдәү эченнән Исмаевның командасы ишетелде:

— Тарал! Тиз!

Төрле якка сибелешеп кайсы окопка посты, кайсы, чокырга сыенып, тынпарын да алмыйча өченчесе килеп төшкәнне көтә башладылар. Тик ату юнәлеше үзгәрде дә, алар яңадан башларын калкыттылар.

Исмаев, үзенең янында гына тамак кырганны ишетеп, борылып карады. Вәлитов икән. Нидер әйтәсе бар кебек...

— Нихәл, Әхмәди абзый? Малаеңнан хат-хәбәр килмәдеме әле?

Вәлитов, күңелләләнеп бер кеткелдәп куйды:

— Бәй, онытмагансың икән әле. Тольке хәзер алар турында түгел. Минем сиңа икенче бер йомыш бар әле. Йомыш дисәң дә ярый, киңәш дисәң дә...

— Ә, шулаймы? Я, я, тыңлыйм.

— Бер уем бар минем. Аны хәзер әйтергә кирәк. Вакыты шундый... Юкса, соңга калуы бар...

Ул, сүзеннән туктап, ничек итеп әйтергә белмичәрәк, аптырап калды. Торып окоп кырыена утырды. Бармагы

белән мыегының чылгыена кагылып куйды, ләкин, аннан да берни дә чыкмаганга күрә, кулын селтәде.

— Ничек әйтергә соң? Менә мин үзем гидай батрак, беләсез инде. Батрак улы батрак, потомственный, әллә кем әйтмешли. Әйтәсем килгәне шул: элек безне татар дип адәм актыгына санап йөрттеләр. Иптәш Ленин безгә хөррият алып, уңны-сулны күрсәтеп бирде. Автономияле республика бит без хәзер. Менә ничек! Аннан, авыл Советын ал. Әлеге теге, хатта язганны әйтәм. Ничек җаның эремәс? Кемнең күргәне бар ул хәлне, әйтик иске режим вакытында? Чын!.. Без менә хәзер сугышка керәбез, актык сугышка дисең бит. Бик каты буласы дисең. Менә шунда, мин әйтәм... алдагын кем белә, тагын бер сәгатьтән әллә кайсыбыз бар, әллә кайсыбыз юк. Кыланып әйтүем түгел, кирәк булса, өч тапкыр үләргә дә риза! Чын... Эш анда түгел. Менә минем беләсем килә, син партия кешесе, әйт син миңа: мин коммунист булырга ярыйммы, юкмы? Ярыйм икән, сез мине бүген үк партиягә алыгыз. Сугышка коммунист булып керим. Үлсәм — коммунист булып үлим. Исән калам икән, коммунистлыгымның беренче көне шундый сугышта башлансын. Менә шул!..

Вәлитов ашыга-ашыга тәмәке төрергә тотынды.

Исмаев башка вакытта сүзгә оста булган бу кешенең пилектән шулай каушап сөйләвен, аның бу минутта нинди якты уйлар белән рухланып дулкынлануын бөтен күңеле белән сизде.

— Ярый, Әхмәди, абзый,— диде,— синең үтенечеңне ячейканың беренче җыелышында ук карарбыз. Тәгаен! Ә син бүгеннән, менә хәзердән үк үзеңне коммунист дип исәплә! Мә! Исәнлек телим сиңа!

Ул каты итеп Вәлитовның кулын кысты.

Бу нинди тынлык? Йокымы бу, әллә өнме икән? Өн булса, ничек тәнгә шулкадәр рәхәт, ничек бөтен гәүдә, куллар-аяклар шулай җылы сөттә коенгандай рәхәт кенә изриләр икән? Әллә югыйсә...

Шәмси шомланып һәм гаҗәпләнеп күзен ачты. Юк, ул үлмәгән икән, исән, исән! Әйе, кичә аягы яраланган иде бит. Ләкин балтырның ул төше хәзер әйтерлек авыртмый, бераз кыздырып кына торган сыман. Санитар арбасы нииндидер бер каралты ышыгына туктаган. Ул арбада ничектер бу хәзер берүзе генә икән. Аста салам, якында

гына ат кушэгэн тавыш та ишетелгэн кебек. Әйтерсең, Шәмси үз авылында лапас астындагы арбада ята. Җылы, йомшак, ягымлы һава, песи баласыдай, иркәләнеп биткә-кулга сыйпалып уза. Нигә шулкадәр җылы икән? Ул да түгел, Шәмсинең йолдызларга күзе төште. Алар шундый эреләр, аларның як-ягыннан шундый якты нур җепләре сузылган. Шәмсинең мондый зәңгәр күкне, андый йодрык хәтле йолдызларны бер җирдә дә күргәне юк иде әле. Ул, күтәрелә төшеп, як-ягына карады. Бер читтән таң атып килә иде. Офык буеннан киң булып сузылган алсу нурлар астында, киртләч-киртләч булып, тау өстендәге гөлбакчалар төсле яшькелт нурлар балкый. Шәмси куанычыннан хәтта торып утырды. Кырым бит инде бу! Кырым үзе! Мин нилектән болай җылы икән, менә нигә йолдызлары эре, күге зәңгәр икән!

Аннары берсе артыннан берсе төрле күңелле уйлар куандырып узды. Күз алдына оялчан гына елмайган сөрмәле күзе — Нәсимәсе килеп басты, авылының су буе, чишмә тамагы... Кырым алынгач та сугыш бетә бит!..

Сугыш... Тукта, нигә атыш тавышлары ишетелми соң әле? Нигә бөтен дөнья тын? Әллә чыннан да сугыш беттеме?

Сулдан таң яктысында әкиятләрдәге пәһлевандай зур булып кичәге санитар калкып чыкты. Озын-озын атлап килде дә мичкәдән чыккандай калын тавышы белән кемгәдер әйтте:

— Кузгал, тиз бул!

Шәмси, гүя тоташтан бер атна йоклап барлык вакыйгаларның очын югалткандай, берни дә аңламый иде әле.

— Ничек болай? Нишләп бик тын?

Ул арада пәһлеван каядыр алга таба йөгерде, ат башында йөрүче, дилбегәсен болгый-болгый, атны кирегә чаптыра башлады. Шәмси аның җиңеннән тартты.

— Кая чабасың, роталар кайда?

— Кайда-кайда... Менә хәзер күрсәтер кайдалыгын!..

Ат йөртүче сүзен дә әйтеп бетерергә өлгермәде, сызгырып, чыелдап килгән снаряд әле генә алар ышыкланып торган каралтыны туздырып та ыргытты.

— Анладыңмы инде?

Ат йөртүче чөңгереп еш-еш дилбегәсен тарта, ялт итеп артына борылып карый да сикереп торып дилбегә белән атының сыртын ярырга тотына иде.

Юлга чыккач, Шәмси тагын да ныграк борчыла башлады. Гүя нәрсәгәдер өлгерергә, кайдадыр тизрәк барып җитәргә теләгәндәй ашыгып, берсен берсе куып алга таба бик күп тачанкалар, патрон төягән, пулеметлар салган арбалар уза, ординарецлар чаба, йөгерә-атлый җәяүле сугышчылар үтеп китә. Шәмси сикереп төшмәкче булып арбаның кырыена ябыша да тагын тыелып кала, омтыла да икеләнеп тагын агымга каршы баруында дәвам итә иде.

Әйләнгәләп караганчы ниндидер бер авылга килеп керделәр. Авылның урамнары, ындыр артлары, авыл янындагы күл буйлары — бөтен җир атлылар белән тулган. Төрле төстәге атлар, озын кара буркалар бөркәнгән сугышчылар...

Ат тотучы, як-яктагы тәгәрмәч тавышларын басырырлык итеп, Шәмсигә кычкырды:

— Күрдеңә Буденный армиясе бу! Җәяүлеләр заграждениене генә өзсеннәр, аннары болар ташлана. Өермә болар, ташкын!

Ул да түгел, кинәт, баш өстеннән бер снаряд сызгырып үтте. Аның артыннан тагын бер, аннары тагы...

— Безнекеләр! Без башладык! Ура!

Алга таба узып баручы сугышчылар, шатлыклы хәбәрдән сөенче алгандай, гүя боларның артыннан, күл буеннан атып торучы артиллеристларга куәт биргәндәй, бер-берсенә дәшеп, куанычларын уртаклашалар иде.

— Бир кирәген, җимер, туздырт!

— Безгә юл арчыйлар!

— Әнә нинди өермә купты!

Артиллерия канонадасы минут саен кыза барды. Аклар артиллериясе дә җавап бирә башлаганнан соң, якын-тирәне тоташ гөрелтеләр, снарядларның сызгыру тавышлары басты. Юлда хәрәкәт аның саен көчәйде. Хәзер инде тачанкалар, җәяүлеләр сугыш барган якка тоташ агым булып агылалар. Бу дәртле, көчле ташкын Шәмсине дә үзенә тарта иде.

Шәмси шулай икеләнеп, пошынып һәм борчылып барды-барды да, ниһаять, түзмәде, ат тотучының колагы төбенә кычкырды:

— Туктат!

— Нәрсә син? Кая болай?

— Иптәшләр янына!

— Сыңар аяк беләнме? Юләр син! Аксак тиле!

— Юк, минем аяк төзәлде инде.

Арбадан төшеп басуга Шәмси, сул аягының балтырына энә кадалгандай, сыны катып сүзсез калды. Шулай да яшьлек горурлыгының ансат кына бирешәсе килми иде.

— Әйтәм бит...— диде.

Ат тотучы икенче борылып караганда, ул инде, патрон әрҗәләре төялгән яшел арбага утырып, алгы сызыкка таба чаба иде.

XIII

Аклар окобы бөтен буе белән утлы өермә астында калды. Аннанургылып-ургылып ялкын, кара сөрем күтәрелә иде.

Ул арада кузгалырга команда булды. Полк, окопларны сулда калдырып, иңкел урыннардан поса-поса узып, ундагы кечкенә хутор артына килеп чыкты.

Хуторны кичәге сугышта ук ваттырып бетерә язганнар иде. Андагы бердәнбер өйнең түбәсен снаряд алып ыргыткан, каралтылар җимерелгән. Ниндидер могҗиза белән бары җил тегермәне генә исән калган иде.

Ике яктан да көчәя барган атыш астында полк, дошманга йөзе белән борылып, озын бер сафка тезелде. Командирлар сугышчыларның хәзерлекләрен тикшерә башладылар. Барысының да патроннары бармы, штыклары төшеп калмаганмы?.. Полк комиссары, политрукларны артка җыеп, иң соңгы киңәшләрен әйтте; ике тәгәрмәчле патрон арбалары, янгында су ташучылар шикелле, ашыгып-ашыгып, арттан өзлексез патрон ташып тордылар; носилкаларын күтәреп, санитарлар килеп чыкты. Бу ашыгу, хәзерлек ыгы-зыгысы эчендә, бары сафка тезелгән кызылармеецлар гына тыныч кебек күренәләр иде.

Командир Пахомов ротаның каршысына чыгып басты, бераз карлыккан тавыш белән:

— Мин сафтан чыксам, ротаның командиры политрук Исмаев булыр! — диде.

Исмаев көтелмәгән бу хәлдән бераз каушабрак калды. Аның күзләре челт-челт килә, ул, ни әйтергә белмәгәнлектән, тырпаеп торган кара чәчен буденка бүреге астына кыстырып маташа иде.

— Аполлинарий Петрович! Мин бит...

Пахомов аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

— Политрук Исмаев!— диде.— Стройда мин Аполлинарий Петрович түгел, ә иптәш командир! Бу — бер,

Икенчедән, командирның сүзе — приказ. Бигрәк тә хәзер, менә шундый вакытта!

Исмаев берьюлы юашланып калды, төз басып уң кулын бүреге янына китереп алды:

— Тыңлыйм, иптәш командир!

Пахомов, рота каршысында озын-озын атлап йөргән килеш, взвод командирларының һәркайсына урынбасарлар билгеләргә кушты. Уйланып бер әйләнде дә тагын өстәп куйды:

— Отделение командирларына да!

Командир артиллерия тавышына колак салды. Болай тыңлауга канонада көчле кебек ишетелә иде. Ләкин Пахомов акларның бетонланган ныгытмаларын җимертү, җәяүлегә юлны арчып җиткерү өчен мондый кечкенә калибрлы пушкалардан ату гына җитмәвен алдан ук сизеп тора, шуңа борчыла иде. Ул тезмә буйлап күз йөртте. Полк та бик кечерәйгән, хәзер ул зуррак батальон кадәр генә калган иде.

Ул, күңеленә үрмәли башлаган борчуга тамыр җәяргә ирек бирәсе килмичә, сугышчыларына сыныйрак карый башлады. Үрнең аръягындагы сугышның дөнья җимертеп, җир тетрәтеп үкерүе аларны дулкынландыра, борчый. Әмма алар бер-берсенә сүз кушкан булалар, баскан урыннарында сикергәлиләр, кулларын угалыйлар, борчылу һәм куркуларын бер-берсеннән яшерергә тырышалар иде. Пахомовка болар һәммәсе дә әллә кайчан ук таныш. Әмма хәзер аның үзенең дә сугышчыларга бик якын да, ягымлы да буласы килде.

— Я, менә озакламыйча кузгалабыз...— диде, әмма рота алдыннан берничә мәртәбә әйләнеп узса да, теле ачылып китмәде, тел очына гына җыелып торган ягымлы сүзләрен әйтеп бирә алмады.

Ихтимал, командирның үзеннән генә бүтән берни дә чыкмаячагын сизенде булса кирәк, Исмаев килеп кушылды:

— Кузгалуын кузгалабыз да, иптәш командир, тик белеп торырга кирәк: безнең егетләргә бит офицерларга каршы сугышырга туры киләчәк. Шулай түгелме? Аларның бит рота командирлары полковник та майор, ә солдат урынына капитаннар, поручиклар, фәләннәр дип әйтәләр.

— Анысы шулай. Алар усал сугышыр. Тик мин уйлыйм: погондамыни хикмәт?! Туган иленә, Россиягә каршы корал күтәргән кешегә офицер исеме әрәм! Ул

яктагы һәртөрле сатлык майордан, полковниктан син мең кат өстенрәк торасың!.. Чөнки...

Пахомов сүзен әйтеп бетерә алмады, артиллерия канонадасы кисәк кенә туктауга, уң канаттан команда тавышы ишетелде:

— Алга!

Полк кузгалды. Ул, тоташ тезмә булып, хутор белән аклар арасындагы үр өстенә күтәрелә башлады.

Ул арада инде яктырып та җитте; ихтимал, аклар полкның кузгалуын күргәннәрдер дә.

Шулай да әле фронт өстендә тын иде. Бары меңнәрчә аякларның дөпелдәве, тартып барган пулеметларның чылтыравы гына ишетелеп торды.

— Кызурак!

Рота командиры бара торган көйгә кобурасыннан маузерын чыгарды.

Бөтен полкның штыклары алга таба юнәлгән. Һәммәсенең күзләре аклар ягына, аларның үр өстендә калкып торган окопларына текәлгән. Аяклар үзләреннән-үзләре җилкенеп атлыйлар кебек. Гәүдәләрдә ниндидер бер сәер җиңеллек, күңелләрдә ниндидер бер ашкынулы дәрт. Менә шушылай тезелгән килеш, көчле ташкындай, юлда очраган һәммә нәрсәне җимереп, сытып, гел барасы, гел барасы гына иде!.. Уңда да шундый ук озын бер тезмәнең атакага баруы күренде.

Менә ике арадагы сыртны узып, үзәнгә төшә башладылар. Уң яктан, рота саен кабатланып, тагын бер команда килде:

— Тизрәк!

Тезмә тагын да кызулый төште. Өченче взводлардагы кечерәк гәүдәлеләр йөгерә үк башладылар.

Алдагы калку өстендә акларның күз күреме җиргә сузылган окоплары, алар алдында берничә рәт булып тезелгән тимер чыбыкның казыкларына хәтле күренә башлады.

Инде аклар окобына ерак та калмады. Тагын берике йөз адым гына барасы...

Хәзер инде аклар бөтен кырны иңләтеп һөҗүмгә баручы полкларның һәр солдатына кадәр күреп торалар, шулай да һаман атмыйлар иде әле.

«Нигә атмыйлар икән?» Бу авыр тынлык, шикләндерә, ачуны чыгарып ярсыта торган хәтәр тынлык, пулемет уты астында калудан да, өстә шрапнель ярылудан да куркынычрак, гадәтләнелмәгән шомлы тынлык иде.

Менә йөгерергә команда булды.

Еракка сузылган тезмә бөтен стенасы белән, озын бер дулкын булып, штыкларын алга төбәгән килеш йөгерә башлады.

«Нигә ата башламыйлар икән, нигә?..»

Менә инде якын гына калды. Йөз, сиксән адым... житмеш...

Барлык командирлар, наганнарын айкап, тезмәнең алдына чыктылар. Полк командирымы, комиссармы, кайсыдыр кычкырып жибәрде:

— Иптәшләр, революция өчен, ура!

Сугыш кырын буйдан буйга «ура» тавышы яңгыратты. Шул секундта ук тезмә өстенә берьюлы кинәт йөзләрчә пулеметның котырынган утлы ташкыны килеп бәрелде. Пуляларның зәһәрләнеп чи-чи килүләре, бергә кушылып, тоташ бер чыелдауга әйләнде. Ул күзне ачырмаслык итеп, битләргә тузан, туфрак, балчык кисәкләре сиптерде. Пуля ташкыны тыннарны кисә, бугазга тыгыла кебек тоела иде. Бер генә адым атлау да исәпсез корбаннар сорый башлады, әллә нихәтле сугышчы егылып калды.

— Ложись!

Хәзер инде кантарларга ябыша-ябыша мүкәләп үрмәли башладылар. Пулеметлар баш калкытырга да ирек бирмичә һаман кыралар, әле анда, әле монда яралылар, үлгәннәр сузылып кала, минут саен тезмә сирәкләнә бара иде.

Пахомов ачынып һәм ярсып тезмәгә күз салды. Болай булса, тагын берничә минуттан бөтен полкның кырылып бетүе мөмкин иде. Карт солдат шундук катгый карарга килде: кинәт кенә сикереш ясап тимер чыбык киртәсенә барып ышыкланырга! Ул җәһәт кенә сикереп торды да кычкырып җибәрде:

— Рота, минем арттан!

Исән калган сугышчылар бердәй алга ташланды. Тагын колак төбендә пуля бураны уйный, сызгыра, тагын кешеләр егылып кала башлады.

Пахомов, бөкрәя төшеп йөгергән уңайга, сугышчыларын әйдәп, әле бер якка, әле икенче якка карап кулын болгый. Тимер чыбык челтәренә якынайган саен аның күңеле күтәрелә, аның саен өмете зурая бара иде. Менә тагын егерме генә адым, ун гына... Аннары — кайчы, гранаталар, штык...

Ләкин командир, ике-өч кенә адым атлагач ук, башын нидер кыздырып узган кебек сизде. Аннан соң гәүдәсенең тотрыксызланып авып төшүен, җиргә килеп бәрелүен тойды. Кинәт кенә төпсез, йомшак караңгылыкка чумган кебек булды...

Хәзер инде һәммәсе дә ачык күрделәр: артиллерия өч катлы тимер чыбык челтәрен җимертеп бетерә алмаган булып чыкты. Шулкадәр күп кыенлыклар белән монда кадәр килеп җиткәч, шулкадәр җан кыелгач та кире чигенү йөрәкне әрнетә, җанны кыйный иде.

Шулай да команда чигенергә кушты.

Шәмсигә кайсыдыр фамилиясе белән кычкырды. Дәшүче әлеге пәһлевандай зур гәүдәле санитар икән.

Ул, түземсезләнеп:

— Тот тизрәк! — диде.

Носилкада рота командирының үле гәүдәсе ята иде. Аның маңгаена кечкенә генә кара тимгел чыккан, күзләрен йомар-йоммас тыныч кына йоклаган кебек күренә. Носилканы күтәреп пулемет уты астында бөгелә-сыгыла бик озак йөгергәннән соң, хуторга җитәрәк туктадылар. Пәһлеван носилка янына тезләнеп папахасын салды.

— Нинди әйбәт кеше иде...

Аның яңаклары буйлап күз яшьләре тәгәрәде. Ул, аклар ягына йодрыгын күрсәтеп:

— Барыбер бетәсез бит,— дип үкереп куйды.— Оягызны тузгытабыз, паразитлар! Качып кына котыла алмассыз!

Аннары, авырттырмаска тырышкан сыман, саклык белән генә командирның күзләрен йомдырды.

Даниловны ротаның яңа командиры Исмаев үзенә ярдәмгә чакырганлыктан, ул взводны Вәлитовка калдырып киткән иде.

Чигенеп, үр кырысна туктаганнан соң, Вәлитов взводның сугышчыларын барлап чыкты. Өчәү үлгән, ике сугышчы яраланган иде.

Кичә политрук белән сөйләшкәннән соң Вәлитов үзен чыннан да коммунист итеп хис кылырга тырышты. Ләкин нинди булырга тиеш соң ул коммунист? Ул моны әле ачык кына итеп үзе дә белми иде. Әмма күңеленең әллә кай төше аңа коммунист кеше дөньяда иң яхшы, иң гадел, иң батыр кеше булырга тиеш, кулыннан нинди яхшылык килә, шуларның һәммәсен дә эшләргә тиеш

дип искәртеп тора иде. Аннары коммунист булу кешене ничектер ныгыта, иптәшләрең каршында да, туган илең алдында да җаваплылыгыңны арттыра кебек сизелә башлады. Шундый каты сугышта командир булу, шуның өстенә коммунист командир булуның үзенә күрә бер күңелне күтәреп, дәртләндерен җибәрә торган ягы да бар икән. Вәлитов, шинель итәген бил каешына кыстырып, сугышчыларының әле берсе, әле икенчесе янына үрмәләде. Ул аларга патрон әләвитте, кая атарга, ничек атарга икәнен өйрәтеп йөрде. Аларның артындагы хутор өстендә өзлексез туп ядрәләре ярыла, яңадан атакага кузгалмасыннар өчен дошман баш калкытырга да ирек бирми, өзлексез пулеметлардан сиптереп тора. Шау-гөр, сөрем... Әмма Вәлитов шунда да үзен тыныч тотарга тырышты, вакыты белән шаяртып алгалады.

— Аһ-һа, һа! Ничек, егетләр, эссеме? Моңарчы әле аның уены гына булган икән, менә кайчан башлана аның дуены! — Ул арада кайсыныңдыр төзәмичә генә ашыкпошык күккә атып җибәрүен күреп аны орышып алды:— Нәрсә син һавадагы торнага атып ятасың? Төзәп ат! Прицел! — Аннары аклар ягына ымлап:— Тыпырчыналар! — дип әйтеп куйды.— Актык сулышлары, аякларын селкиләр. Тагын беразга чыдасак — була! Бетә сугыш, егетләр, бетә. Нык тор, бирешмә!

Ике якның да артиллерия уты көчәйгәннән-көчәя генә бара иде. Аклар артиллериясе полкның команда пункты һәм элемтәчеләре-фәләннәре ышыкланырлык бердәнбер урын булган хутор калдыгына каныкты. Җимерек каралтылар берсе артыннан берсе икенче тапкыр җимерелә һәм яна башладылар. Хутор өстеннән куе ялкын күтәрелде. Җил тегермәненә снаряд тиде. Сынык канатлар, җил өргәндәй, ничектер үзләреннән-үзләре әйләнә башладылар.

— Оһо, тарта тегермән!

Вәлитов сүзен әйтеп бетерүгә, икенче снаряд тегермәннең түбәсен үк каерып ташлады. Аны ут чорнап алды.

Полкның команда пункты артиллерия уты астында калды. Шул котырынган өермә эчендә нинди әмәлләр беләндер үзен дә, аппаратын да саклап кала алган телефонист, өй калдыгын чолгап алган ялкын эченнән йөгереп чыгып, таш сарай буена килеп урнашты. Аның янына рота командиры урынына калган Исмаев йөгереп килде.

— Комиссар кирәк, я командир! Кайда алар?

Телефонист, җавап бирмәстән, чүгәләгән җиреннән бераз читкәрәк күчеп утырды. Аның артындагы койма ышыгында кулларын як-якка җәеп, сузылып яткан үле гәүдә күренде. Исмаев ни әйтергә белмичә аптырап калды. Шул вакыт, янып ята торган тегермән калдыгына ышыкланып йөгерә-йөгерә, беренче батальон командиры килеп чыкты. Телефонист башы белән аңа ымлады.

— Командир яраланды. Әнә янәсы!

Командирның сул кулы иңенә асылган, бите канаган иде. Ул яулыгы белән битен сөртә-сөртә сарай стенасына килеп сөялде.

— Икенче батальонның командиры үлде. Җәяүле разведканың яртысы кырылып бетте... Югалту зур. Һич аңламыйм, нигә шулкадәр озакка сузарга? Бригаданы ал! Тиз!

Ул, телефонның эшләмәвен белеп алды булса кирәк, ачу белән кулын селтәде:

— Ташла трубканы! Үзең йөгер!

Исмаев командирның янына ук барып колагына кычкырды:

— Иптәш командир, патрон бетте!..

Исмаев үтенечен әйтеп тә бетерергә өлгермәде, снаряд алар ышыкланып торган стенаның почмагын умырып ыргытты. Алар төтен, тузан эчендә калдылар. Аның артыннан янәшә генә тагын берсе килеп төште. Командир, өстен каккалап, аягына басты, тегермән артында аты һәм олаучысы үлеп кырынаеп яткан патрон арбасын күрсәтте:

— Әнә патрон, әнә! Бар, йөгер, нишләп монда син?!.

Исмаев берничә сугышчы белән ротасына патрон китергәндә, аклар ягыннан җитез генә бер машина килеп чыкты.

— Броневик! Броневик! — дип кычкырдылар.

Зур гына яшел машина, каршысына пулеметлардан һәм винтовкалардан атуга һич исе китмичә, бик тиз якынлаша башлады. Кырык-илле адым калгач, кинәт сулга борылып, пулеметлардан ата-ата тезмә алдыннан чабып китте.

— Их, астына граната җибәрергә! — диде берсе.

Исмаев унга узышлый ике сугышчының тезмәдән аерылып, ашыга-ашыга броневикка таба шуышуларын күреп калды. Бу икенең берсе Вәлитов иде. Аклар окобыннан боларны күреп, пулемет уты ачтылар.

Алар тирәсендә күз ачырмаслык пуля бураны купты. Әмма бернигә карамастан, әрем төпләренә ябыша-ябыша, әле чокыррак урыннан, әле ызаннан алар түшләре белән алга шуыштылар.

Бераздан аларның берсе, үрмәли торгач, чокыр эчендә ятып калды.

Шәмси ачынып, нишләргә белмичә, кычкырып җибәрде:

— Әхмәди абый!

Ул да түгел, сикереп торган иде, ләкин Даниловның ачулы тавышы аны кире ятарга мәҗбүр итте:

— Тукта! Барасы булма! Нәрсә син, үзеңнең дә тәгәрәп каласың киләме?

Броневик гөрелдәп, пулеметтан ата-ата, бу якка таба килергә борылды.

Исән калган сугышчы ызанга кереп яшеренде.

Машина, җирне гүләтеп, яссы борыны белән актарып ташларга җыенган сыман, ызанга таба юнәлде. Тик шунда гөрселдәп граната ярылуга, өреккәндәй, кинәт бер якка ыргылды. Бер генә секундка атуыннан туктап торды да, ярсып, үкереп, корыч җанвардай ырылдап, тагын алга ташланды, әмма шунда ук тагын туктап калды.

Машина белән кешенең шулай үлем сугышы башлауларын тыннарын да алмыйча күзәтеп торган сугышчылар кинәт җанланып киттеләр. Кайсыдыр кычкырып җибәрде.

— Әһә! Чукынды броневик, кадалды!

— Кара, кара! Вәлитов икән бит ул! Әнә папахасы. Исән картлач, исән!

Чыннан да, броневик янындагы ызаннан бер генә сулышка Вәлитовның папахасы күренеп калды. Ләкин куанырга иртәрәк булып чыкты. Вәлитов кире иптәшләре янына кайтырга дип яшеренгән ызаннан чыкты да сузылып яткан килеш хәрәкәтсез калды.

Шәмси, йөрәге әрнеп, җиргә капланды.

— Аййй!..

Полк яисә, дөресрәге, полкның исән калган берничә йөз сугышчысы икенче тапкыр һөҗүмгә күтәрелде. Иптәшләре узышлый Вәлитовны носилкага салдылар. Ул кул-аягын тота алмый, аңына килер-килмәс авыз эченнән нидер пышылдый иде. Шәмси аның калтыранган юеш кулларыннан алып битенә иелде.

— Әхмәди абый! Хәлең ничек?.. Кай төшең?

Әхмәди авыр итеп ыңгырашты да тынып калды. Шәмси атасы кебек яраткан Әхмәди абыйсын кочаклады, гүя суына башлаган кулларына үз җылысын бирергә теләгәндәй, кулларын кысып, маңгаен сыйпады. Аннары, кычкырып елап җибәрмәс өчен тешләрен кысып, ротасы артыннан йөгерде.

Икенче һөҗүмгә бару да җиңел булмады. Пулемет уты һаман да көчле иде әле.

Сугышчыларның байтагысы яраланган иде инде. Әле анда, әле монда бәйләүле куллар, канаган йөзләр, аксап баручылар күренә. Хәлләре беткәннәре котомкаларын ташлыйлар. Бара торгач, эштән чыгып, егылып калалар. Тик яраларын бәйләтәләр дә тагын торып китәләр. Тирләрен, каннарын сөртә-сөртә, тешләрен кысып, аксый-аксый үрмәлиләр.

Урталыкка җиткәндә Даниловка бер кызылармеец дәште:

— Иптәш командир, кулыңда кан...

Данилов кулының әчетүен шунда гына сизде. Винтовканың көбәгенә бармакларыннан канлы эз төшкән иде. «Шулай взводны калдырып китәргә туры килерме икәнни?» Ул, яраның алай куркынычлы булмавына ышанырга тырышып, взводы белән үрмәләүдә дәвам итте. Менә күп булса тагын йөз илле адым калгандыр. Аннан соң атака башланырга, дөньяның асты өстенә килсә дә, Юшунь позициясе алынырга тиеш. Шундый вакытта артта калырга ничек күңел түзсен? Тагын ун минутка чыдарга... Унбиш минутка... Ул, тешен кысып, үзенчә тагын да җәһәтрәк үрмәли башлады.

— Иптәш взводный, кулыңны бәйләтергә иде!

Әмма шул вакыт ротаның уң канатыннан Исмаевның ашыгырга кушып кул изәгәне күренде. Данилов каты гына кычкырып җибәрде:

— Хәзерләнергә! Артка калмаска!

Ләкин үзе никадәр тырышса да, взвод белән барырга хәле калмады, уң кулына таяна алмас булды. Җиңеннән өзлексез кан тама иде. Аның күз аллары караңгыланды, башы шаулый башлады, тәнен хәлсезлек басты...

Ул арада йөгерергә команда бирделәр. Даниловның взводы алга китте. Аның уңында бөтен полк, ә сулында тозлы күлнең сөзәк яры иде.

Алда моторлар гуләве ишетелде. Аклар ягыннан, нәкъ күл турындагы циклдән, берьюлы ике броневик күренде. Алар икесе янәшә тезмә өстенә килә башладылар.

Ул да түгел, броневикларның ике ягыннан кисәк кенә атлылар төркеме атылып чыкты. Аклар, атаканы ничек тә булса туктатырга, сугышны озаккарак сузарга теләп, актык чараларын күрәләр, сул канатны жимереп кереп, бу полкны чорнап алырга телиләр иде булса кирәк.

Хәл яхшыдан түгел иде. Ике броневик башны калкытырга да мөмкинлек бирмичә тезмәнең буеннан-буена аттырып йөриләр, шуннан файдаланып атлылар һаман якынлашып килә иде. Ротага яңа гына килгән яшь кызылармеецлар, котырынып өсләренә килгән атлыларны, алар өстендә ялтыраган ялангач кылычларны күргәч, каушап, артка күз салгалый башладылар. Иң кырыйда калган Данилов взводының хәле аеруча авыр иде.

Шул вакыт, тыны-өне бетеп, рота командирыннан вестовой йөгереп килде. Ул взвод командирын дәшә иде.

— Командир! Кайда Данилов?

Сугышчылар, ни әйтергә белмичә, бер-берсенә карандылар.

— Данилов юкмыни? Кем калды соң командир урынына?!

Уртадан Шәмси күтәрелде.

— Күрәсең, мин калганмын инде болай булгач!

— Тыңла! Рота командиры кавалерияне артка уздырмаска кушты! Кырылып бетсәгез бетәсез, әмма урыннан кузгалмыйсыз! Аңлашыламы? Сезгә бер пулемет килә.

Шәмси, дулкынланып, гомерендә беренче тапкыр команда бирде:

— Взвод, минем янга!

Шәмси Гайфуллинның мондыйны башыннан уздырганы бар, кавалериягә каршы торганда көчне бер йодрык итеп тупларга һәм залп белән атарга кирәген ул белә иде.

Алда акларның акырып «ура» кычкырганы ишетелде. Шәмси үз янына тупланган взводның артына басты. Бер атлыларга, бер взводка карап алды. «Килә төшсеннәр... якынрак, тагын бераз!..»

Взвод өстеннән гөрселдәп беренче залп күтәрелде.

Ул арада пулемет та килеп житте. Ләкин атлылар беренче залпны сизмәделәр. Күл ярыннан өскә күтәрелүгә, кылычларын айкап, акырышып, тагын да шәбрәк чабарга тотындылар. Шәмси, алар якынайган саен, үзенең усаллана һәм ярсый баруын сизде. Ачулы һәм нык тавыш белән:

— Прицел, прицел! Каушамаска!— дип кычкырды.

Гөрселдәве белән күңелләрне рәхәтләндереп тагын берничә залп яңгырады.

Бу вакытта әлеге пәһлеван санитар Даниловның ярасын бәйләргә тотынган иде. Ул, пулялардан башын яшереп, җиргә иелгәли, сүгенгәли иде.

— Биси, утырырга да ирек юк, коя да тора... Кычкырдым бит мин сиңа, элегрәк бәйләргә кирәк иде. Та ничоһо, тирән түгел...

Ул, ашыгып, икенче бинтын чыгарды.

— Кан күбрәк киткән. Кулбашың да яраланган икән әле синең! Кая, салыйк әле шинельне!

Атышның кинәт кенә тукталуына сәерсенеп, Данилов торып утырды. Алга таба күзе төшү белән сискәнеп китте. Атлылар ташкыны туп-туры аның взводы өстенә килә иде. Ул бәйләнеп җитмәгән бинтын сөйрәп, взводы артыннан йөгерде. Коты чыгып: «Бетерәләр!— дип уйлады.— Артта калып начар иттем. Ай, начар иттем!..» Акларның «ура» кычкыруларына ул эсселе-суыклы булып китте. Ул берничә мәртәбә егылды. Тагын торып йөгерде.

Якында гына команда тавышын, взводның залп белән атып ятуын ишеткәч, эченә бераз җан керде. Атлыларның буталуын күреп, шатлыгыннан кычкырып җибәрде:

— Кррой, ребята!

Бер залп шартлаган саен ул, җиргә сугып, взводына куәт бирә:

— Тагын!.. Тагын!..— дип кычкыра иде.

Бу вакытта уң канат, ике броневикны да кире чигендереп, алга бара башлаган иде. Шәмси взводы да, башкалар белән бергә, тимер чыбык киртәсенә атакага ташланды.

Иң кискен минутлар җитте. Контрреволюциянең ярсыган офицер полклары иң соңгы сугышка, үлем сугышына күтәрелделәр. Меңнәрчә кеше үтерү машинасы

ярсып эшкә тотынды. Перекоптан күчерелгән диңгез артиллериясе, иксез-чиксез пулеметлар — кургаш, чуен, ялкын өермәсе — һәммәсе берьюлы ыргый иде. Янәшә барган кешенең тавышы ишетелмәс булды. Шрапнель шартлавы, гранаталарның гөрселдәве астында яраланган, эштән чыгып арыган сугышчылар актык көче белән ялкынлы өермәне ерып, тимер чыбык киртәсенә таба үрмәләде.

Киртәгә җитәрәк, вестовой Исмаевтан приказ китерде:

— Кисәргә, җимертергә! Граната белән!

Хәер, команда биреп торуның кирәге дә булмады, килеп җиткән берсе үзе үк ташланды. Кайчылылар ашыгып кисәргә, кайчысызлар штыгы, кечкенә балтасы, прикладлары белән ватарга, каерырга тотынды. Кулларын, шинельләрен ерттырып, чыбык астыннан үрмәләп узалар, ярсып, ашыгып икенче рәткә, өченчесенә ташланалар иде.

Шәмсинең өстенә балчык кисәкләре яуды, авызына, күзенә ком тулды. Нәрсәдер аның фуражкасын чөеп ыргытты, тимер чыбык әле шинелен, әле обмоткасын ертып алды, тәне тоймас, үзе тирә-яктагы дәһшәттән курыкмас булды. Ул бөтен көче белән шуышты, тырмашты. Аның күңелендә бертуктаусыз бер генә уй бөтерелде. «Тизрәк бәреп чыгарга, тизрәк атакага ташланырга!»

Хәзер инде акларның окобы күренеп кенә тора. Ул буеннан-буена төтенгә, ялкынга күмелгән иде.

Шәмсинең тирә-ягында иптәшләре тимер чыбык кисәләр, казыкларны прикладларны белән каералар, аударалар, уфылдыйлар, нидер кычкыралар, егылып калалар, дүрт аякланып, түшләре белән шуып, тимер чыбык араларыннан узалар иде.

Менә, ниһаять, тимер чыбык киртәләренең аргы ягына бәреп чыктылар. Кинәт «ура» тавышы күтәрелде. Исән калган сугышчылар ярсып кычкыра-кычкыра аклар окобы өстенә ташландылар. Ротаның иң алдында Исмаев йөгерә иде.

Окоплар өстенә гранаталар ява башлады. Окоп юлларында яшел шинельләр, күтәрелгән куллар, атып маташучылар күзгә чалынды. Ләкин хәзер инде соң иде. Окопларда, окоп өсләрендә прикладлар чыркылдады, кемнәрдер акырып җибәрде, кемнәрдер шәфкать сорап кулын күтәрде.

Шул вакыт шатлыклы тавышлар ишетелде:

— Буденный!..

— Ура, атлы армия!..

Күз күреме җирне иңләтеп, ат аягы астында кырны гүләтеп, тыелгысыз көчле агым булып, өермәдәй тизлек белән үр артыннан Буденный атлылары килеп чыкты. Бөркет канаты кебек җәелгән кара буркалар, очып баргандай алга йөгенгән гәүдәләр, бөтен армия өстеннән күтәрелгән ялангач кылычлар, дәһшәтле бер ташкын булып, сирпелеп кенә үттеләр. Окоплар бер тилпенүлә артта калды. Атлы ташкын Врангельнең качып барган дивизияләре өстенә ташланды.

Җимерелгән окоплар, туралып ташланган гәүдәләр, ертылган погоннар, кыр уртасында турсаеп калган орудиеләр, пулеметлар яныннан узып, сугышчылар акларны куып диңгезгә таба киттеләр.

Бу — бер мең тугыз йөз егерменче елның унберенче ноябре иде.

1937—1957



35 тиен